# ШУРА

№ 27

2020



## ГАЛИЕВ МӘЧЕТЕ

2000999959196

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

## ЭЧТӘЛЕК

ВӘГАЗЬЛӘР

Аллаһы Тәгаләнең ихлас колларымы без? . . . . . . 12
Кайгыда булганнарга . . . . . . 19
Аллаһы Тәгаләнең «Әр-Раззак» исеме . . . . . . 27
Хөсетлек-көчсезлек ул . . . . . . 32
Дусларны сайлау . . . . . . 40
Хайваннарга карата мөнәсәбәт . . . . . . 46
Рәгаиб кичәсе . . . . . . 52
Иман баганалары . . . . . . 57
Ислам динендә хатын-кыз . . . . . . 64
Ислам – «сәлам» сүзеннән . . . . . . 69
Мигъраҗ кичәсе . . . . . . 74
Риба . . . . . . 79
Бәраәт кичәсе . . . . . . 86

ФӘТВАЛАР

Иясе бар кабергә икенче берәүне күмү мәсьәләсе . . . . . . 92
«Әәмин» сүзенең әйтелеше . . . . . . 93
Коръән укуга багышлана торган вакытның күләме . . . . . . 94

ҮРНӘК ЗАТЛАР

Пәйгамбәребезнең әнисе Әминә радыяллаһу ганһә . . . . . . 96

ФӘН

Шәригать хөкемнәре . . . . . . 106
Сәүдә итү (Сәүдәгәрлек) . . . . . . 113

ТАРИХ

Японияләге татарлар тарафыннан төзелгән беренче мәчет . . 122
Финляндиядә татар җәмәгатьчелегенең төп рухи һәм мәдәни үзәгенең барлыкка килүе . . . . . . 125

ТӘРБИЯ

Гыйлем иясенең һәм гыйлем алучының әдәпләре . . . . . . 132

Гаиләләребезне саклау – һәрберебезнең бурычы . . . . . . . . . . . 134

ТӘФСИР

Йосыф галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Фәтихә (Ачучы) сүрәсе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Әл-Галәкъ (Оешкан кан) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
«Әл-Кадр» («Кадер») сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Әл-Бәййинә (Ачык дәлил) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Әз-Зәлзәлә (Җир тетрәү) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Әл-Гәәдийәәт (Чабып баручылар) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . 163
Әл-Карига (Ишек каккан) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Әт-Тәкәәсүр (Арттыру) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Әл-Гаср (Икенде вакыты) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Әл-Һүмәзә (Яла ягучы) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Әл-Фил (Фил) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Курайш (Кораешләр) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Әл-Мәгүн (Изгелек кылу) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Әл-Кәүсәр (Муллык) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Әл-Кәфирун (Кяферләр) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Ән-Нәср (Ярдәм) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Мәсәд сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Әл-Ихлас сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Әл-Фәләкъ (Таң) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Ән-Нәс (Кешеләр) сүрәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

НӘСЫЙХӘТ

Ихлас бәяны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Олы гөнаһлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191

ӘДӘБИ СӘХИФӘ

Агулы сабак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199

**«ШУРА» дини альманах, №27**

*гыйнвар – март 2020*
*җөмәдәл-әүвәл – шәгъбан 1441*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Эдуард Димасов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 25.12.2019
Чыгу көне: 6.01.2020

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ:

________________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

۞_______________________________________________

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгене сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللّٰهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللّٰهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللّٰهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللّٰهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللّٰهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ

إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بارِكْ عَلى مُحَمَّدٍ، وَعَلى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاتِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләӟии һәдәәнә лиһәәӟәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләәән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләӟии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйӟү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-эллаһ». Нәшһәдүән ләә иләәһә илләллаһү. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаӟәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мүʼминиинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуӟмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъдү: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләӟиинәт-тәкау, вәл-ләӟиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйӟү билләһи: ________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________
________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалләлаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иẓәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйзү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхааммәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ẓәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә

вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә'мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

# Вәгазьләр

*10 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Аллаһы Тәгаләнең ихлас колларымы без?

«Күрсәм ышанырмын», ди кеше,
«Ышансаң күрерсең», ди Аллаһы.

Галәмнәрне юктан бар кылган, безне – Адәм балаларын дөньяга китереп, Үзенең чиксез нигъмәтләрен яудырып торучы Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз булса иде.

Галәмнәргә рәхмәт булып җибәрелмеш сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифәләребез барып ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә безнең кылган хәерле гамәлләребезне кабул итеп, ике җомга арасында кылынган гөнаһларыбызны гафу әйләсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә Үзенә иман китергән бәндәләрне «колым» дип атый:

يُنَزِّلَ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ عَلَىٰ مَن يَشَاءُ مِنْ عِبَادِهِ ۖ ﴿٩٠﴾

**«Аллаһы Үзе теләгән колларына нигъмәтләрен тәгаенли...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:90

وَهُوَ الْقَاهِرُ فَوْقَ عِبَادِهِ ۚ وَهُوَ الْحَكِيمُ الْخَبِيرُ ﴿١٨﴾

**«Ул коллары белән идарә итә, һәрнәрсәгә Хуҗа вә Җиңүчедер».**

«Әнгәм / Терлек», 6:18

وَيُرْسِلُ عَلَيْكُمْ حَفَظَةً

**«Ул – коллары өстендә чиксез куәтле. (Гамәлләрегезне язып) Саклаучыларны (фәрештәләрне) дә сезгә Ул юллый».**

«Әнгәм / Терлек», 6:61

Мәктәпләрдә өйрәнгәнчә, кол – хуҗасы кушканнарны берсүзсез, карусыз үтәүче, безнең очракта мөселман – буйсынучы. Ләә иләәһә илләллаһ, Мүхәммәдүр расүлүллаһ, дип ихластан бер тапкыр гына әйтсә дә, кеше мөселман була һәм Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, фарызларны үтәп, пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте буенча эш итәргә тиешбез. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин кешеләрне дә, җеннәрне дә Үземә гыйбадәт кылсыннар өчен яраттым».**

«Зарият / Таратучы», 51:56

Гыйбадәт – Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен эшләнгән ачык яки яшерен гамәлләр, Аллаһы риза булган сүзләр. Гыйбадәтләр тел, тән һәм мал белән башкарыла.

Тел белән башкарыла торган гыйбадәт:

1.Аллаһыны һәрдаим искә алу – «бисмилләһ», «сөбхәналлаһ», «әлхәмдүлилләһ», «Ләә иләәһә илләллаһ», «Аллаһу әкбәр» һәм башка зикерләр әйтү.

2. Тән белән гыйбадәт кылу: намаз уку, ураза тоту һ.б.

3. Мал белән гыйбадәт кылу: үзеңнең малыңнан мескеннәргә, мохтаҗларга өлеш чыгару:

а) зәкят бирү: елга бер тапкыр нисаб күләмендә (230 мең) ел дәвамында хәрәкәтсез яткан (банкта яки башка саклау урынында) байлыгы булса, 2,5% ын бирү. Нисаб күләмендә байлыгы булмаганнар зәкяттән азат ителә.

б) гошер бирү: бакчабызда су сипмичә үстергән уңышның (Аллаһы биргән) уннан берен, су сибеп үстергәннең (Аллаһы әмереннән) егермедән берен мохтаҗларга, мескеннәргә, дин юлында йөрүчеләргә, шәкертләргә бирү.

в) Корбан бәйрәмендә көндәлек хаҗәтләрдән тыш сарык сатып алырлык акчасы булганнарга Аллаһы ризалыгы өчен корбан чалу вәҗиб гамәл.

г) нәфел садакалар: үз теләгең белән, теләгән вакытта һәм теләгән күләмдә бирелә торган садакалар.

Садака – ислам шәригате буенча үзеңнән артканны түгел, үзеңә дә кирәкле малдан мескеннәргә, мохтаҗларга, дин юлында йөрүчеләргә дә өлеш чыгару.

Мөселман булу Аллаһы Тәгаләнең колы булу, гыйбадәт кылу гына түгел, ул кешенең яшәү рәвеше, мөселман әхлагын, әдәбен саклау, гөнаһлы гамәлләрдән – зина кылу, гайбәт сөйләү, ялганлау, сүгенү, харамнан тыелу; игелекле гамәлләр кылу – дуслык, туганлык, кардәшлекне саклау һәм үстерү, үзара яхшы мөгамәлә, өлкәннәрне (яше һәм дәрәҗәсе буенча) хөрмәт итү, мескеннәргә ярдәм итү, яшь буынга Ислам нигезләрен өйрәтү.

Үзебезнең бүгенге һәм үткәндәге гамәлләребезгә күз салыйк әле. Аллаһы Тәгалә кушканнарның кайсысын Аның колы буларак үтибез? Ә үтәү өчен нәрсә кирәк? Җавап гади: иманлы булу кирәк. Иман ул – Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә, фәрештәләренә, пәйгамбәрләренә, Аллаһының китапларына, Кыямәт көненә, тәкъдиргә – тормышыбызда булган яхшы һәм начар хәлләрнең Аллаһы Тәгаләдән булуына бернинди дәлилләрсез, шартларсыз, үзең күргәндәй ышану.

Аллаһы Тәгалә безгә төрле нигъмәтләр һәм алар белән файдаланыр өчен әманәт итеп тән һәм төрле әгъзалар биргән. Иң әһәмиятлесе: фикерләү сәләте, акыл нигъмәте һәм аның аркылы мөселманга иң зур байлык – иман байлыгы биргән. Коръәндә бик күп аятьләр «Әй иман китергән бәндәләр....», дип башлана һәм без – иманлы кешеләр, мөселман буларак, Аллаһы Тәгаләнең коллары буларак, динебезнең биш терәге булган: иман китерү, биш вакыт намаз уку, Рамазан аенда бер ай ураза тоту, зәкят бирү, матди мөмкинлеге һәм сәламәт булганнарга хаҗ кылу гамәлләрен үтибезме?

Кыямәт көнендә беренче сорау намаз турында булачак. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

الَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللَّـهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَىٰ جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ

**«Алар (акыл ияләре) аякта торганда да, утырган килеш тә, яныкларында килеш тә Аллаһыны зикер итәләр һәм күкләр белән җирнең яратылышы турында фикерлиләр...»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:191

Бу әмерләрне башкарып, Аллаһыга тәкъвалыгын күрсәтер өчен кешегә нәрсә кирәк? Зиннәтле бинамы? Юк! Шактый юл узарга мәҗбүр итә торган махсус билгеләнгән урынмы? Юк! Зур байлыкмы? Юк! Тәүбәгә килеп, ничек телим, шулай яшим дигән нәфес, теләкне җиңеп, ялкаулыкны ташлап, Коръәннән «Фәтихә һәм тагын берничә кыска сүрә һәм аять өйрәнергә, намаз укыйм дип ниятләргә, тәһарәт алырга, теләсә кайсы чиста, башкалар комачауламый торган урынга, кыйблага карап басып, намазны үтәргә кирәк, чөнки бөтен җир йөзе – мөселман кешесе өчен намаз урыны. Кызганыч, үзебезне Аллаһы Тәгаләнең коллары икәнлегебезне истән чыгарып, бу дөньяга Аллаһы безне сынау өчен генә яратканны да

онытып, нәфес колы булып яшәвебезне дәвам итәбез. Балаларыбызны да җитеш, зиннәтле тормышта яшәргә өйрәтәбез һәм кайчак моның өчен үкенергә дә туры килә.

Кешедән «ник намазга басмыйсың» дип сорагач, ул «әле вакыт җитмәгән», «вакыт юк», «намазга гөнаһларын юу өчен зур гөнаһлылар гына баса», дигән җаваплар ишетәсең. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Һәрбер кеше хаталы һәм иң хәерле, мактаулы хаталанучылар – хаталарын танып, аны төзәтергә теләүчеләр», – диде.

Коръәндә болай дип әйтелгән:

إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا فَأُولَٰئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٧٠﴾

**«Тик (көферлектән) тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына! Аларның (тәүбәләре сәбәпле сөртелгән) начарлыкларын Аллаһы күркәм нәрсәләр белән алмаштырачак. Аллаһы Гафу итүче, Рәхимле».**

«Фуркан / Аеручы», 25:70

Димәк, тәүбәгә килгән һәркем Аллаһының ярлыкавына лаек. «Җирдә бик зур гөнаһлылар да яши, шуларны Аллаһы Тәгалә җәзалаганын күрсәм, намазга басам», – дип әйтүчеләр бар. «Кылган гөнаһларына күрә Аллаһы инсаннарны җәзалый барса, Җир йөзендә бер генә җан иясе дә калмас иде. Ләкин Аллаһы җәза бирүне Үзенә генә мәгълүм бер билгеләнгән вакытка кичектереп килә. Вакыты җиткәч барысы да үз өлешен алыр.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

فَإِنَّ اللَّهَ كَانَ بِعِبَادِهِ بَصِيرًا ﴿٤٥﴾

**«Хакыйкатьтә Аллаһы Үз колларын күреп тора»,** – дип әйткән.

«Мәләикә / Фәрештәләр», 35:45

Аллаһы Тәгаләнең яраткан колы булу, Аның ризалыгына ирешү өчен, Аның кушканнарын үтәү, тыйганнарыннан тыелу өчен теләк, тырышлык, авырлыкларга һәм артык рәхәткә сабыр булу кирәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

ذَٰلِكَ بِأَنَّ اللَّهَ لَمْ يَكُ مُغَيِّرًا نِّعْمَةً أَنْعَمَهَا عَلَىٰ قَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ۙ وَأَنَّ اللَّهَ سَمِيعٌ عَلِيمٌ ﴿٥٣﴾

**«Бу (газап) – Аллаһы бер кавемгә биргән нигъмәтне үзгәртмәгәне өчен, алар күңелләрендә булганны (яхшы холыкны начар омтылышка) үзгәртмәсәләр. Һичшиксез, Аллаһы – Ишетүче һәм Белүче».**

«Әнфәл / Табыш», 8:53

وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ ۖ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ إِذَا دَعَانِ ۖ فَلْيَسْتَجِيبُوا لِي وَلْيُؤْمِنُوا بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ ﴿١٨٦﴾

**«Дога кылучының догасын Миңа ялварган чагында ук кабул итәм. Миннән кабул итүне сорасыннар һәм Миңа иман китерсеннәр. Бәлки, алар (дини һәм дөньяви мәнфәгатьләренә ирешеп,) туры юлдан барырлар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:186

Кызганыч, без гаепне үзебездән түгел, башкалардан эзлибез. Биш вакыт намазның һәрберсенә ун-унбиш минут вакытны кызганабыз, ә Аллаһы Тәгалә биргән иң кыйммәтле вакытны сәгатьләр буе телевизор каршында утыруга, урамда гайбәт сөйләүгә әрәм итүебезне башыбызга да кертмибез. Ирләргә: Аллаһы Тәгалә биргән бер атнадагы 168 сәгатьнең бер сәгатен иң бөек намаз – җәмәгать белән укыла торган җомга намазына биреп, олы бурычыбызның берсен генә булса да үти башлыйк.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр! Акылыбызны эшкә җигеп, иманыбызны ныгытып, мәңгелек тормыш – җәннәт һәм җәһәннәм турында уйланып, бу дөньядагы соңгы сулышыбызны алганчы Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, Аның яраткан коллары булып, дөньялыкта Аллаһының ризалыгына, Ахирәттә рәхмәтенә ирешергә омтылып яшәргә Аллаһы Тәгалә насыйп итсен.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Габдулла хәзрәт Сираҗиев,*

*Питрәч районы, Күн мәхәлләсе, «Иман нуры» мәчете имам хатыйбы*

*17 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Кайгыда булганнарга

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифәләрен бирсә иде.

Мөхтәрәм газиз дин кардәшләрем, Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي كَبَدٍ ﴿٤﴾

**«Без кешене авырлыкта барлыкка китердек».**

«Бәләде / Шәһәр», 90:4

Әйе, җәмәгать! Кеше яралганнан алып үлеменә кадәр авырлыкларда. Аның ана карынында 9 ай булуы, әнисенең тилмереп аны саклап йөрүе булсынмы. Кеше дөньяга барлыкка килгәндә, әнисенең тулгак белән авырдан бала табуымы. Үсә торгач, дөнья авырлыклары барлыкка килә: һәрвакыт акча җитми; гаиләсе булгач, балалары тугач, ул янә авырлыклар, төшенкелектә яши: балаларның мәктәп проблемалары, аларны урнаштыру һ.б.

Һәм аның бу авырлыклары һич тә туктамый, ул һич тынычлана алмый. Ә бит Ахирәткә, бакый дөньяга күчкәч, анда тагын да зуррак авырлыклар, кайгылар башлана.

Ләкин бүгенге хотбәдә кешеләр арасында иң хәерлеләре булган пәйгамбәрләр, аларның якыннары, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу

галәйһи вә сәлләмнең бу авырлыкларга каршы торганнары, нинди сүзләр әйткәннәре турында сөйлисем килә.

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

الم ﴿١﴾ أَحَسِبَ النَّاسُ أَن يُتْرَكُوا أَن يَقُولُوا آمَنَّا وَهُمْ لَا يُفْتَنُونَ ﴿٢﴾

**«Әлиф. Ләм. Мим. Кешеләр «без иман китердек» дигәннән соң, Аллаһы аларны сынамас дип уйлыйлармени? Без инде аларга кадәр булган кешеләрне сынадык. Без, һичшиксез, алар арасында хак сүздә булып, нык торганнарын да, тугры булмаганнарын да белербез».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:1-2

Димәк, тормыш авырлыклары – ул Аллаһы тарафыннан килүче сынаулар. Без ул авырлыкларны ничек итеп каршыларбыз, нинди сүзләр әйтеп, нинди эшләр эшләрбез икән?

Шуңа күрә ул авырлыкларның, ул сынауларның иң зурларын Аллаһы пәйгамбәрләргә, илчеләргә бирде. Һәм дә ул пәйгамбәрләрнең җаваплары, сынауларны үтүләре безнең өчен яхшы үрнәк булды.

Аллаһының Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иң зур бәла-казалар пәйгамбәрләргә килә. Моннан җиңелрәкләре – изгеләргә. Аннан да җиңелрәкләре – изгеләрнең дәрәҗәләреннән түбәнрәкләргә», – дип әйткән. Пәйгамбәрләр арасында зур бәлага очраган Әюб пәйгамбәр бар иде. Аның байлыгы, мал-мөлкәте, балалары күп иде. Ләкин көннәрдән бер көнне Аллаһы тәкъдире буенча мал-мөлкәте юкка чыга, балалары бер-бер артлы үлеп бетә, сәламәтлеге какшый, бик каты авырый башлый. Бер аять тәфсирендә «Әюб галәйһиссәлам лепра[1] чире белән чирли башлый» дип әйтелә. Сәламәт тәненнән йөрәге һәм теле генә имин килеш калган, янында терәк булырдай хатыны гына булган шул авыр вакытта ул Аллаһыга болай дип ялвара, дога кыла.

[1] Барыс авыруы.

وَأَيُّوبَ إِذْ نَادَىٰ رَبَّهُ أَنِّي مَسَّنِيَ الضُّرُّ وَأَنتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ

**«Шулай ук Әюбне исеңә төшер. Ул Раббысына ялварып, «Дөреслектә миңа авырлык, зыян килде. Ә Син, Раббым, мәрхәмәтлеләр арасында иң мәрхәмәтлесе!» – диде».**

Шунда Аллаһы Тәгалә аңа җавап биреп болай дип әйтте:

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ فَكَشَفْنَا مَا بِهِ مِن ضُرٍّ ۖ وَآتَيْنَاهُ أَهْلَهُ وَمِثْلَهُم مَّعَهُمْ رَحْمَةً مِّنْ عِندِنَا وَذِكْرَىٰ لِلْعَابِدِينَ

**«Һәм без аның догасына җавап бирдек. Аңа тигән авырлыкны бетердек. Аңа гаиләсен китердек һәм шуңа өстәп Бездән рәхмәтебезне бирдек. Бу – гыйбадәт кылучыларга бер искә төшерү булып торсын!»**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:83-84

Карагыз, җәмәгать! Шундый авырлыкларда да Әюб галәйһиссәлам Аллаһыга ялварды, Аңа дога кылды. Бөтен дөньяны каргап, төшенкелеккә бирелеп утырмады. Аның авырлыкларга каршы торуы – безнең өчен күркәм мисалдыр.

Шулай ук Ягъкуб пәйгамбәр кыйссасын искә төшерик. Ата балалары арасында иң сөйгән улы Йосыфны югалтты. Аны «ул үлде, аны бүре ашады» дип алдадылар. Шул кайгыдан елаганга Ягъкуб пәйгамбәрнең күзенә зыян килде: күзенә ак төшеп, сукырайды. Ләкин шулай да Коръәндә аның сүзләре ап-ачык итеп әйтелгән.

فَصَبْرٌ جَمِيلٌ ۖ

**«Күркәм сабырлык белән түзәрбез»,** – диде.

«Йосыф», 12:83

قَالَ إِنَّمَا أَشْكُو بَثِّي وَحُزْنِي إِلَى اللّهِ

**«Ягъкуб: мин моң-зарларымны һәм кайгымны Аллаһыга гына юнәлтәм», – дип әйтте».**

«Йосыф», 12:86

Ягъни, шундый авыр хәлдә дә Аллаһы ризалыгы өчен сабыр итәм. Кайгымның авырлыгын, моң-зарларымны Аллаһыга гына юллыйм, Аннан гына дога кылып яхшылыкны өмет итәм диде.

Ә бүген нәрсә? Бүген кешегә чебен очы кадәр генә авырлык килсә дә, ул бу кайгысында бөтен дөньяны гаепли, язмышына, Аллаһы тәкъдиренә көферлек сүзләре яудыра башлый. Кайгы вакытында Раббысы барлыгын, кайгыларны бетерүче, догаларны кабул итүче барлыгын оныта, хәтта кайгыга бирелеп тормышы аска таба тәгәри. Ә бит бу безнең дөньябыз – фани дөнья. Үзебез дә бу дөньяга мәңгелеккә килмәгәнбез. Әле алда безне мәңгелек Ахирәт тормышы көтә.

Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең дә тормышында зур авырлыклар булды. Пәйгамбәребезне Мәккә мөшрикләре эзәрлекләп, аны үтерергә теләгәндә, Аллаһы аңа Мәккәдән Мәдинәгә күченергә әмер итте. Пәйгамбәребез шул күченешендә иң якын иптәше Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән юлга чыга, ләкин артларыннан мөшрикләр дә куалый башлый. Шулардан качырга теләп, тау башына менеп, кечкенә генә тау тишегенә керәләр. Шунда качып утыралар. Ләкин дошманнары аларга якынайгач, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Әй, Аллаһының Илчесе! Әгәр боларның берәрсе аяк астына караса, безне күрәчәк», – дип әйткәч, Расүлебез: «Әй, Әбү Бәкер! Әгәр бу икәүнең өченчесе ярдәмче, яклаучы Аллаһы булса, бу икәү турында ни әйтер идең?» – дип аны тынычландыра. Әйе, җәмәгать, Аллаһының Илчесе хәтта мондый авыр вакытта да, үлем куркынычы якын булганда да Аллаһыга бөтен иманы белән юнәлгән, Аллаһыга тәвәккәлләгән, Аннан гына ярдәм көткән.

Шуңа күрә мөэмин-мөселман үзенең тормышына авырлык килсә: «Аллаһы безне ташламас, җиңеллеген бирер», – дип сабыр итәргә тиеш.

Әгәр уйлап карасак, хәзерге көндә без зәгыйфь, мескеннәр, хәтта кечкенә авырлыкларны күреп, төшенкелеккә бирeләбез: акча җитмәде, матур күлмәк, пәлтә алып булмады, малай укуын бишлегә тәмамлый алмады, теләгән машинаны алып булмады һәм башка төрле күренешләргә борчылабыз. Бу авырлыкларны да күреп, кешенең дөньясы караңгылана, уй-фикерләре чуала. Безгә кадәр яшәгән пәйгамбәрләр булсынмы, сәхабәләр булсынмы, аларның бәла-казалары безнеке белән чагыштырырлык түгел. Ләкин алар һәрвакыт Аллаһыга ялвардылар. Җиңеллекне сорап дога кылдылар. Аллаһының рәхмәтенә өметләнделәр.

Дөрестән дә, бу безнең өчен зур гыйбрәттер!

Шулай Ибраһим галәйһиссәлам һәм Һаҗәр радыяллаһу ганһә кыйссасын карап китик. Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы әмеренә буйсынып, Һаҗәрне һәм улы Исмәгыйльне хәзерге Кәгъбәтулла янына, су булмаган чүлгә китерә, эчәргә әзрәк су, ашарга азык калдырып, алар яныннан китә. Китеп барганда Һаҗәр: «Нигә син безне су да, бернәрсә дә булмаган җирдә калдырасың», – дип кат-кат сорый. Ибраһим җавап бирми. Шуннан соң Һаҗәр анабыз: «Безне монда калдырырга Аллаһы әмер иттеме?» – дигәч, Ибраһим: «Әйе», – дип җавап бирә. Шуннан соң Һаҗәр анабыз: «Алай булса, Аллаһы безне ярдәмсез калдырмас!» – дип әйтә. Бу һәрберебезгә күркәм үрнәк.

Ул кыйссаны тулысынча күп тапкыр ишеткәнегез бардыр, җәмәгать: Аллаһы Тәгалә Һаҗәргә һәм улы Исмәгыйльгә зәм-зәм суын бирә, аннары үтеп бара торган кәрван туктап, шунда гомер итә башлый… Берсе дә ачтан үлмәде, берсе дә чүлдә көеп, вафат булмады, чөнки Аллаһы аларны тәрбияләде, ризыкландырды.

Ибраһим галәйһиссәлам аларны шул чүлдә калдыргач мондый дога кыла. Ул дога «Ибраһим» сүрәсендә әйтелгән:

رَّبَّنَا إِنِّي أَسْكَنتُ مِن ذُرِّيَّتِي بِوَادٍ غَيْرِ ذِي زَرْعٍ عِندَ بَيْتِكَ الْمُحَرَّمِ رَبَّنَا لِيُقِيمُوا الصَّلَاةَ فَاجْعَلْ أَفْئِدَةً مِّنَ النَّاسِ تَهْوِي إِلَيْهِمْ وَارْزُقْهُم مِّنَ الثَّمَرَاتِ لَعَلَّهُمْ يَشْكُرُونَ ﴿٣٧﴾

**«Йә Раббыбыз! Мин гаиләмнең бер өлешен бер үсемлек булмаган үзәндә, Синең тыюлыгың булган Йортың янында калдырдым. Алар намаз әһелләре булсалар иде. Кешеләрнең йөрәкләренә аларга карата өлфәт, ярату, кабул итүне сал. Һәм аларны ризыкландыр. Бәлки алар шөкер итүчеләрдән булырлар!»**

«Ибраһим», 14:37

Ибраһим Аллаһы әмеренә буйсынды, каршы килмәде, гаиләсе өчен иминлек сорап дога кылды, Аллаһыга ялварды.

Без дә, мөхтәрәм җәмәгать, Ибраһим пәйгамбәр үрнәгенә ияреп, нинди генә авырлыгыбыз булмасын, нинди генә кайгы килмәсен, догада булсак иде. Аллаһы Раббыбызга аларны чишү, аларны бетерү берни тормый. Раббыбызның кодрәте киң, Раббыбыз юмарт, Раббыбызның байлыгыннан дөньяда булган бөтен мал-мөлкәт бернәрсә киметмәс.

Шуңа күрә Аллаһы Раббыбыз безгә болай дип әйтте:

أَمَّن يُجِيبُ الْمُضْطَرَّ إِذَا دَعَاهُ وَيَكْشِفُ السُّوءَ وَيَجْعَلُكُمْ خُلَفَاءَ الْأَرْضِ ۗ أَإِلَٰهٌ مَّعَ اللَّهِ ۚ قَلِيلًا مَّا تَذَكَّرُونَ ﴿٦٢﴾

**«Авырлыкта булган кешенең догасына кем генә соң җавап бирә алыр, кайгысын бетерер һәм сезне җир өстендә хәлифәләр итеп калдырыр? Аллаһыдан башка илаһ бармы? Ләкин сез нәсыйхәтләрне бик аз искә аласыз!»**

«Нәмел / Кырмыска», 27:62

Авырлыкта калдың икән, Аллаһыга ялвар, дога кыл! Бурычларың җыелды икән, Аллаһыга ялвар, дога кыл! Гаиләңә кайгы килде икән, Аллаһыга ялвар, дога кыл! Балаларыңа тәүфыйк-һидаять телисең икән, Аллаһыдан сора, Аңа дога кыл!

Аллаһы Раббыбыз Коръәннең «Инширах» сүрәсендә болай дип әйтә:

فَإِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٥﴾ إِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٦﴾

**«Дөреслектә, һәр авырлыктан соң җиңеллек килә! Һәр авырлыктан соң җиңеллек килә».**

«Инширах / Ачмак», 94:5-6

Нәрсә генә булмасын, Аллаһы безгә җиңеллекне бирермен диде. Ләкин бездән таләп ителгәне – ул Аллаһыга буйсынып, иманлы рәвештә сабыр булырга һәм дә Аллаһыга тәвәккәләргә. Хәерлесен бары тик Аллаһыдан гына өмет итәргә кирәк.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әгәр мөселманга ниндидер кайгы килгәндә: «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун. Йә Аллаһы! Бу кайгыга сабыр иткән өчен әҗерләреңне насыйп итсәң иде. Миңа аны яхшылык белән алмаштырсаң иде», – дип әйтсә, Аллаһы ул кайгысына сабыр иткәне өчен әҗер-савапларын насыйп итәр һәм җиңеллек белән кайгысын алмаштырыр», – дип әйтте.

Шул доганы укып, Аллаһыга юнәлсәк, сынауларны үттек дигәнне аңлата, мөхтәрәм җәмәгать.

Сүземнең ахырында шуны әйтәсем килә: тормышыңда нинди генә авырлык, кайгы яки хәсрәт килмәсен, бу сиңа әҗер, гөнаһларыңның сөртелүенә бер сәбәп булып тора.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Мөселманга тигән һәртөрле авыру, кайгы-хәсрәт, авырлык, хәтта аягына кергән чәнечке үсемлеге өчен дә Аллаһы аның гөнаһларын ярлыкар, сөртер!» – дип әйткән.

Аллаһы Раббыбыз безне сакласын, бәла-казалардан имин кылсын! Авыр хәлебезне җиңеләйтсен! Әмин!

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Сәлимҗан хәзрәт Домнин,*
*Кабан арты мәчете имамы*

*24 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-әүвәл аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Аллаһы Тәгаләнең «Әр-Раззак» исеме

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәналәрбез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифәләрен бирсә иде.

Җомга көнен олуглап мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм, газиз дин кардәшләребез барчабызга да Аллаһының сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте ирешсә иде. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Бүгенге җомга вәгазебез Аллаһы Тәгаләнең «Әр-Раззак» исеменә багышлана.

Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме арасында Коръәндә искә алынган «Әр-Раззак» исеме бар. Ул тәрҗемә ителгәндә «Бәрәкәт һәм ризык бирүче», мәгънәсендә килә. Адәмнәргә тормышта яшәү өчен кирәк булган әйбер хакында Коръәндә хәбәр ителә. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ هُوَ الرَّزَّاقُ ذُو الْقُوَّةِ الْمَتِينُ ﴿٥٨﴾

**«Шиксез, Ул – Аллаһы барча мәхлукатьне ризыкландыручы һәм олуг куәт ияседер».**

«Зарият / Таратучы», 51:58

Әлеге аятьтән һәр нәрсәне, һәр җан иясен ризыкландыручы – Аллаһы Тәгалә икәне аңлашыла. Ул җан ияләре кайда гына һәм нинди зурлыкта булсалар да, Аллаһы Тәгаләнең аларны ризыкландырырга көч-кодрәте җитә. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән җир өстендәге барча җан ияләре

җирне эшкәртмәсә дә үзләренә туклану өчен ризык таба. Болардан кала Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә кешеләргә ризыклану өчен җирдә яшәүче хайваннарның, күктә очучы кошларның һәм суда йөзүче балыкларның итләрен файдалануны хәләл кылган.

Коръәндә шулай ук Аллаһы Тәгаләнең кисәтүе дә килә. Әгәр Ул җирне Үзенең рәхмәтеннән калдырса, җир бернинди дә уңыш бирми. Яңгырлар җирне сугарудан туктаса, җир үле чүлгә әйләнә.

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

أَمَّنْ هَٰذَا الَّذِي يَرْزُقُكُمْ إِنْ أَمْسَكَ رِزْقَهُ ۚ بَل لَّجُّوا فِي عُتُوٍّ وَنُفُورٍ ﴿٢١﴾

**«Аллаһыдан башка сезләрне кем ризыкландыра, әллә сынымнарыгыз ризыкландырамы?»**

«Мүлек / Патшалык», 67:21

Ләкин Аллаһы Тәгалә чиксез рәхмәтле һәм Ул Үзенең рәхмәтләрен санамый. Шулай ук Аллаһы Тәгалә түбәндәге аятьтә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ ۚ هَلْ مِنْ خَالِقٍ غَيْرُ اللَّهِ يَرْزُقُكُم مِّنَ السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ ۚ لَا إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ ۖ فَأَنَّىٰ تُؤْفَكُونَ ﴿٣﴾

**«Ий кешеләр, Аллаһының сезгә биргән нигъмәтләрен хәтерегезгә төшереп Аңа гыйбадәт кылырга вә итагать итәргә бурычлы икәнегезне белегез, әллә Аллаһыдан башка күктән су иңдереп, җирдән үстереп сезгә ризык бирүче бер зат бармы? Әлбәттә юк, коллык кылырга яраклы һич Илаһ юк, мәгәр Аллаһы Үзе генәдер».**

«Мәләикә / Фәрештәләр», 35:3

Аллаһы Тәгалә кешеләргә бу дөньяда биргән нигъмәтләреннән кала җәннәттә дә шундый ук тормыш әзерләгән, бәлки мөэминнәргә тагы да яхшыракны хәзерләгән.

Түбәндәге аятьтә Аллаһы Тәгалә кешеләрнең исләренә төшерә:

فَلَا تَعْلَمُ نَفْسٌ مَّا أُخْفِيَ لَهُم مِّن قُرَّةِ أَعْيُنٍ جَزَاءً بِمَا كَانُوا يَعْمَلُونَ ﴿١٧﴾

**«Җәннәткә керәсе мөэминнәр аларга анда нәрсә хәзерләнгәнлеген алдан һичберсе белмәс, җәннәткә кереп күргәч, күзләре карарланыр, күңелләре шатланыр, аларның кылган яхшылыкларына изге җәза булсын өчен».**

«Сәҗдә», 32:17

«Һуд» сүрәсенең түбәндәге аятендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمَا مِن دَابَّةٍ فِي الْأَرْضِ إِلَّا عَلَى اللَّهِ رِزْقُهَا وَيَعْلَمُ مُسْتَقَرَّهَا وَمُسْتَوْدَعَهَا ۚ
كُلٌّ فِي كِتَابٍ مُّبِينٍ ﴿٦﴾

**«Җирдәге һәр җан иясенең ризыгы Аллаһы кулында, дәхи аларның торачак җирләрен вә үлгәч күмеләчәк җирләрен беләр. Барчасы Ләүхүл Мәхфүздә язылыр».**

«Һуд», 11:6

Аллаһы Тәгалә ризыкны барлык җан иясенә: иман китерүчегә һәм иман китермәүчегә дә, изгеләргә һәм гөнаһлыларга да биргән. Ул һәрберсен ризыкландыра: кемнәргәдер байлыкны күп, ә кемгәдер аз бирә. Ләкин бу тормышта кулланыла торган нәрсәләр Аллаһының яратуыннан түгел, Аллаһы Тәгалә бу нәрсәләрне барча кешегә: яратканына да, яратмаганына да бирәчәк. Әмма Ахирәттә Аллаһы Тәгалә Үзенең яраткан колларына гына бирә.

فَأَمَّا الْإِنسَانُ إِذَا مَا ابْتَلَاهُ رَبُّهُ فَأَكْرَمَهُ وَنَعَّمَهُ فَيَقُولُ رَبِّي أَكْرَمَنِ ﴿١٥﴾
وَأَمَّا إِذَا مَا ابْتَلَاهُ فَقَدَرَ عَلَيْهِ رِزْقَهُ فَيَقُولُ رَبِّي أَهَانَنِ ﴿١٦﴾ كَلَّا ۖ بَل لَّا
تُكْرِمُونَ الْيَتِيمَ ﴿١٧﴾

**«Әмма адәм баласы Раббысы аны дөнья байлыгы белән мүбтәлә кылса һәм дөнья эшләрендә кешеләр арасында хөрмәтле итсә, ул мине Аллаһы хөрмәтләде, дип, дөнья байлыгы белән генә үзен Аллаһының дусты саныйдыр. Вә әмма Раббысы аның ризыгын кылып, ярлылык белән мүбтәлә[1] итсә, ул Раббым мине хур итте, диядер. Кешенең Аллаһы каршында хөрмәте дөнья байлыгы белән түгел, бәлки чын иман, хак дин һәм изге гамәлләр беләндер. Хур булуы да ярлылык белән түгел, бәлки имансыз, динсез булу белән һәм нәфескә ияреп азгынлык кылу беләндер».**

«Фәҗер / Таң», 89:15-17

Әйтүебезчә, беренче төр ризык бөтенесенә бирелә: динлегә дә, динсезгә дә, гөнаһлыга һәм гөнаһсызга да. Ә менә икенче төр ризык бары тик мөэминнәргә, Аллаһы Тәгаләнең яраткан колларына гына бирелә. Икенче төр ризык – җан ризыгы, иман, туры юл. Шуңа күрә кешегә Аллаһыдан ике төр ризыкны: гомум ризыкны һәм иман ризыгын да сорау вәҗиб булып тора. Кем Аллаһыдан курка, Аллаһы Тәгалә аңа уйламаган җирдән ризыкны киң кылып бирә. Шуңа күрә дә ризык табу өчен гөнаһлы эшләрдән ераклашырга кирәк, чөнки гөнаһлы эшләр, ризыкның азаюына һәм иманның зәгыйфьләнүенә сәбәп булып тора. Төрле бәла-казалар да шул сәбәпле килә. Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу болай дип әйткән: «Кайгы гөнаһ сәбәпле килә, ә тәүбә кылу сәбәпле китә».

Барча ризык Аллаһы Тәгалә кулында, кеше үзенә язылган ризыкны кулланмыйча дөньядан китми. Кем шуңа ышана, кемдә шундый иман байлыгы бар, шул кеше беркайчан да төшенкелеккә бирелмәс. Ул һәрвакыт Аллаһыга ышана һәм барча эшләрен Аллаһыга тапшыра. Бу кешене Аллаһы Тәгалә беркайчан да ризыксыз итмәс һәм сораган догасын җавапсыз калдырмас.

[1] Мүбтәлә ителү – сыналу.

Әй Раббыбыз Аллаһы, Үзеңнең рәхмәтең белән динебезгә һәм тормышыбызга файда китерә торган хәерле һәм хәләл ризыклар насыйп итсәң иде. Әәмин.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Илшат хәзрәт Динмөхәммәтов,*

*Норлат районы, Кизләү авылы «Иске мәчет» имамы*

*31 гыйнвар вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Хөсетлек-көчсезлек ул

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәналәрбез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифәләрен бирсә иде. Ислам динебез тән һәм рухи яктан пакьлеккә өнди, әмма рухи чисталык тән чисталыгына караганда әһәмиятлерәк. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَوْمَ لَا يَنفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ ﴿٨٨﴾ إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ ﴿٨٩﴾

**«Ул көндә малы вә баласы һичкемгә файда бирмәс. Мәгәр кеше мөшриклек вә монафикълык керләреннән күңеле пакь хәлдә чын мөселман булып килсә, аңа файда булыр».**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:88-89

Аллаһы Тәгалә Китабында калебкә күп тапкыр игътибар итә. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә үзенең хәдисендә болай дип әйткән:

«Дөреслектә Кыямәт көнендә Аллаһы сезнең тәннәрегезгә һәм сурәтләрегезгә карамас, ләкин сезнең калебләрегезгә карар»[1].

Шулай ук Аллаһы рухи авырулардан кисәтә, чөнки аларның шәхескә һәм җәмгыяткә зарары тиядер, андый очракларда истигазә сүрәләрен укырга куша.

---

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ (١) مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ (٢) وَمِنْ شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ (٣) وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ (٤) وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ (٥)

**«(Расүлем!) Әйт: «Таңның Раббысына сыенамын. Ул яраткан (кешеләр һәм җеннәрдән булган бөтен начар) нәрсәләрнең зарарыннан. (Караңгылыгы һәрнәрсә өстенә төшеп,) Каплаган чакта куе караңгылык зарарыннан. (Җепләргә ясаган) Төеннәргә (төкерә-төкерә) өргән (сихерче) җаннарның зарарыннан да. Янә көнләшүченең көнләшкән чагындагы зарарыннан да».**

«Фәләкъ», 113

Кешеләр арасында бик күп рухи авырулар таралган: явызлык, көнләшү, ялганлык, бер-берсенә нәфрәт һәм башкалар. Үзебезгә теләгәннәрен кардәшләребезгә теләмәсәк, шул калеб авыруларыннан котылып булмас.

Шулар арасындагы иң куркыныч авыруларның берсе – ул көнчелек. Бу сыйфат аркасында кеше үзенә һәм башкаларга зыян китерә. Белгәнебезчә, дөньяда беренче гөнаһ шул сыйфат аркасында эшләнде. Адәм галәйһиссәламнең улы Кабил көнләшеп, үзенең бертуган кардәшен Һабилне үтерде. Бу сыйфат башка гөнаһларга юл ача һәм иң әүвәл якыннардан, дуслардан, күршеләрдән башланып китә. Янындагы көнләшүче беркайчан да якынының аңардан өстен булуын яратмас. Туганының, кардәшенең, күршесенең малы, көче, гыйлеме, дәрәҗәсе, эше аңардан яхшырак булуын сөймәс, бигрәк тә сәүдәгәрләрнең бер юнәлештә эшләре булса. Гади эшчеләр арасында да көнләшү бар. Шуңа күрә, әгәр искә төшерелгән төркемнәр арасында булган мөнәсәбәт начар булса, гаҗәп түгелдер, ул бары шул көнчелек нәтиҗәсе.

## Көнчелекнең сәбәпләре

Дөреслектә, көнчелек хисе тәкъдир һәм Аллаһының исемнәрен, сыйфатларын начар аңлаудан килеп чыга.

Тәкъва кеше башка кешеләргә карата көнчелек, күрә алмау хисе сакламый, чөнки һәрбер нәрсә Аллаһының Әл-Галим (һәр нәрсәне Белүче) һәм Әл-Хәким (Хикмәт иясе) дигән сыйфатлары белән бәйле.

Беренче сәбәп: Көнләшкән кешегә ачу тоту, берәр бәла-каза килсә шатлану, берәр яхшылык килсә кайгыру. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

«أَمْ يَحْسُدُونَ النَّاسَ عَلَى مَا آتَاهُمُ اللَّهُ مِنْ فَضْلِهِ فَقَدْ آتَيْنَا آلَ إِبْرَاهِيمَ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَآتَيْنَاهُمْ مُلْكًا عَظِيمًا»

**«Йә ул (яһүдләр) кешеләргә хөсетлек кылалармы? Ул кешеләргә Аллаһы Үз фазыйләтеннән нигъмәтләр яки дәрәҗә биргәне өчен. Дөреслектә Ибраһим балаларына китап бирдек, ислам диненең хөкемнәрен өйрәттек һәм зур байлык бирдек».**

«Нисә / Хатыннар», 4:54

Икенче сәбәп: Тәкәбберлек һәм горурлык. Башкаларда яхшырак әйбер күреп, үзе аны булдыра алмаса, шуны яратмау. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَقَالُوا لَوْلَا نُزِّلَ هَذَا الْقُرْآنُ عَلَى رَجُلٍ مِنَ الْقَرْيَتَيْنِ عَظِيمٍ

**«Алар янә әйттеләр: «Ни булыр иде, әгәр бу Коръән Мәккә яки Таиф шәһәрендәге бер олуг дәрәҗәле бай иргә иңдерелгән булса», – дип. Күрәсез алар бай кешене, гакыллы туры кешедән артык күргәннәр».**

«Зүхъруф / Зиннәтләнү», 43:31

Шулай ук Аллаһы Тәгалә түбәндәге аятьтә болай дип әйтә:

أَهَؤُلَاءِ مَنَّ اللَّهُ عَلَيْهِمْ مِنْ بَيْنِنَا

**«Йә шул кешеләрне безнең арадан Аллаһы бүләкләдеме»**

«Әнгәм / Терлек», 6:53

Өченче сәбәп: Рәислекне һәм алда булуын ярату. Берәр нәрсәдә ул гына алда, беренче булуын теләү.

Дүртенче сәбәп: Аллаһының тәкъдиренә ачу тоту. Аллаһы башкаларга биргән нигъмәтләргә, үзендә ул күп булса да, көнләшеп карау.

Бишенче сәбәп: Астыртын һәм саран булуы. Башкаларда бу нигъмәтләр булмасын дип теләү, башкаларда яхшырак әйбер күреп, кемнеңдер баерак, бәхетлерәк яшәвенә көнләшеп карау. Берәүләрнең ниндидер дөньяви нигъмәтләргә ия булуы ул кешедә: «Нигә анда бар, ә миндә юк», яисә: «Аныкы бетеп, миндә барлыкка килсен иде», – дигән фикер тудыруы.

Кешеләрдә еш очрый торган әлеге сыйфат турында галимнәр: «Бу – куркыныч чир», – дип әйтәләр. Бик сирәк кеше генә бу чирдән котыла ала. Чөнки адәм баласы табигате белән өстен булырга яратучы. Ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан шулай яратылган. Күпләр бу авыру белән көрәшеп, аны җиңә ала, ә кемдер көрәшми дә, теләми дә.

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә: «Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән утырган вакытта әйтте:

«Хәзер шул ишектән сезнең яныгызга җәннәт белән шатландырылган бер кеше керер».

Әнәс бине Мәлик дәвам итә: «Дөрестән дә яныбызга әнсарлардан бер кеше керде һәм шул хәл өч көн дәвамында кабатланды. Шуннан соң мин аңа ияреп, өч көн аның белән булдым, әмма безнең гамәлләрдән аерылып торган бер артык гыйбадәтен күрмәдем.

Өч көн узгач, үзенә булган хәлләрне сөйләп бирдем. Ул мине чакырып, болай дип әйтте:

«Миндә башка мөселманнарга карата бернинди ачу һәм Аллаһы биргән нәрсәләргә көнчелегем юк».

Шуңа күрә мөхтәрәм мөселманнар, көнчелек ул кешенең көчсезлегеннән килгән сыйфат. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дә аннан котыла торган юллар күрсәтте:

1. Истигазә сүрәсен уку («Фәләкъ» сүрәсе).

2. Тәкъва булып калу. Тәкъва кеше башка кешеләргә карата көнчелек, күрә алмау хисе сакламый һәм аларның кайгы-хәсрәтләренә дә шатланмый.

3. Яратмаган кешеләргә сабыр итү, алар белән әрләшмәү, алар өстеннән зарланмау һәм аларга зыян китерә торган сүзләр әйтмәү.

4. Аллаһыга тәвәккәл итү. Бу сыйфат иң көчлесе булып тора, чөнки Аллаһыга тәвәккәл итү – Аллаһы язганы белән разый булып калу, начары да яхшысы да Аннан дип тану. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

مَا أَصَابَ مِن مُّصِيبَةٍ إِلَّا بِإِذْنِ اللَّهِ وَمَن يُؤْمِن بِاللَّهِ يَهْدِ قَلْبَهُ
وَاللَّهُ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ ﴿١١﴾

**«Кайгы бәла-каза Аллаһының теләге белән генә ирешә. Берәү итагать иткән хәлдә Аллаһыга иман китерсә, Аллаһы ул кешенең күңелен хаклыкка күндерер. Аллаһы һәрнәрсәне Белүче».**

«Тәгабүн / Алдану», 64:11

5. Күңелгә начар фикер кертмәү, аның турында уйламау.

6. Гөнаһлы фикер килгәндә тиз арада тәүбә итү. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمَا أَصَابَكُم مِّن مُّصِيبَةٍ فَبِمَا كَسَبَتْ أَيْدِيكُمْ وَيَعْفُو عَن كَثِيرٍ

**«Ий мөэминнәр сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар, үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпледер, шулай булса да Аллаһы гөнаһларыгызның күбрәген гафу итәдер».**

«Шура / Киңәш», 42: 30

7. Хәлдән килгәнче садака бирү һәм изгелек кылу. Дөреслектә аның тәэсире бик гаҗәеп һәм ул бәла-казалардан һәм көнчелектән саклый.

8. Көнчелекле, яман, рәнҗетүче кешеләргә яхшылык күрсәтү. Әлбәттә, бу иң авыры. Начарлык күбрәк күрсәткән саен, күбрәк яхшылыклы булу. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلَا تَسْتَوِي الْحَسَنَةُ وَلَا السَّيِّئَةُ ادْفَعْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ فَإِذَا الَّذِي بَيْنَكَ وَبَيْنَهُ عَدَاوَةٌ كَأَنَّهُ وَلِيٌّ حَمِيمٌ (٣٤) وَمَا يُلَقَّاهَا إِلَّا الَّذِينَ صَبَرُوا وَمَا يُلَقَّاهَا إِلَّا ذُو حَظٍّ عَظِيمٍ (٣٥) وَإِمَّا يَنْزَغَنَّكَ مِنَ الشَّيْطَانِ نَزْغٌ فَاسْتَعِذْ بِاللَّهِ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

**«Яхшылык белән явызлык бертигез булмаслар, чөнки яхшылыкка файда һәм савап бар, явызлыкка зарар һәм газап бар. Әгәр сиңа берәү явызлык кылса, син аңа җавап итеп яхшылык кыл, ул кеше сиңа явызлыкны дошманлык илә кыладыр, әмма син сабыр ит һәм дә аның явызлыгына каршы һәрвакыт изгелек ит, соңра ул синдә явызлыкның юклыгын белеп, явызлык итүеннән туктар һәм тәүбә итеп синнән гафу сорар, аннары бер-берегезгә якын дус булырсыз. Ләкин бу эшне һәр кеше эшли алмас, мәгәр көчле иманлы, чын сабыр мөэминнәр генә эшли алырлар, вә явызлыкка каршы изгелек итү һәрбер кешегә бирелмәс, мәгәр олуг бәхетле кешегә генә бирелер. Әгәр явызлык итүчегә изгелек итәргә шәйтан сиңа ирек бирмәсә, шәйтанның шәреннән Аллаһыга сыгын, Ул сине шәйтан вәсвәсәсеннән саклар, анна-**

**ры явызлыкка каршы изгелек итә алырсың. Аллаһы Ишетүче вә Белүчедер».**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:34-36

9. Көнчелеккә китерә торган нигъмәтләрне яшерү. Аллаһы Ягъкуб гәләйһиссәлам турында болай дип әйтте:

وَقَالَ يَا بَنِيَّ لَا تَدْخُلُوا مِنْ بَابٍ وَاحِدٍ وَادْخُلُوا مِنْ أَبْوَابٍ مُتَفَرِّقَةٍ وَمَا أُغْنِي عَنْكُمْ مِنَ اللَّهِ مِنْ شَيْءٍ إِنِ الْحُكْمُ إِلَّا لِلَّهِ عَلَيْهِ تَوَكَّلْتُ وَعَلَيْهِ فَلْيَتَوَكَّلِ الْمُتَوَكِّلُونَ

**«(Аларның) аталары әйтте: «Ий угылларым, Мисырга җиткәч барыгыз да бер капкадан кермәгез, төрлегез төрле капкалардан керегез! (Бөтенегезне бергә күреп, сезгә күз тидермәсеннәр) Аллаһыдан килгән бәла-каза хакында берни белергә дә, сезгә ярдәм итәргә дә хәлемнән килмидер, һәр эш өстеннән хөкем йөртүче Аллаһыга хастыр, шуңа баш июдән башка чара юк, мин Аллаһыга тәвәккәл иттем һәм тәвәккәл итүчеләр Аллаһыга гына тәвәккәл итсеннәр!»**

«Йосыф», 12:67

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйтә:

«Үзегезнең эшләрегездә уңышлы булыр өчен яшерү белән ярдәм сорагыз, дөреслектә нигъмәт ияләренә көнчелек тиядер».

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Илмир хәзрәт Хәсәнов,*

*Буа районы имам-мөхтәсибе, Буа мәдрәсәсе мөдире*

*7 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Дусларны сайлау

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәналәрбез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифәләрен бирсә иде.

Без, җәмгыятьтән аерылып, бу дөньяда үзебез генә, кешеләр белән аралашмыйча гына яши алмыйбыз, Аллаһы Тәгалә безне шулай яраткан. Динебез дә бер-беребез белән аралашып, ярдәмләшеп яшәргә чакыра. Бу хакта безгә сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә искәртә:

«Кешеләр белән аралашып һәм аларның зыян салуларына сабыр итеп яшәүче мөэмин-мөселман, кешеләр белән аралашмыйча һәм аларның зыян салуларына сабыр итмичә яшәүче мөэмин-мөселманга караганда олуг әҗерләргә лаеклырак»[1].

Әйе, җәмгыятьтә төрле холыклы кешеләр бар, алар сиңа гел елмаеп, матур, йомшак сүзләр әйтеп кенә тормыйлар, ә кайвакыт үзләрен бик дорфа тотарга да, хәтта сиңа начар сүзләр әйтергә дә мөмкиннәр. Әмма без хәдистә әйтелгән сүзләрне искә тотарга тиешбез: «Аларның зыян салуларына сабыр итеп яшәүче мөэмин-мөселман олуг әҗерләргә лаек».

Ә ни өчен андый мөэмин-мөселман кешесе хәерлерәк, олуг әҗерләргә лаек соң? Галимнәр аңлатуынча, мөселман кешесе, аралашып яшәве сәбәпле, кешелек дөньясына күбрәк файда китерә ала. Җәмгыятьтә берәр начарлык, бозык гамәл тарала башлый икән, ул мөмкинлегеннән чыгып, бу гөнаһны туктатырга омтыла: күркәм вәгазь белән нәсыйхәт кыла

[1] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

ала яки көченнән килә икән, кулы белән туктата. Шул сәбәпле күпмедер кеше бу гөнаһны кылудан тыелып кала. Яки инде киресенчә, кешеләрдә гафиллек күренсә, мөселман аларны нинди дә булса файдалы, игелекле гамәлләргә чакыра ала. Менә шул рәвешле, ул җәмгыятьнең бер өлешенә әверелә. Ә үз эченә бикләнеп, беркем белән дә аралашмыйча яткан кеше җәмгыять тормышына нинди файда китерә алсын?! Ул бикләнеп ятуы сәбәпле андагы проблемаларны да белми, күрми бит.

Җәмгыятьтәге мөшкел-мәшәкатьләрне хәл итү һәм, гомумән, тормышта үз урыныңны табу, нindидер бер өлкәдә уңышка ирешү өчен дә, безгә ярдәм кулы сузып, авыр вакытта терәк була алырдай, белмәгәнне аңлатырдай, кирәк чакта киңәш сорардай ышанычлы дуслар кирәк. Бергә булганда сынауларны җиңеп чыгуы җиңелрәк. «Дуссыз башым, тозсыз ашым» дигәндәй, дусларсыз тормыш та ямьле булмый. Безнең динебездә дә дуслык төшенчәсенә зур урын билгеләнгән, дуслык, кардәшлек олуг дәрәҗәгә ия. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ إِخْوَةٌ فَأَصْلِحُوا بَيْنَ أَخَوَيْكُمْ ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿١٠﴾

**«Дөреслектә, мөэминнәр – кардәшләрдер. Кардәшләрегезнең арасын килештерегез һәм Аллаһыдан куркыгыз, Аның рәхмәтләренә ирешерсез».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:10

Аллаһы Тәгалә мөэмин-мөселманнарны, хәтта, дуслар дип кенә түгел, ә кардәшләр дип атый. Бу нәрсә дигән сүз соң? Кардәшлек ул – үзара мөнәсәбәтләрне туганлык дәрәҗәсенә күтәрү. Әйе, без мөэмин-мөселман кардәшләребезне туганнар кебек хөрмәт итәргә, үзебезгә теләгән яхшылыкларны аларга да теләргә тиешбез. Бу хакта безгә яраткан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәтеп калдырган:

«Үзенә теләгәнне кардәшенә теләми торып, берегез дә иманлы булмас»[1].

Әйе, дусларны кардәшлек дәрәҗәсенә күтәреп, кардәшләребезгә дә үзебез яраткан нәрсәләрне теләргә тиешбез. Арабызга, берүк, кара көнчелек кермәсен. Бу инде кардәшлекне җимерә торган куркыныч чирләрнең берсе булып тора. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кардәшлек җепләрен бер бина белән чагыштырган: «Дөреслектә, мөэминнәр, бер бинаның өлешләре кебек, бер-берсен ныгытып, куәтләп торалар»[2]. Әмма туганыңдай якын, үзенә теләгәнне сиңа да теләүче, авыр чакта акыллы киңәшләр бирүче, ярдәм итеп торучы кардәшләрне табуы, кызганыч, бик авыр. Чөнки кардәш дигәнең дә, безнең үзебез кебек үк, кимчелеге булган кеше. Күбебезнең ишеткәне дә, күргәне дә бардыр: хәтта кардәшләр арасында да алдалаучылар да, сүзендә тормаучы, әманәтенә хыянәт итүчеләр дә, хәтта зур гөнаһларга җиңел караучылар да юк түгел. Шуңа күрә үзебезгә дус-ишне сайлаганда иманыбызга, тәкъвалыгыбызга зыян китерми торганнарын сайларга тиешбез. Бу мәсьәләдә зирәк булып, кеше кыяфәтле шәйтан дуслардан ерак торырга кирәк. Үзебезгә дуслар сайлаганда да кардәшләрнең түбәндәге сыйфатларга ия булганнарын сайлау зарур:

– алар сиңа Аллаһының ризалыгына ирешергә ярдәм итә;

– тәкъвалыкны арттыруга сәбәп була;

– җәннәткә керергә булыша;

– ялгышкан вакытларыңда сине гафу итеп, туры юлга юнәлтә;

– гафиллеккә чума башласаң, бу хакта сиңа искәртеп, изгелеккә өнди башлый;

– ярдәм сорап килгәндә ярдәм кулын суза.

1 Имам Бохари риваяте.

2 Имам Бохари риваяте.

Әмма тагын да мөһимрәк сыйфат шул: Аллаһыга иман китереп, гөнаһлардан тыелып, изге гамәлләр кылып яшәргә тырышу. Әнә шундый тугры кардәшләр белән бергә булырга кирәк. Раббыбыз Аллаһы Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَكُونُوا مَعَ الصَّادِقِينَ ﴿١١٩﴾

**«Ий, иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм тугры кешеләр белән бергә булыгыз!»**

«Тәүбә», 9: 119

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә дуслар сайлаганда игътибарлы булырга өндәгән, дустың нинди булса, син дә шундый буласың, дип искәрткән: «Кеше үз дустының динендә булыр, шуңа да ул үзе кемнәр белән дус булуына игътибар итсен!»[1]

Кардәшләрең әдәпле булсалар, син дә алардан үрнәк алып, аларның күркәм холыкларындагы яхшы сыйфатларны үзеңдә булдыра башлыйсың. Кардәшләрең тәкъвалы булсалар, син дә алар кебек тәкъвалыкны арттыру өстендә эшли башлыйсың. Кардәшләреңнең намазларын үз вакытында укуларын күрәсең икән, син дә алардан калышмыйм дип намазыңны вакытында укып барырга тырышасың. Дус – дусның көзгесе, шуңа күрә безгә яхшы кардәшләр белән генә аралашу зарур. Бу фикерне ныгыту өчен тагын бер дәлил китерәм. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кеше кемне сөйсә, шуның белән бергә булыр»[2].

Ягъни, әгәр берәүнең холык-табигатен беләсегез килсә, шул кешенең дустына карагыз, чөнки алар икесе дә бер холыкта булырлар, дигән сүз бу. Әгәр шулай булмаса, димәк, аларның дуслыклары чын түгел. Безнең халыкта бер мәкаль бар: «Кешенең кем икәнен беләсең килсә, төсенә карама, дустына кара».

1 Имам Әт-Тирмизи риваяте.

2 Имам Бохари риваяте.

Икенче бер хәдисендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм акыллы дусның синдә яхшы эз калдыруы, ә начар дусның тискәре йогынтысы булып, сиңа барыбер зыяны тиячәге хакында әйтә: «Гадел, яхшы дус – ислемай сатучыга, ә начар иптәш – тимерче күреген өрдерүчегә тиң. Ислемай сатучы янында булсаң, син аннан ислемай сатып алачаксың, яки бер дә булмаса, сиңа аннан килгән хуш ис сеңәчәк. Күрек өрдерүчегә килгәндә исә, ул яки синең киемеңне яндырачак, яки син аннан үзеңә яман ис ияртеп чыгачаксың»[1].

Әгәр Ризаэтдин бине Фәхреддин хәзрәтләренең хезмәтләренә күз салсак, аларда да дуслар турында файдалы киңәшләр табарга мөмкин.

«Дусларыгызны яхшы кешеләр арасыннан сайлагыз. Дине бөтен һәм акылы камил, фикере туры булган әдәпле кешеләрне табыгыз. Мондый кешеләр авыру вакытыгызда – дәва, сәламәт вакытыгызда – зиннәт, мәшәкатьләрегездә – таяныч, боек сәгатьләрегездә – күңелләрне күтәрүче, сәфәргә киткән вакытыгызда догачыгыз булырлар. Байлыкка ирешүләре белән сездән киселмәсләр, ә сез тарлыкка төшсәгез, ярдәмнәреннән ташламаслар. Дуслыклары сүзләреннән артык эшләрендә күренер. Әгәр шундый дусларыгыз булса, аларга нык ябышыгыз, үзегездә зарланырлык кимчелекләр булдырмагыз. Дусларыгызны чын күңелдән сөегез, арагызны үлемнән башка нәрсә аермасын. Дустанә мөгамәлә кылучыларның барысы белән дә дус булырга ашыкмагыз, ә үзегез яратмаган кешеләрнең барысын да дошман күрмәгез. Телләре белән генә вәгъдәле, ихлас күңелле булучылар белән, сынамастан элек, ышанып, дус булмагыз. Тел күп вакытта ялган сөйли, ихтимал, бу кешеләр теләкләренә ирешер өчен генә шулай сөйлиләр, теләкләренә ирешкәч үзгәрәләр. Бозык кешеләр белән аралашмагыз, алар юлына кермәгез. Алар бозыклык кылу һәм кешеләрне һәлакәткә төшерүдән үзләренә ләззәт табалар. Адәм баласы ашап-эчмичә тора алмаган кебек, бозык кешеләр дә уссалык итмичә тора алмыйлар. Шуның өчен яхшылар юлына керегез, алар

---

[1] Имам Бохари риваяте.

белән дус булыгыз», – дип язып калдырган Ризаэтдин хәзрәтләре. Шунысын да әйтү тиешле: янында әйбәт кардәшләр булсын өчен үзеңә дә яхшы дус була белергә кирәк. Үзеңә карата нинди мөгамәләдә булуларын теләсәң, дусларыңа карата да шундый ук мөгамәлә кыл! Бу – әдәп-әхлакның алтын кагыйдәсе. Әгәр син дусларыңның алдамауларын теләсәң, син дә аларны алдама. Әгәр сине рәнҗетүләрен теләмәсәң, син дә аларны рәнҗетмә. Начар, бозык сүзләр әйтүләрен теләмәсәң, син дә начар сүзләр әйтмә. Сиңа карата дорфалык күрсәтүләрен теләмәсәң, үзең дорфа булма. Сиңа елмаюларын теләсәң, үзең беренче елмай. Без күп вакыт безгә дуслар-кардәшләр генә тиеш, дип уйлыйбыз. Беренче чиратта үзең яхшы дус булмый торып, сиңа ничек яхшы дуслар тартылсын соң?! Бу хакта фикерләсәк, уйлансак һәм, әлбәттә, чын дусларга хас сыйфатларны үзебездә тәрбияләсәк, төзәлсәк иде. Язмамны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кардәшлекне ныгыта, дусларны бер-берләренә якынайта торган киңәшләрен үз эченә алган хәдисе белән тәмамлыйсы килә: «Көнләшмәгез, бәяләрне арттырмагыз, үзара нәфрәттән баш тартыгыз, бер-берегезгә аркаларыгыз белән борылмагыз, бер-берегезнең сәүдәсен бозмагыз һәм, бер-берегезгә кардәшләр булган хәлдә, Аллаһының коллары булыгыз. Мөселман – мөселманга кардәш. Ул аны рәнҗетергә, алдарга һәм хурларга тиеш түгел»[1].

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Раил хәзрәт Фәйзрахманов,*

*Балык Бистәсе районының Тәберде Чаллы авылы мәчете мөгаллиме*

1 Имам Мөслим риваяте.

*14 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Хайваннарга карата мөнәсәбәт

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәналәрбез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифәләрен бирсә иде.

Адәм балаларына җирләрдән вә күкләрдән файдаланыр өчен барлык мөмкинлекне биргән, галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә мактау-сәналәребез булса иде. Рәхмәт өчен җибәрелгән, күркәм нәсыйхәтләрен әйтеп калдырган Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи вә сәлләмгә нур өстенә нур булып торган салаватларыбыз, сәламнәребез вә догаларыбыз ирешсә иде. Мөбарәк булган җомга көнебез котлы булсын, мөхтәрәм дин кардәшләрем. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Шәддәд бине Әнәс радыяллаһу ганһе риваять кылуы буенча, Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Аллаһы бөтен эштә дә мәрхәмәтлелек (ихсан) күрсәтергә боерган. Шуңа күрә, сезгә хайванны чалырга туры килсә, яхшы ысул белән чалыгыз. Хайванны азапламас өчен һәрберегез үзенең пычагын яхшы итеп үткенләсен».

«Ихсан» ике төрле була. Гыйбадәттәге «ихсан» – ягъни Аллаһыны күргән кебек итеп Аңа гыйбадәт кылу. Чөнки син Аны күрмәсәң дә, Ул сине күрә. Бу эчкерсез һәм тулысынча Аллаһы Раббыбызның кушканнарын үтәп, тыйганыннан тыелып яшәү дигән сүз. Һәм шулай ук «ихсан» төшенчәсе – барлык тере мәхлүкъларга карата да кулланырга була. Ата-анага карата мәрхәмәтле һәм ихтирамлы булу. Кардәшләр белән

элемтәләрне саклау, кешеләргә карата гадел булу. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا ﴿٣٦﴾

**«Аллаһының Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз. Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары ата-анага изгелек итегез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган күршеләргә һәм кардәш булмаган күршеләргә дә изгелек итегез. Шулай ук сәфәрдә ят юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһы, әлбәттә, сөйми!»**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Шулай итеп, Раббуль Гыйззә әлеге аятьтә әйтелгән һәрбер кешегә карата да изгелек кылырга кушкан. Бу боерык бөтен мәхлүкъларга һәм шул исәптән хайваннарга да мәрхәмәтле булу дигән сүз.

Кызганычка, җәмәгать, андый мөнәсәбәт хәзерге вакытта күрсәтелми. Хәтта кешеләр үзләре үк дәрәҗәләрен төшерәләр. Ник дисәгез, мисал өчен карыйк әле: Аллаһы Тәгалә мәрхәмәтле, олы йөрәкле, нечкә күңелле итеп яраткан затлар – хатын-кызлар үзләре үк гомер биргән нарасыйларыннан үз теләкләре белән котылалар. Ә ир-атлар нишли, бернәрсә булмаган кебек, тормышын дәвам итәләр. Ә бит Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә түбәндәге аятьтә болай дип әйткән:

ثُمَّ رَدَدْنَاهُ أَسْفَلَ سَافِلِينَ ﴿٥﴾

**«Соңра ул итагатьсез кире кешене, Ахирәттә түбәннәрнең түбәненә кайтардык, ягъни җәһәннәмгә».**

«Тин / Инҗир», 95:5

Түбәннәрнең түбәненә кайтарылачак кешеләрне белеп, алар җөмләсеннән булудан Аллаһы Үзе сакласын! Алар кяферләр, мөшрикләр, хаксыз золым итүче залимнәр, бозык вә пычрак эшне эшләүче фасикълар, риячылар, сихерчеләр, багучылар, бидгатьчеләр, мал җыючы бик саран байлар, ышанып та дин тотмаучылар, тәкәбберләр, хәмер эчүчеләр, зина кылучылар, хаксыз кеше үтерүчеләр, шул исәптән хайваннарга да карата мәрхәмәтсез булучылар – гомумән Коръән белән гамәл кылмаучылар: куәтле вакытларында тәүбә итеп, Коръән белән гамәл кылып төзәлмәсәләр – һәммәсе дә җәһәннәмгә керәчәкләр.

Шулай ук, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи сәлләмнән үрнәк алырга була. Йортында яшәгән песигә карата мөнәсәбәтен карыйк. Чапанының читендә ятып торган песине, йокысыннан уятмаска тырышып борчымыйча, чапанын кисеп калдыра. Безнең өчен нинди күркәм гамәл, гыйбрәт. Бу кыйссада Расүлебезне хайванга карата күркәм мөнәсәбәте сурәтләнә.

Әлеге кыйссаның тагын бер гыйбрәтен искә төшермичә булмый. Хайваннарга ярдәм итү адәм баласын җәннәтле дә итәргә мөмкин. Шушы сүзне әйткәндә, Гомәр радыяллаһу ганһе тормышында булган кыйсса да искә төшә.

Гомәр радыяллаһу ганһе икенче хәлифә иде. Кичләрен гыйбадәттә, көндезләрен күп вакытта уразада, мөмкинлеге булганда Коръән укып уздырган, гаделлек белән хөкем иткән шушы диндар, тәкъва бәндә үлеп киткәннән соң, берничә кеше аны бер үк хәлдә төштә күрәләр. Күргән кешеләр төшләрендә: «Әй Гомәр радыяллаһу ганһе, тугры хәлифәбез, син намаз укый идең, һәр көнне диярлек уразалар тота идең, күп гыйбадәтләр,

изгелекләр эшли идең. Шушы изгелекләрең арасыннан Аллаһы Тәгалә кайсысын аерым бәяләде һәм гамәлләрең арасында нинди гамәлең сине җәннәтле итте», – дип сорадылар. «Әйе, намазлар, уразалар, изге гамәлләрем күп иде. Әмма бөтен гамәлләрем арасында мине җәннәтле иткән бер хәл булган. Дөньяда яшәгән вакытымда кулына кош тоткан бер сабый баланы күргән идем. Әлеге кошны баладан сатып алдым һәм азат иттем. Менә шушы гамәлем өчен Аллаһы Тәгалә мине җәннәтле итте», – дип сөйләгән булган Гомәр радыяллаһу ганһе.

Әйе, бу кыйссаны тыңлаган вакытта намаз укымаган кешеләр үзенчә бер нәтиҗә дә ясарга яраталар. Ягъни, кара әле, намаз укымасаң, ураза тотмасаң, хайваннарга ярдәм итеп кенә дә җәннәткә кереп була икән дип уйлап хаталы булалар. Намазның, уразаның фарыз икәнлеген белгән хәлдә аларны үтәмичә, этләргә, мәчеләргә ярдәм итү белән генә гомерне чикләү дөрес булмас. Булдыра алган хәлдә нинди генә саваплы, әҗерле, изге гамәл очраса, аларның барысын да эшләргә омтылырга тиешбез.

Тагын бер кыйсса искә төшә. Сөләйман галәйһиссәлам янына ике ана болан килә икән. Бер болан баласын, «минем балам», дип тартышалар. Шул вакытта, Сөләйман пәйгамбәр гаделлеген күрсәтә: «Әгәр дә шул болан баласы синеке дә һәм синеке дә икән. Әйдәгез икегә бүлеп, яртылаш гәүдәсен алырсыз», – дип фәтвасын бирә. Мондый хөкемне ишеткәч, бер ана болан ризалаша: «Әйе, хак хөкем», – дип әйтә. Ә инде икенче ана болан баш тарта: «Аллаһы хакы өчен, бүлә күрмәгез. Бу болан баласы аныкы булсын», – дип елап җибәрә. Шунда Сөләйман пәйгамбәр галәйһиссәлам чын ананың кайсы икәнен белә. Шулай ук безнең өчен гыйбрәт.

Тик ни кызганыч, бүгенге көндә күбесенчә «ана» дигән исемен алган кыз-хатыннар, үзләренең балаларын да язмыш кочагында калдыралар, ташлыйлар.

Кадерле дин кардәшләрем, мәрхәмәтлелекне, ихсанлылыкны ешрак куллансак иде.

Бу гыйбрәтле кыйссаны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе сөйли. «Бер юлчы сусыз кала һәм аның бик нык су эчәсе килә. Тегендә-монда бәргәләнеп, су эзли башлый. Йөри торгач, ташландык бер кое табып ала. Әлеге коега төшә һәм су эчә. Коедан чыгып юлын дәвам итә торгач, юл өстендә шулай ук сусаудан хәлсезләнеп аяктан егылган, телен асылындырган, авырлык белән генә сулап ята торган бер этне күрә. Кара әле, бу эт тә минем кебек сусау хисе белән яна бит, дип, әлеге этне бик җәлли. Кирәдән кое янына бара. Тирән генә булган бу коега төшә. Читегенә су тутырып, коедан чыга. Барып, шушы эткә су эчерә. Әлеге гамәле өчен Аллаһы Тәгалә аның бөтен гөнаһларын гафу итә һәм җәннәте белән бүләкли».

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, бервакытны Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм ашап утырганда, янына песи килеп утыра. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзе эчә торган савытыннан шул хайванны авыз иттерә. Шул хәлне күргән Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә: «Нишләвең бу? Эчә торган суыңны аңа эчертәсең. Пычрак хайван бит ул», – дигәч, Аллаһының Илчесе: «Ул киресенчә пакь, җәннәт хайваны», – дип җавап кайтара һәм савытындагы калган суы белән тәһарәт ала.

Расүлебез галәйһиссәлам шулай ук бер хәдисендә: «Бер хатын газапларга дучар була. Чөнки ул песине үлгәнчегә кадәр бикләп тоткан була. Һәм шул хайванны ашатмаган, эчертмәгән өчен ул хатын җәһәннәмле булды», – дип әйткән.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Корбан чалганда да хайваннарга карата мәрхәмәтле булыйк. Аны чалыр алдыннан, куркытмыйча, җәберләмичә, йомшак кына, җайлап кына чала торган урынга алып килергә. Аннан соң чалыначак корбан янында ниятеңне әйтеп, «Бисмилләһи! Аллаһу әкбәр!» – дип, яхшы кайралган пычак белән хайванны чалырга кирәк. Ә инде хайванны чалыр алдыннан, корбанлыкның иясе яки суючы хайванга карап, түбәндәге доганы укый:

**«Әллааһүммә иннә саләәтии үә нүсүкии үә мәхйәәйә үә мәмәәтии лилләәһи раббил-гәәләминә ләә шәриикә ләһ. Әллааһүммә тәкаббәл һәәзиһил-удхийййәтә (мин фүләәни ибни фүләән) йәки (мин фүләәнәтә бинти фүләән)».**

**Мәгънәсе:** «Йә Рабби, дөреслектә, минем намазым һәм гыйбадәтләрем, тереклегем һәм үлемем барча галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһы Тәгалә өчен, Аның һичбер тиңдәше юк. Йә Рабби, ошбу корбанны фәлән-фәлән улыннан яки фәлән-фәлән кызыннан кабул ит».

Җәмәгатем мөслимүн! Аллаһы Раббыбызның биргән нигъмәтләренә шөкраналар кылып, бер-беребезгә, ятимнәргә, мохтаҗларга, хәтта безнең дүрт аяклы дусларыбызга да карата мөнәсәбәтне, ихласлылык белән гаделлек күрсәтеп, мөселманча, Аллаһы Тәгалә кушканча яшәргә насыйп әйләсен иде. Һәм дә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үрнәге белән кулланырга насыйп әйләсен. Әәмин! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Фәнис хәзрәт Низамов,*

*Аксубай районы, Яңа Дума авылы имам-хатыйбы*

*21 февраль вәгазе,*

*Җөмәдәл-ахыр аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Рәгаиб кичәсе

Мактау вә дан галәмнәрнең Раббысы, Рахмән, Рахим вә Кыямәт көненең Хуҗасы булган Аллаһыга хастыр. Тик Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, тик Синнән генә ярдәм көтәбез. Безне тугры юлга, Үзең нигъмәтләндергән кешеләрнең юлына күндер. Газапка дучар булганнар, адашканнарның юлыннан читләт.

Бу айның беренче җомгасы – Рәгаиб кичәсе көне – җомга алдындагы кичтән башлана, ягъни пәнҗешәмбегә туры килә. Ислам динендә кичә көндездән алда бара, чөнки кояш баеганнан соң икенче көн башлана. Нинди көн соң ул Рәгаиб кичәсе? Бу – Пәйгамбәребезнең әтисе Габдулла белән әнисе Вәһаб кызы Әминәнең никахлашкан көннәре.

Ни өчен без Рәгаиб кичәсен билгеләп үтәбез? Чөнки шушы никах нәтиҗәсендә дөньяга рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам дөньяга килгән.

Хәзрәти Габдулладан да, хәзрәти Әминәдән дә алтыннар, байлыклар калмаган. Аларның никахыннан дөньяга бер изге бала туган. Бөтен никахларның максаты, нәтиҗәсе – бала. Әгәр без үзебездән соң холык ягыннан да, әхлак ягыннан да – бөтен яктан үзебезгә караганда яхшырак балалар калдырабыз икән, димәк, безнең гомеребез заяга үтмәгән, димәк, без Аллаһы Тәгалә каршысында бурычыбызны үтәгәнбез дигән сүз. Пәйгамбәребезнең әтисе – улы туганчы, әнисе – улына алты яшь вакытта вафат булалар. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм ятим кала. Әмма хәзрәти Габдулла белән хәзрәти Әминәнең саф җаннар, изге күңелле кешеләр, харамга катышмаган яхшы кешеләр булганы өчен, Аллаһы Тәгалә изге бала биреп дөньяны сөендерә.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең әйткән сүзе бар: «Аллаһыны танымаган, харам белән хәләлне аермаган, изге гамәлләр кылмаган кешегә Аллаһының беренче җәзасы – дөньяда юлдан язган бала булыр. Ата-ананың төрле юллар белән тырышып-тырмашып җыйган байлыгын туздырыр өчен, картлык көнендә бөтен тынычлыгын алыр өчен шушы бер бала җитә, шушыннан артык бернәрсә дә кирәк түгел».

«Хатыннар өстендә булган хакларның иң зурысы – ир хакы, ирләр һәм хатыннар өстендә булган хакларның иң зурысы – ана хакыдыр»[1].

Бу хәдистә хатыннар өстендә булган ирләр хакы һәм ирләр һәм хатыннар өстендәге аналар хакы бәян ителгән булса да, ирләр өстендә хатыннарның да, аналар һәм аталар өстендә балаларның да хаклары бар һәм алар күп. Аларны яхшылап белү һәм шул белгәннәр белән гамәл кылу, белер өчен уку, сорап булса да өйрәнү тиешле. Милләтләрнең иҗтимагый камилләшүләре гаиләләрдәге шәхесләр арасындагы бердәмлек һәм өлфәт-мәхәббәткә бәйле булганлыктан, өйләнүнең табигый булуы һәм аннан соң шәхесләрнең үзара хакларының тиешле дәрәҗәдә үтәлүе лязем. Гадәттә, өйләнешү ир белән хатынның яшь һәм әхлакта, гыйлем һәм табигать кебек эшләрдә бер-берсенә туры килүләреннән гыйбарәт. Бу нәрсәләргә игътибар бирелмәгән никахларда ир хакы да, хатын хакы да үтәлми, бәлки күп вакытта хәерсез эшләргә сәбәп була. Әгәр без, Аллаһыны танымыйча, теләсә нәрсә эшләп йөрсәк, безгә Аллаһы Тәгалә игелексез бала бирүе бар. Безгә җәза бу һәм инде, киресенчә, харамга катышмыйча, изге гамәлләр кылып, тормышның авырлыкларына сабыр итеп, үзебезне кешечә тотсак, хайван дәрәҗәсенә төшмәсәк, безгә Аллаһы Тәгалә бүләк итеп изге, миһербанлы бала бирер.

Рәгаиб кичәсе башлангач, моны без: гаилә кичәсе, гаилә көне, дибез. Раҗәб аенда ураза тоту бик саваплы гамәл. Кемнең көче, ихтыяры җитә – уразага керик. Кояш баешка хәләл ризыклар белән табыннар әзерлик.

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Гаилә белән шундый табыннар янында бергәләшеп сөйләшеп утырыйк. Бер-беребезгә изге теләкләр телик, бүләкләр бирешик. Кемнәрдер әти-әни булырга җыена – шушы көнне садакалар биреп, изге гамәлләр кылып, үзләренә Аллаһы Тәгаләдән изге бала сорасыннар. Баласы булганнар үзләренең балаларына тәүфыйк-һидаять бирүне үтенсеннәр. Ир белән хатын никахларына тугрылык сорасыннар. Ир – хатынына, хатын иренә бүләк биреп, матур-күркәм сүзләр әйтеп, шушы көнне үзләренең никахларын ныгытсыннар.

Кияүгә чыкмаган, өйләнмәгән егет-кызлар бу кичәдә Аллаһы Тәгаләдән бер-берсенә тиң ярларны сорасыннар. Карт-карчыклар бу кичәдә Аллаһы Тәгаләдән тигез гомер, бергә-бергә, таза-сау, тигез яшәүләрен үтенсеннәр. Раҗәб аенда Аллаһының рәхмәте яңгыр шикелле явар, диелгән. Менә шушы рәхмәт аенда, бигрәк тә җомга көнендә, үзебезнең мөселман икәнебезне тоеп, бәйрәмне зурлап, Аллаһы Тәгаләгә муафыйк эшләп кылып, хәерле теләкләрне телик. Үзебез өчен дә, балаларыбыз һәм киләчәк буын өчен дә догада булыйк. Гаилә ничек яши, никахның ныклыгы нинди – киләчәгебез шундый. Никахларыбыз төзек булмаса, аны игътибарга алмыйча яшәсәк, без хайван шикелле гомер иткән булабыз һәм үзебездән соң да юньле буын калдыра алмабыз. Балаларыбызның үзебездән начар булуы ихтимал. Әмма начар холыклы әти-әнинең дә баласы, әти-әнисенең хаталарыннан азат булып, яхшы бала булып үсәргә мөмкин. Әти-әнинең бурычы – тәрбияле бала үстерү.

Аллаһы Тәгалә каршысында никах иң күркәм, иң саваплы, иң кирәкле гамәл. Бу уңайдан, бер нәрсәне әйтеп китәсе килә: никахны кайчан укырга ярый, ә кайчан ярамый? Хәзер газеталарны укыйсың да, аптырап каласың – монысына йолдызнамә туры килми, монысының ае, көне башка, аларга, имеш, никахны бүтән вакытта укырга кирәк, хәзер һич очына барып җитәрлек түгел.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Сафәр аенда начар билгеләр юк, әйберләрдә шомланулар юк», – диде. Бернинди ырым да булырга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә каршысында никах күркәм эш булгач, һич тә аптырап тормаска кирәк. Яхшы эшне эшләр өчен без берәр вакытны сайлыйбызмы? Юк. Изге эш эшләргә ярамаган көн бармы? Юк. Шуңа күрә никах укырга ярамаган көн дә, сәгать тә юк. Бөтенесе урынсыз шомлану, урынсыз ырым. 3-4 елга бер тапкыр гает белән җомга көне бергә туры килә. Менә шушы вакытта гает вакыты чыкканнан соң, җомга укыганчыга кадәр никах укымый торырга кирәк, дигән фикер бар. Бу, җәмәгать, вакыт тыгыз булудан гына, һич тә дөрес фикер түгел. Никах бу вакытта укыла. Тагын бер нәрсә бар: ураза аенда никах укылмыйча тора. Бу – яшьләрнең уразасына авырлык килмәсен өчен. Җир йөзендәге миллиардлаган мөселманнар ураза тотып, намаз укып яши. Алар никахланганнан соң да ураз тотарга тиешләр. Яшьләрнең уразаларына авырлык килмәсен дип кенә, Рамазан аенда никах укылмыйча тора. Әмма бу айда, мәсәлән, ураза вакытында никах укыла, ә авыз ачылганнан соң никах мәҗлесе ясалса. Рамазанда никах укырга ярамый дигән фикер дөрес түгел.

Әмма иң борчыганы, иң әрнеткәне – никах мәҗлесен харам туйга – хәмер туена әйләндерү. Бер генә гаилә нигезен дә аракы ныгытканы юк. Бер генә дәүләтне дә аракы ныгытканы юк. Аракы эчеп, теләк теләп, берәүнең дә уңганы юк. Аракы – бозыклыкларның анасы, һәм без, шушы никах көнне – гаилә кавышкан көнне – бозыклыкның иң начарын эшләп, сез әйбәт торыгыз, дип теләк телибез. Аллаһы сакласын.

Никахта кыз бала да, ир бала да: риза булып бардым, риза булып алдым дигәч, Аллаһы Тәгалә каршысында да, бәндәләр каршысында да вәгъдә биргән була. Хатын-кыз иремне ир итеп санармын дип, ә ир кеше хатынымны хатын итеп тотармын дип вәгъдә бирә. Һәм әти-әнине дә догасын алырлык итеп, алар риза булырлык итеп тәрбияләп озатырмын

дип әйтә. Балаларымны да шәригатькә муафыйк итеп, Аллаһы Тәгалә кушканча тәрбияләп үстерермен дип әйтә. Никах менә шундый була.

Балаларыбызны никахка җитди итеп әзерләргә, үзебезгә дә никахыбызга хилафлык китермичә, аңа тугры булып яшәргә тиешбез.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Җәмалов,*

*«Саләх» мәчетенең имам ярдәмчәсе*

*28 февраль вәгазе,*

*Раҗәб аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Иман баганалары

Бу дөньяның һәм Ахирәтнең Хуҗасы, адәмнәрне, барлык тере һәм тере булмаган нәрсәләрне юктан бар итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә дан һәм мактауларыбыз булса иде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез һәм догаларыбыз ирешсә иде, Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Бер вакытны без Аллаһының Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә утырганда, безнең янга гадәттән тыш ак киемнән, кара чәчле бер кеше килде. Ул ерактан килгән кешегә охшамаган, әмма безнең беребез дә аны белми иде. Әлеге кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршысына килеп утырды. Тезләрен аның тезенә терәп, учын аның ботларына куйды һәм мондый сүзләр әйтте: «Ий Мөхәммәд, миңа Ислам турында сөйлә әле!» Аллаһының Илчесе: «Исламның мәгънәсе Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Аллаһының Илчесе булуына иман китерү, намаз уку, зәкят бирү, Рамазан аенда ураза тоту, мөмкинлегең булса, хаҗ кылудан гайбарәт» – дип җавап бирде. Әлеге кеше: «Син дөрес әйттең» – диде. Ә без аның сорау бирүенә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрен раславына гаҗәпләндек. Аннан соң ул: «Ә хәзер миңа иман турында сөйлә инде», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иманның асылы: кешенең Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, Кыямәт көненә, Аллаһы әзерләп куйган тәкъдирнең

игелекләренә һәм яманлыкларына һәм үлгәннән соң кабат терелүгә ышану», – дип җавап бирде. Бу кеше тагын: «Син дөрес әйттең» – диде...

Әлеге кеше китеп баргач, безнең кызыксынуыбызны канәгатьләндереп Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Чынбарлыкта бу сезгә динегезне өйрәтү өчен яныгызга килгән Җәбраил фәрештә иде», – дип әйтте.

Гарәп телендә «иман» сүзе «ышану» дигәнне аңлата. Ышану ул дөньялыкта барлык кыйммәтләрдән дә кыйммәтле һәм бик кадерле нәрсә булып тора. Чын күңелдән ышану белән чагыштырганда, җир йөзенең байлыклары ком бөртеге генә. Иман – мәңгелек дөньяда коткарылуга ачкыч ул.

Иман ул – Аллаһыга ышану хисе. Ислам галимнәре белдерүе буенча, Аллаһыга ышаныр өчен һәр кешегә өч нәрсә сәбәп булып тора:

1. Һәр кешегә тумыштан бирелә торган Аллаһыны тою хисе (фитри иман). Галимнәр аңлатулары буенча, җан Ахирәттән җибәрелә: Аллаһы әмере буенча фәрештәләр аны ана карынындагы яралгыга өреп кертә. Шулай итеп, җан Ахирәт тормышын күргәнгә, белгәнгә күрә, шушы Ахирәт тормышына кайтасын да белә. Менә бу – фитри иман була. Фитри иман Аллаһы Тәгалә барлыгына ышанырга этәреп тора.

2. Кешенең үз-үзен барлыкка китерүе мөмкин булмавы. Кешене барлыкка китерү Аллаһыдан башка берәүнең дә көченнән килми.

3. Галәм төзелешендәге тәртиплек. Әлеге тәртип үзеннән-үзе берничек тә урнаша алмый, ә кешенең галәмдә тәртип урнаштырырга көче җитми.

Аллаһы Тәгаләгә ышану мөселманга бик яхшы йогынты ясый, аның дөньясы өчен дә, Ахирәте өчен дә гаять зур файда китерә. Кодси хәдисләрнең берсендә болай дип әйтелә: «Мин Адәм баласының йөрәгендә берьюлы ике курку һәм ике иминлек хисен салмамын. Әгәр кеше Миңа ышанса һәм Миннән курыкса, башка бер кемнән дә курык-

мас. Әгәр Миңа ышанмаса, Миннән курыкмаса, мәхлукъларидан куркуны йөрәгенә урнаштырырмын». Шулай ук Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

بَلَىٰ مَنْ أَسْلَمَ وَجْهَهُ لِلَّهِ وَهُوَ مُحْسِنٌ فَلَهُ أَجْرُهُ عِندَ رَبِّهِ وَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ ﴿١١٢﴾

**«Аллаһыга буйсынганнарга һәм изге гамәлләр кылучыларга Аллаһы әҗерен бирер һәм шундыйлар курку һәм кайгы белмәс».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:112

Аллаһы Тәгаләгә иман китергән кешеләр Аның фәрештәләренә дә ышанырга тиеш. Фәрештәләргә ышану иманның икенче баганасы булып тора. Фәрештәләр нурдан барлыкка китерелгән. Алар ашамый да, эчми дә, җенесләре дә юк һәм һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә табынып яшиләр, Аның кушканнарын тиешенчә үтиләр. Кешеләрдән аермалы буларак, фәрештәләр беркайчан да гөнаһ кылмыйлар. Аллаһының әмере буенча фәрештәләр төрле вазифалар башкара.

1. Җәбраил фәрештә аша Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм башка пәйгамбәрләргә хәбәр җибәргән.

2. Микаил фәрештә яңгыр, кар, җил һәм башка табигать күренешләре өчен җавап бирә.

3. Исрафил фәрештә Кыямәт көне җитүен һәм үлгәннәрнең кабаттан терелүен белгертеп, Сур мөгезенә өрәчәк.

4. Газраил – кеше үлгәндә аның җанын алучы үлем фәрештәсе.

5. Мөнкир һәм Нәкир – кабердә кешедән аның гамәлләре турында сорау алачак фәрештәләр.

Моннан тыш, бик күп фәрештәләр бар: Коръән укыганда җиргә төшүче фәрештәләр, кешене саклап торучы фәрештәләр, Аллаһы

Тәгаләне мактар һәм зикер итәр өчен җыелган кешеләрне эзләп табучы фәрештәләр, ана карынындагы балага җан өреп кертүче фәрештә, һәр кешенең яхшы һәм яман гамәлләрен язып баручы фәрештәләр һ.б.

Фәрештәләргә ышануның әһәмияте бик зур. Әйтик, үзебез исән чакта барлык кылган эшләребезне, сүзләребезне гамәл фәрештәләре язып барганнарын белгәч яки югарыда язып үткән фәрештәләрнең вазифаларын өйрәнгәч, безнең барчаларыбызда да җаваплылык хисе уяна һәм Аллаһы Тәгалә кушканча яшәү мөһим икәнлегенә ышану арта. Шулай ук һәр гамәлебез өчен җавап тотачагыбызны белеп яшибез.

Аллаһыны тану һәм Аңа гыйбадәт кылу бу дөньяда яшәүче һәр кешенең мөһим бурычы булып тора. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләр аша кешеләрне бер Аллаһыга ышанырга, Аңа гына табынырга өндәгән һәм Аның һич тиңдәше юклыгын аңлата торган Изге Китаплар җибәргән. Барлык пәйгамбәрләр дә Раббыбыздан алган хәбәрләрне иң элек үзләре җиренә җиткереп үтәгәннәр һәм кешеләргә дә бернинди үзгәрешсез җиткергәннәр. Һәр Китапта да бер Аллаһыга табынуга өндәү, Аллаһы Тәгалә турында белемнәр, кешеләрне бу дөньяда һәм үлгәннән соң бәхеткә ирешү юллары өйрәтелгән була.

Кешеләргә Аллаһы Тәгалә тарафыннан дүрт изге Китап иңдерелүе мәгълүм:

1. Тәурат – Муса галәйһиссәлламгә җибәрелгән.
2. Зәбур – Давыт галәйһиссәлламгә җибәрелгән.
3. Инҗил – Гайсә галәйһиссәлламгә иңдерелгән.
4. Коръән – Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгән.

23 ел дәвамында Җәбраил галәйһиссәллам аркылы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгән изге Коръән китабын мөселманнар Кыямәт көненә кадәр, кешелеккә яшәү өчен өйрәтмә һәм Ахирәткә әзерләнү өчен күрсәтмә буларак кабул итәләр, Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгаләнең хак сүзләре булуына ышаналар.

Моңа әлеге аять дәлил булып тора:

قُل لَّئِنِ اجْتَمَعَتِ الْإِنسُ وَالْجِنُّ عَلَىٰ أَن يَأْتُوا بِمِثْلِ هَٰذَا الْقُرْآنِ لَا يَأْتُونَ بِمِثْلِهِ وَلَوْ كَانَ بَعْضُهُمْ لِبَعْضٍ ظَهِيرًا ﴿٨٨﴾

**«Шунысы хактыр ки, бәндәләр белән барлык җеннәр бергә җыелышып бер-берсенә ярдәм итешсәләр дә, Коръәнгә охшаш башка китап иҗат итә алмаячаклар».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:88

Коръәнне, аның үзенчәлеген беркем дә һәм һичкайчан да кабатлый алмаячаклар. Коръән ул – Раббыбыз Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән кабатланмас Изге Китаптыр.

Адәм балаларына Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген искә төшерү, Аңа гыйбадәт кылырга кирәк икәнен аңлату һәм ул гыйбадәтне башкару рәвешен күрсәтер өчен Аллаһы Тәгалә халыкка пәйгамбәрләрләр җибәргән. Алар бик күп булган. Коръәни Кәримдә 25 пәйгамбәрнең исеме искә алына, ә хәдисләрдә килгән мәгълүматларда барлыгы 124 мең пәйгамбәр җибәрелгәнлеге билгеле. Һәрбер мөселман барлык пәйгамбәрләргә дә ышанырга тиеш. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләрне кешеләр арасыннан сайлап куйса да, алар үзләренең күркәм әхлаклары, изге күңелләре һәм олы гөнаһлар кылмаулары белән аерылып торганнар. Алар барысы да кешеләрне Аллаһы кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып, ягъни Аллаһы Тәгаләгә буйсынып яшәргә өндәгәннәр, шулай ук Кыямәт көне булачагын һәм барлык кылган гамәлләр өчен Ахирәттә җавап бирергә кирәк булачагын аңлатканнар.

Пәйгамбәрләр – кешеләрнең асыллары, ә аларның иң яхшысы – Аллаһы Тәгаләнең соңгы Илчесе – кешеләр һәм җеннәр өчен барлык галәмгә рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу

галәйһи вә сәлләм. Ул – Аллаһының соңгы Пәйгамбәре, аннан соң пәйгамбәрләр булмады һәм бу дөнья беткәнчегә кадәр булмаячак.

مَّا كَانَ مُحَمَّدٌ أَبَا أَحَدٍ مِّن رِّجَالِكُمْ وَلَكِن رَّسُولَ اللَّهِ وَخَاتَمَ النَّبِيِّينَ ﴿٤٠﴾

**«Мөхәммәд – ирләрегезнең һәрберсенең атасы булмады, ул Аллаһының Расүле һәм пәйгамбәрләрнең соңгысыдыр».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:40

Иманлы кеше Кыямәт көнендә һәркемнең үзенә тиешле җәза яки савап алуына ышана. Бу дөньядагы гөнаһлары, яманлыклары һәм гаделсезлекләре өчен, һичшиксез, теге дөньяда җәзаланачак. Үз гомерендә бик күп изгелекләр кылып та, фани дөньяда савапларга ирешмәгән булса, үлгәннән соң тиешен алачак. Кыямәт көненә ышану мөселман өчен бик мөһим, чөнки кешедә үз эш-гамәлләре өчен җаваплылык хисе уяна, ул вакытын бушка әрәм итми башлый. Мөселман үзенең ап-ачык һәм яшерен кылган гөнаһлары өчен, шулай ук Аллаһы Тәгалә аңа насыйп иткән игелекләрдән ничек файдалануы турында җавап тотачак. Моны аңлаган кеше тыелганнардан тыелырга өйрәнә һәм үзенең әхлагын камилләштерә. Кыямәт көненә ышану – иман нигезләренең берсе булып тора.

Тәкъдиргә иман китерү – иман шартларының берсе. Аллаһының барлыгына, берлегенә, Аның фәрештәләренә, изге Китапларына, пәйгамбәрләренә һәм Кыямәт көненә ышанган кеше тормышта булган барлык вакыйгалар, яхшы һәм яман нәрсәләр Аллаһы Тәгаләдән булуына ышанырга тиеш. Шулай итеп Ислам динендә булган мөселман кешесе туганнан алып үлгәнчегә кадәр үзе белән булган вакыйгаларны, шатлыклы яки кайгылы хәлләрне, тормышында булган һәрбер яхшылыкны һәм яманлыкны Аллаһы Тәгалә насыйп иткән тәкъдир – язмыш буларак кабул итәргә тиеш. Имам Әт-Тәһави болай дигән: «Тәкъдир – Аллаһы

Тәгалә барлыкка китергән сер ул. Раббыбызга якын булган фәрештәләргә дә, Ул безгә җибәргән пәйгамбәрләргә дә бу хакта белемнәр бирелмәгән. Тәкъдирнең асылы турында күп һәм тирәнтен уйлану ялгыш юлга, югалтуларга һәм гөнаһларга этәрә. Шуңа күрә кирәкмәгән уйлардан, ялгыш фикерләрдән сакланыгыз! Аллаһы Тәгалә кешелектән тәкъдир турындагы белемнәрне яшергән һәм аларны эзләүне тыйган».

Хөрмәтле дин кардәшләрем, Раббыбыз алдагы көннәребездә барчаларыбызга да гыйлемнәребезне туплап, гамәл гыйбадәттә булып, мәчетләргә мөмкин кадәр ешрак килеп, җәмәгать намазларында катнашып, иманыбызны, күңелдәге тәкъвалыгыбызны ныгытырга насыйплар итсә иде.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Данир хәзрәт Шәрәфетдинов,*

*Чүпрәле районы мөхтәсибе*

*6 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Ислам динендә хатын-кыз

Галәмнәр Раббысы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә барча хәмед һәм сәналәр, галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән Хак расүлебез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәламгә, аның сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде. Көннәрнең солтаны – җомга көнне Аллаһының әмеренә буйсынып, мәчетләргә килгән мөселман кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Техника үсеше һәм яңартылу чорында яшибез. Тормыш гөрли, алга чаба. Артта калмас өчен адәм баласы бөтен көчен куеп эшли, белемен ныгыта, сәламәтлеген кайгырта. Ләкин шул вакытта ул рухи яктан үзен кайгыртмый башлый, әкренләп кешедә тормышыннан канәгатьсезлек хисе уяна башлый. Мондый халәттә адәм баласына дин ярдәмгә килә, чөнки бары тик Аллаһыга гыйбадәт кылу гына рухи тынычлык бирә ала. Көне буе чабып, арып-талып кеше өенә тынычлык эзләп кайта. Өендә ирне мөслимә тормыш иптәше көтсә, димәк бу йорт чыннан да тынычлык, мәхәббәт оясы дип әйтеп була.

Бүген сүзебез хатын-кызлар турында барачак. Хатын-кыз ир-ат тормышында 4 рольне башкара: ана, хатын, апа (сеңел) һәм кыз бала. Һәрбер роле ир кеше яшәешендә зур әһәмият алып тора.

Әгәр дә хатын-кызның хатын буларак ролен карасак, иманлы тормыш иптәше гаиләдә балаларны Ислам дине кушканча тәрбияләп үстереп, ир-атны иманлы, итагатьле балалар белән шатландырачак. Сеңел яисә апа буларак ул абыйсына төрле тормыш авырлыкларын җиңеп чыгу өчен терәк булачак. Кыз бала буларак әтисен кайгыртып яшәячәк. Шулай итеп, ир кеше бәхетле булсын өчен аңа төрле яктан хатын-кыз терәге, мәхәббәте кирәк дигән нәтиҗә ясап була.

Ислам дине хатын-кызны үзенчәлекле итеп ир-аттан аерып куйды. Ләкин моны хатын-кызның хокукын чикләү дип түгел, ә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең аңа булган кайгыртуы, мәхәббәте дип аңлау тиешле. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا يَحِلُّ لَكُمْ أَن تَرِثُوا النِّسَاءَ كَرْهًا ﴿١٩﴾

**«Әй, мөэминнәр, хатыннарны көчләп, мирас урынына тоту сезгә хәләл түгел».**

«Нисә / Хатыннар», 4:19

Шул рәвешчә Раббыбыз ирләргә хатыннарын кадерләргә куша.

Хатын-кызның ире алдында бик күп бурычлары бар. Аларны үтәмәгән очракта Аллаһының ачуына дучар булуын да бөтенесе дә аңлый, моның турында күп языла. Бүген без ир кеше гаиләдә бәхетле булсын өчен нинди чаралар барлыгын карап үтәчәкбез.

Гокбә бине Әмир хәбәр итә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Ныклап үтәлергә тиешле шартлар шул – ул якынлык кылуны рөхсәт итүче шартлар»[1].

Мулла Әл-Кари бу хәдисне болай аңлата: «Шарт дигәннән, без монда мәһәрне күзалларга тиешбез, чөнки аны түләп, без тормыш иптәшебез белән якынлык кылырга хокук алабыз. Башка галимнәр болай дип әйтә: «Монда сүз никахтан соң хатын-кызның нинди хокукларга ия булуы турында сүз бара. Болар мәһәр, тәэмин итү һәм яхшы мөгамәлә», – диләр.

Димәк, өйләнешкәч, ир-ат та үз өстенә зур гына йөкләмәләр ала икән. Кызганычка, бүгенге көндә ир-атның гаиләсенә карата яхшы мөгамәлә һәм кирәкле кадәр игътибар бирүе чын ир кеше эше дип саналмый башлады. Киресенчә, андый ир-ат өстеннән «хатын кубызына биюче» дип мәсхәрәләү гади күренеш.

---

1 Әл-Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыкларыннан.

Әгәр дә инде ул берничә көн буена өендә дә күренмичә кафе һәм рестораннарда йөрсә, хатыны һәм туганнары да аның кайдалыгында хәбәрдар булмасалар бу «чын» ир дәрәҗәсенә күтәрелә. Әмма, дөреслектә, монда ирлекнең тамчысы да күренми.

Гаилә ул – ике кешенең бәхетле гаилә төзүдә уртак хезмәте, бердәмлек булмаса, нәтиҗә дә юк дигән сүз. Ничәмә-ничә еллар шул кеше белән бер түбә астында гомер итеп, ул кешедә сиңа карата бары тик нәфрәт хисе генә калса, бергә яшәүнең нинди мәгънәсе кала?

Гаилә – ул, беренче чиратта, бер-береңә юл кую өстендә табу юнәлешендә эшләү. Әбү Һөрайрадан җиткерелә: «Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хатын-кызларга карата яхшы мөгамәләдә булыгыз диеп әйтеп калдырам. Дөреслектә, хатын-кыз кабыргадан яратылды, кабырганың иң кәкре җире – өске ягы. Турайтырга уйласаң, сындырырсың, ничек бар шулай калдырсаң ул тураймаячак. Хатын-кызларга карата яхшы мөгамәләдә булыгыз дип әйтеп калдырам»[1], – дип әйткән.

Бу сүзләр алар үзгәрер дигән фикер белән яшәмәскә, аларның «кәкрелеген» кабул итеп, алар янәшәсендә булуны аңлата. Яшьләр гаилә корып бераз вакыт үткәч, бер-берсен өйрәнү, ияләнү чоры башлана. Менә монда инде ир кеше хатын-кызны төзәтергә кирәк дигән фикер белән яна башлый. Бу бер дә яңалык түгел, чөнки моны Пәйгамбәребез дә шулай булачак дип әйтеп калдырды. Монда инде «алтын» урталыкны югалтырга ярамый: әлбәттә, хатын-кыз ир кешегә яраклашырга тиеш һәм ир кеше дә моны әйтмичә, исенә төшермичә тора алмый, әмма чикләрне узарга да ярамый. Кимчелекләргә сабыр итәргә, ачу китерә торган гадәтләр белән килешергә кирәк. Бер хатын-кыз озак җыена, икенчесе кире, өченчесенә берәр төрле ризык ошамый һ.б. Шуның ише вак кимчелекләргә сабыр

[1] Әл-Бохари һәм Мөслим җыентыкларыннан.

итәргә тиешле, чөнки бу кимчелекләрне «сындыра» башласаң бу аерылышуга китерәчәк.

Бүгенге көндә бу хәдис бик актуаль. Безнең балалар һәр шәхеснең үз фикере булган чорда яши, хәтта мөселман гаиләсендә туып-үскән балалар да моннан читтә калмый. Бер-береңә юл кую дигән төшенчә күп очракта яшьләр өчен бөтенләй ят әйбер.

Имам Ән-Нәвәви болай дип әйтә: «Бу хәдис хатын-кызга карата йомшаклык күрсәтергә, аларга карата яхшы мөгамәләдә булырга, аларның начар холкына сабыр итәргә өнди, чөнки аларның акылы зәгыйф, ә алардан сәбәпсез аерылу мәкруһ һәм аларны үзгәртү өметсез».

Әлбәттә, юл кую килү дини мәсьәләләргә һәм гөнаһ эшләр кылуга китерергә тиеш түгел. Мәсәлән, үзең намаз укып хатының гаурәтләрен капламыйча йөрсә, «мин сабыр итәм» дип кенә Аллаһы каршында акланып утырып булмаячак.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Иманлы кешенең мөслимәгә карата нәфрәт хисе булырга тиеш түгел. Әгәр аның берәр сыйфаты ошамаса, икенчесе, һичшиксез, күңеленә хуш киләчәк»[1].

Бу хәдистән без хатын-кызның кимчелексез булмаячагын күрәбез. Әгәр дә ир кеше кимчелексез тормыш иптәше эзли башласа, ул беркайчан да өйләнмәячәк дип ныклап әйтеп була. Кешенең бер генә булса да яхшы сыйфаты булмыйча калмый, шулай булгач, аннан начар якларны эзләмичә, яхшы якларын күрә белергә кирәк. Ир белән хатын-кызга тормыш баткаклыгыннан күтәрелергә тырышырга тиешле. Синең янәшәңдә Аллаһыга һәм Пәйгамбәребезгә ышанучы кеше һәм аның сиңа ошаган, синдә горурлык уяткан сыйфатлары булмау мөмкин түгел.

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Парлар башкаларның тормышына кызыгырга, бер-берсе алдында аларны мактарга тиеш түгел, чөнки ябык ишекләр артында нәрсә барын беркем дә белми. Ә бу гамәл бер-береңә карата нәфрәт уятырга мөмкин.

Шулай ук бер нәрсәне истән чыгарырга кирәкми: ә син үзең нинди, синдә башка кешедә күрә алмаган нинди сыйфатлар бар? Синең бу сыйфатларың хатыныңда ачу, нәфрәт хисләре уятмыймы икән?

Бу хәдис гаилә «бер капкалы уен» гына түгел, ә икеңнең дә хезмәте дигәнне аңлата.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә барчаларыбызга да күркәм гаилә булып, бер-беребезне яратып, хөрмәт итеп яшәргә насыйп итсен. Балаларыбыз безнең көзгебез, алар бәхетле булсын дисәк, гаиләдә тынычлык, ихтирамлылык, сабырлык урнаштыру безнең бурыч, җәмәгать!

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Илгиз хәзрәт Әшрапов,*
*Яңа Чишмә районы мөхтәсибе*

*13 март вәгазе*

*Раҗәб аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Ислам – «сәлам» сүзеннән

Барлык галәмнәрне юктан бар кылып, ризыкландырып, нигъмәтләндереп торучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу Хак Тәгаләгә мактау олуглауларыбыз, хәмде-сәналәребез булсын.

Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән, безне ут газабыннан котылып, җәннәткә илтү юлларын өйрәтеп калдырган сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ихлас күңел түрләреннән чыккан салават шәрифләребез булса иде.

Соңгы елларда адәм балаларына диндә ирек куелды. Күп кенә кешеләр ничә еллар динсезлектә яшәгәннән соң, яңадан үз диннәрен тотып яшәү өчен киртә булмавын аңладылар. Туксанынчы елларда бабайларыбыз әти-әниләреннән ишеткән, отып калган дини гыйбадәтләрне торгызу өстендә зур көч куеп эш башладылар. Дин халык күңелендә үлмәде, һәркем Раббысына ышанды, Аңа күңеленнән ихлас мөрәҗәгать итте. Ислам янәдән кешеләр күңелендә яшәрде, яши башлады.

Ислам дине – тынычлык дине. Ислам сүзенең тамырында булган сәлам сүзе тынычлык, иминлек дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә Коръәндә бөтен мөселманнарга дөньяга тынычлык, хозур һәм кардәшлек китерүләрен әмер итә. Мөселманнарга башка дин әһелләренә карата да гүзәл әхлак күрсәтү, аларның да яхшылыгы өчен тырышу җаваплылыгы йөкләнгән. Әйе, мөселманнарны фетнә чыгаручылар, кан коючылар итеп күрсәтергә тырышучылар бүген шактый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне бу хакта хәдис-шәрифләрендә кисәтеп куя. Ничек кенә булса да, без, мөселманнар, динебездә нык торырга тиешбез. Татар халкының «Таш атканга аш ат» мәкале дә юктан

гына чыкмаган. Начарлыкка начарлык белән җавап бирү – явызлыкка юл кую, аны арттыру дигән сүз. Инде сиңа карата яманлык кылучыга изгелек белән җавап бирү, кимендә тыелып калу – үзеңә савап алу гына түгел, ә, бәлки, Аллаһы Тәгалә кушуы белән, теге кешенең күңелен йомшартуга, кылган начар гамәлләренә тәүбә итүгә, киләчәктә бары яхшылыклар, изгелекләр башкаруга сәбәпче дә булырга мөмкин. Мөселман кешесе башкаларга сабырлыкның, гаделлекнең, ихласлыкның, тынычлыкның үрнәге булырга тиеш. Бу безнең изге максатыбыз булып тора. Аллаһы Раббыбыз бу уңайдан Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ ۗ ﴿١١٠﴾

**«Ий сез Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәте, дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, Аллаһыга хак ышану илә ышандыгыз, кешеләрне хәерле эшләргә, изге гамәлләргә өнди белү белән өндәдегез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыя белеп тыйдыгыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Әйе, ислам дине артына яшеренеп, начарлык кылып йөрүчеләр дә бихисап. Үзләрен мөселман дип атап, башкаларның да күзен буып, алдалап, башка дин вәкилләрендә ислам дине турында дөрес булмаган фикер булдырып йөрүче монафикълар пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында да булганнар, бүген дә бар, ахырзаманга-ча булачак. Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә барыбызны да кылган гамәлләребезгә, ниятебезгә карап хөкем кылачак. Җаныбыз тәнебездән аерылып чыкканчы, без Ислам диненең саф дин икәнен башкаларга да җиткерү өчен тырышып яшәргә тиешбез. Динебезне үзләренең шәхси максатларында файдаланырга тырышучылар безләрдән түгел. Шуңа

да дингә килүчеләр, ислам дине нигезләрен өйрәнә генә башлаучылар остазларны игътибар белән сайласын иде. Ислам динендә кан коюга, үтерүгә, экстремистлыкка чакыру юк һәм булырга мөмкин түгел. Ислам кешене башка дин тотуы, башка милләттән булуы өчен генә үтерүне, аңа җәрәхәт салуны катгый тыя. Аллаһы Тәгалә мөселманнарга явызлык кылырга түгел, хәтта гөнаһка илтергә мөмкин булган эшләргә якын килергә дә кушмый. Кеше үтерү – зур гөнаһ, чын мөселман кешесе моны яхшы белә, ул Аллаһы Тәгалә ләгънәтеннән, мәңгелек җәһәннәм утыннан курка һәм бу адымга бармый.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَّا يَنْهَاكُمُ اللَّهُ عَنِ الَّذِينَ لَمْ يُقَاتِلُوكُمْ فِي الدِّينِ وَلَمْ يُخْرِجُوكُم مِّن دِيَارِكُمْ
أَن تَبَرُّوهُمْ وَتُقْسِطُوا إِلَيْهِمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُقْسِطِينَ ﴿٨﴾

**«Ислам диненә каршы сезнең белән сугышмаган һәм сезне йортларыгыздан куып чыгармаган кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булудан һәм аларга гаделлек кылудан Аллаһы сезне тыймый. Аллаһы гадел булганнарны сөядер».**

«Мүмтәхәнә / Сыналучы хатын», 60:8

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, игътибар итегез әле: Раббыбыз мөселманнарга үзебезгә, гаиләбезгә, динебезгә, илебезгә кылыч күтәреп килмәгән кешегә карата, аның нинди дин тотуы, кайсы милләттән булуына карамастан яхшы мөнәсәбәттә булырга өнди.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисшәрифендә мондый сүзләр әйтә: «Явызлык күрсәгез – аны кулыгыз белән туктатыгыз. Кулыгыз белән туктата алмасагыз – телегез белән тыегыз. Инде телегез белән дә тыя алмасагыз, кимендә, күңелегез белән бу эшкә каршы булыгыз». Берәр начар гамәлгә карата «дөрес эшләгән» дип фикер йөртү мөселманлык билгесе түгел. Инде андый начар гамәлләрдә

катнашу турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Без – мөселманнар көн дә кечкенә генә булса да яхшылык кылу белән генә чикләнеп калмыйча, үзебезне явызлыкка каршы көрәшкә дә багышларга тиешбез. Яхшылык башка яхшылыкларны алып килгән сыман, начарлык яңа начарлыкларга китерә. Мисаллар өчен ерак йөрисе юк, мөхтәрәм кардәшләр. Күпер салдыкмы – аның аркылы узган һәр кешенең рәхмәте күперне төзүченең гамәл китабына язылып бара. Инде әгәр хәмер сату белән шөгыльләнәбез икән: шул хәмерне эчеп, кем нинди яманлык кыла – шул гамәлләр өчен хәмерне сатучыга да җавап бирәсе булачак. Экстремистлыкка, кеше үтерүгә, фетнә чыгаруга өндәүче дә, хәтта үзе бу эшләрдә катнашмаса да – бу гамәлләрне үз куллары белән кылган сыман булачак. Ислам дине – гаделлек дине. Рәхимле вә Рәхмәтле Аллаһы Тәгалә бу фани дөньяда барлык кешеләрне тигез яратса да, Ахирәттә кылган гамәлләребезгә һәм уй-ниятләребезгә карап, кемнәрне мәңгелек җәннәтле, кайсыларыбызны җәһәннәмле итәчәк. Раббым, Үзең сакла!

Террорчылык белән экстремизмны Ислам диненә бәйләп аңлату – хаталы һәм бик куркыныч күренеш. Изге Китабыбыз Коръән, сөекле Пәйгамбәребезнең тормышы, хәдис-шәрифләре мөселманнарга шуны инандыра: Ислам дине мөселманнарны эшләрендә һәм гамәлләрендә күндәмлеккә, изгелеккә чакыра. Әхлагыбызны төзәтергә, яхшылыклар эшләп яшәргә тырышырга, бер төрле мәхлүкатка да зыян салмаска тиешбез. «Кем ул мөселман?» – дигән сорауга, «Мөселманның кулыннан да, теленнән дә башка кешеләргә зыян килмәс,» – дип җавап бирелә. Шуңа да Ислам әхлагы террорның һәм экстремизмның чыганагы түгел, чишелешедер.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Рәдиф хәзрәт Тимергалиев,*

*Кукмара районы имам-мөхтәсибе*

*20 март вәгазе,*

*Раҗәб аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Мигъраҗ кичәсе

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин. Барча галәмнәрнең Раббысы булган, барлык мәхлүкатларны тәрбияләп торучы Аллаһы исеме белән башлыйбыз. Аллаһы Тәгаләгә күңел түреннән әйтелгән хәмде-сәналәребез, шөкерләребез булсын. Галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән, үзенең холкы, әдәбе белән безгә мисал булган сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә әйтелгән салават шәрифләребез, сәламнәребез ирешсен. Йә Раббым, безгә ошбу вәгазьне дөрес иттереп аңлап һәм үзебезнең калебебез белән кабул итеп, көндәлек тормышыбызда кулланырга насыйп ит.

Пәйгамбәребезнең тормышында иң әһәмиятле вакыйгаларның берсе – Мигъраҗ кичәсе, ул зур могҗиза булып тора. Аллаһының рәхмәте белән бу кич турында сөйләшеп китәрбез.

Исра вә Мигъраҗ кичләре нәрсәне аңлата? Исра – ул төнлә сәфәр кылу, Мигъраҗ – күккә күтәрелү дигән мәгънәгә ия. Аллаһы Тәгалә бу вакыйганы Коръәни Кәримдә болай дип искә ала:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى
الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

**«Үзенең колы Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер кичтә Мәккә шәһәрендәге мәсҗид Харамнан Кодес шәһәрендәге мәсҗид Әл-Әкъсага йөртеп кайтаручы Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь дип белегез! Ул Кодес шәһәренең тирәсен бәрәкәтле кылдык, Мөхәммәд галәйһиссәламгә гаҗәп**

**галәмәтләребезне күрсәтмәк өчен кодрәтебез белән йөрттек, әлбәттә, Аллаһы һәр сүзне Ишетүче вә һәрнәрсәне Күрүчедер».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:1

Бу вакыйганың төгәл нинди елда булганы хакында галимнәр төрле фикердә, әмма күпчелеге раҗәб аеның егерме алтысыннан егерме җиденче көненә каршы төндә – 621 елда булды дип хисаплыйлар. Хәзер әлеге вакыйганың нинди рәвештә булганы турында хәдис җыентыкларында искә алынганны зикер итәрбез.

Бохари, Мөслим җыентыкларында Исра һәм Мигъраҗ вакыйгасы бу рәвешле бәян ителә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Кәгъбәтуллага сөялеп утырган вакытында, аның янына Җәбраил фәрештә килә. Ул Бурак дигән канатлы атка (оча торган җан иясе) охшаган хайван белән була һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламне алып, Кодес (Иерусалим) шәһәренә оча һәм шуннан соң Буракны мәчет капкасына бәйләп куеп, Җәбраил фәрештә белән Аллаһы Илчесе күккә күтәреләләр. Пәйгамбәребез күкнең беренче катында Адәм галәйһиссәлам, икенче катында – Яхъя һәм Гайсә галәйһимуссәлам, өченче катта – Йосыф галәйһиссәлам, дүртенче катта – Идрис галәйһиссәлам, бишенче катта – Һарун галәйһиссәлам, алтынчы катта Муса галәйһиссәлам белән очрашып, алар белән сәламләшә. Муса галәйһиссәлам белән сәламләшкәч, Муса елый башлый. Пәйгамбәребез елавының сәбәбен сорагач, ул: «Җәннәттә минем өммәтемдәгеләргә караганда, синекеләр күбрәк булыр», – дип җавап бирә. Шуннан соң Пәйгамбәребез җиденче катка күтәрелә, анда Ибраһим галәйһиссәлам белән күрешә. Болардан соң «Сидратүл-Мөнтәһә» дигән урынга килә. Моның турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

أَفَتُمَارُونَهُ عَلَىٰ مَا يَرَىٰ ﴿١٢﴾ وَلَقَدْ رَآهُ نَزْلَةً أُخْرَىٰ ﴿١٣﴾ عِندَ سِدْرَةِ الْمُنتَهَىٰ ﴿١٤﴾ عِندَهَا جَنَّةُ الْمَأْوَىٰ ﴿١٥﴾ إِذْ يَغْشَى السِّدْرَةَ مَا يَغْشَىٰ

﴿١٦﴾ مَا زَاغَ الْبَصَرُ وَمَا طَغَىٰ ﴿١٧﴾ لَقَدْ رَأَىٰ مِنْ آيَاتِ رَبِّهِ الْكُبْرَىٰ ﴿١٨﴾

> **«Әллә аның күргәннәрен шөбһә итеп низаглашасызмы? Тәхкыйк, ул икенче мәртәбә Җәбраилне үз сурәтендә күрде. Сидратүл-Мөнтәһә агачы Мәэва җәннәте янындадыр. Ул агачны күп фәрештәләр каплаган иде. Мөхәммәд галәйһиссәламнең күзе шул агачтан һәм андагы фәрештәләрдән читкә авышмады һәм куелган чиктән уңга-сулга үтмәде. Тәхкыйк, ул Мигъраҗда Раббысының олуг галәмәт вә дәлилләрен күрде».**

«Нәҗем / Йолдыз», 53:12-18

«Сидратүл-Мөнтәһә» – ул агач исеме, аның яфраклары фил колаклары зурлыгында һәм җимешләре чүлмәк кебек. Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгында, әлеге агач ботакларының күләгәсе астында атка атланган йөз кеше басып тора ала, дип әйтелә.

Шуннан соң Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә дүрт елга күрсәтелер, шуның икесе яшерен, икесе ачык булыр. Җәбраил фәрештә яшерен булган елгаларның җәннәттә булуын, ә ачык булганнарының Нил һәм Фырат (Евфрат) елгасы икәнлеген әйтер. Шуннан сон Бәйт Әл-Мәгъмурга күтәрелерләр һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршына өч савыт китереп куелыр. Аның беренчесендә сөт, икенчесендә су, ә өченчесендә хәмер салынган була. Пәйгамбәребез сөт салынган савытны сайлый һәм Җәбраил фәрештә, бу фитри иманнан, дип әйтә. Болардан соң Пәйгамбәребез Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә белән сөйләшә һәм Раббыбыз аңа көнгә илле вакыт намаз укырга әмер итә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу әмергә ризалык белдереп, Раббыбыз хозурыннан китә һәм моннан соң Муса гәләйһиссәлам белән очраша, ул аңа: «Синең өммәтеңә бу авыр булыр, Аллаһыдан илле вакыт намазны киметүне сора»,

– дип әйтә. Пәйгамбәребез Аллаһы Тәгалә хозурына килеп, намаз саннарын киметүне сорый, шуннан соң кабат Муса галәйһиссәлам белән очраша, ул Расүлебез галәйһиссәламгә: «Монысы да күп, синең өммәтең башкарып чыга алмаячак, Раббыбыздан тагын киметүне сора», – дип киңәш бирә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кабат Раббыбыз хозурына килә. Бу хәлләр берничә тапкыр шул рәвешле кабатлана.

Пәйгамбәребез биш вакыт намаз әмере белән Раббыбыз хозурыннан киткәннән соң, кабат Муса галәйһиссәлам белән очраша. Ул Расүлебезгә, тагын киметүне сорауны тәкъдим итә. Бу юлы Пәйгамбәребез: «Мин моннан да кимрәк намаз вакыты йөкләвен сорарга оялам», – дип җавап кайтара. Шул вакыйгадан соң мөселманнарга биш вакыт намаз фарыз кылына. Моннан соң Пәйгамбәребезгә җәннәт һәм җәһәннәм, җәннәттәге Кәүсәр елгасы күрсәтелә, шулай ук аңа җәһәннәм әһелләренең нинди газапка дучар булганнары бәян ителә.

Ошбу мәгънәле һәм бик эчтәлекле хәдистән без бик күп файдалы мәгълүмат алабыз. Шуларның иң әһәмиятлеләрен зикер итик:

1. Пәйгамбәребезнең Аллаһы Тәгалә белән турыдан-туры сөйләшүе;

2. Бу вакыйгадан соң биш вакыт намазның фарыз булуы;

3. Расүлебезгә җәһәннәмдәге газаплар һәм нинди гамәлләр өчен аларга юлыгу хакында бәян ителүе;

4. Аллаһы Илчесенең пәйгамбәрләр белән очрашуы, сәламләшүе.

Йә Раббыбыз, безнең кылган гыйбадәтләребезне, изге эшләребезне кабуллардан кыл. Безгә файдалы гыйлемнәр алырга һәм алар белән гамәл кылып яшәргә насыйп ит. Йә Раббыбыз, безнең белеп һәм белми кылган гөнаһларыбызны гафу ит, һидаять юлыннан чыгарма, үзебезне, гаиләләребезне туры юл белән генә алып бар. Намазның фазыйләтен аңлап, гыйбадәтләребезгә игътибарлы булырга насыйп әйлә.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Илгиз хәзрәт Сөнгатуллин,*

*Яр Чаллы шәһәренең «Ихлас» мәчете имам-хатыйбы*

*27 март вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Риба

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмед-сәналәрбез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Мөхәммәд бине Габдулла – Аллаһының хак илчесе, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – Аллаһы аңа, аның гаиләсенә һәм аның сәхабәләренә Үзенең салават-шәрифәләрен бирсә иде.

Ихлас күңел белән пакьләнеп, аруланып, Аллаһының рәхмәтен өмет итеп, ерак һәм якын җирләрдән җомга намазына җыелган мөхтәрәм мөселман кардәшләрем! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Аллаһы Тәгалә барчаларыбызга, илләребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә сәламәтлек, күңелләребезгә тәүфыйк, һидаять биреп, вакытлы гына булган дөнья тормышыбызда хәерле, бәрәкәтле һәм күркәм тормыш белән яшәп, мәңгелек булган Ахирәт тормышыбызда да Хак Тәгаләнең ризалыгына һәм рәхмәтенә ирешергә насыйп итсә иде. Тән һәм киемнәребезне пакьләгән кебек, Аллаһы Тәгалә күңелләребезне дә динебез тарафыннан харам гамәлләрдән, начар гадәтләрдән саклавыбызны насыйп итсә иде. Ул көндә бөтен серләр ачылып, бөтен яхшы, яман эшләребез ачык, мәгълүм булачак. Аллаһының газабыннан котылырга һичкемнең хәленнән килмәс, Аллаһыдан башка ярдәмче булмас.

Аллаһы Тәгалә Корьән Кәримдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә болай дип әйтте:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَأْكُلُوا الرِّبَا أَضْعَافًا مُّضَاعَفَةً ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ
تُفْلِحُونَ ﴿١٣٠﴾ وَاتَّقُوا النَّارَ الَّتِي أُعِدَّتْ لِلْكَافِرِينَ ﴿١٣١﴾ وَأَطِيعُوا اللَّهَ
وَالرَّسُولَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿١٣٢﴾

**«Ий, иман китерүчеләр! (Җаһилият дәверендәге кебек) Кат–кат арттырылган риба ашамагыз. Аллаһыдан куркыгыз, бәлки (Ахирәт савабын казанып,) уңышка ирешерсез. (Ий, риба ашаучылар!) Кяферләр өчен әзерләнгән Уттан куркыгыз (Һәм рибаны ташлагыз, юкса, аларга ияреп сез дә газапка дучар булачаксыз). Аллаһыга һәм Расүленә итагать итегез, бәлки, (Аллаһы тарафыннан мәрхәмәт ителерсез)».**

Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе, 3:130-132

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителгән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Бәла китерүче җиде гамәлдән ерак булыгыз!» Кешеләр: «Йә Расүлуллаһ, ул нинди гамәлләр?» – дип сорадылар. «Аллаһыга ширек китерүдән, сихердән, хаксызга кеше үтерүдән, риба һәм ятимнәр малын ашаудан, сугыш кырыннан качудан, әхлаклы һәм мөэминнә хатыннарга яла ягудан сакланыгыз», – диде[1].

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәлакәткә илтә торган җиде гамәл арасында күрсәткәннәрнең берсе – риба. Чынлыкта, риба – бүген дөньяда иң киң таралганы, хәтта мөселманнар арасында да иң ятатканы булып тора. Иблис мәлгунь безләргә аны шулкадәр матур итеп күрсәтә ки, без инде аның гөнаһ икәнлеген дә аңламыйбыз, үзебезне тынычландырабыз, тормышыбызда бу төр гөнаһка аз әһәмият бирәбез. Харам малның бәрәкәте юк, ничек керсә – шулай тиз чыгып китәчәк. Риба белән баеп, малны арттырып булмый.

1 Имам Мөслим хәдис җыентыгыннан.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең күп урынында безләрне кисәтеп болай дип әйтә:

الَّذِينَ يَأْكُلُونَ الرِّبَا لَا يَقُومُونَ إِلَّا كَمَا يَقُومُ الَّذِي يَتَخَبَّطُهُ الشَّيْطَانُ مِنَ الْمَسِّ ۚ ذَٰلِكَ بِأَنَّهُمْ قَالُوا إِنَّمَا الْبَيْعُ مِثْلُ الرِّبَا ۗ وَأَحَلَّ اللَّهُ الْبَيْعَ وَحَرَّمَ الرِّبَا ۚ فَمَن جَاءَهُ مَوْعِظَةٌ مِّن رَّبِّهِ فَانتَهَىٰ فَلَهُ مَا سَلَفَ وَأَمْرُهُ إِلَى اللَّهِ ۖ وَمَنْ عَادَ فَأُولَٰئِكَ أَصْحَابُ النَّارِ ۖ هُمْ فِيهَا خَالِدُونَ ﴿٢٧٥﴾ يَمْحَقُ اللَّهُ الرِّبَا وَيُرْبِي الصَّدَقَاتِ ۗ وَاللَّهُ لَا يُحِبُّ كُلَّ كَفَّارٍ أَثِيمٍ ﴿٢٧٦﴾

**«Риба ашаучылар (каберләреннән) шәйтан сугып еккан тиле кеше газапланган кебек кубарылыр. Бу җәза аларга: «Сату-алу да риба кебек бит», – дигәннәре өчен. Хәлбуки, Аллаһы сату-алуны хәләл итте, (акчаны акчага алмаштырганда яки бер үк төрле малларны алмашканда,) рибаны исә харам кылды. Кем дә кем Раббысыннан аңа (рибаны тыйган) үгет-нәсыйхәт килгәннән соң, (аңа ияреп, ялгышыннан) ваз кичә, үткән нәрсә – аның үзе өчен (Рибадан алганнары соралмый). Аның эше – Аллаһыга (калдырыла). Кем дә кем (рибаны хәләл дип кабул итү фикеренә) кайта, алар – Ут әһелләре. Алар – анда мәңге калучылар. Аллаһы рибаны юк итә, садакаларны исә (бәрәкәтләндереп) арттыра. Аллаһы (рибаны хәләл санап инкярга төшкән) кяфер һәм (өзлексез харам ашап гөнаһ кылуын туктатмаган) гөнаһлы беркемне дә сөйми».**

Әл-Бәкара / Сыер, 2: 275-276

«Әл-Бәкара» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә безләргә, иман китерүчеләргә, ачык итеп әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَذَرُوا مَا بَقِيَ مِنَ الرِّبَا إِن كُنتُم مُّؤْمِنِينَ ﴿٢٧٨﴾ فَإِن لَّمْ تَفْعَلُوا فَأْذَنُوا بِحَرْبٍ مِّنَ اللَّهِ وَرَسُولِهِ ۖ وَإِن تُبْتُمْ فَلَكُمْ رُءُوسُ أَمْوَالِكُمْ لَا تَظْلِمُونَ وَلَا تُظْلَمُونَ ﴿٢٧٩﴾

**«Ий, иман китерүчеләр! Әгәр (чыннан да,) мөэминнәр икәнсез, Аллаһыдан куркыгыз һәм риба өлешен калдырыгыз. Әгәр алай итмәсәгез (рибаны тыйган әмерләрне үтәмәсәгез), Аллаһы һәм Расүленнән булачак сугышны белегез.Әгәр (рибачылыктан) тәүбә итсәгез, малларыгызның нигезе (булган төп өлеше) – сезнеке. (Бурычлылардан артык сорап) Золым иткән һәм (төп өлешегез киметелмичә) золым күргән булмассыз».**

Әл-Бәкара / Сыер, 2:278-279

Риба телдә «өстәү», ә шәригатьтә бу аңлатма ике төрдә карала: беренчесе – сату-алудагы риба. Бу риба – тиңдәш булмаган, ягъни бер җисемнән булмаган товарларны алмаштыру. Әбү Сәгыйд Әл-Ходри радыяллаһу ганһедән риваять кылына: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Алтынны – алтынга, көмешне – көмешкә, бодайны – бодайга, арпаны – арпага, хөрмәне – хөрмәгә, тозны – тозга һәрвакыт үз тиңдәшләренә һәм бер үк микъдарда түләргә кирәк. Әгәр бер кеше өстәп бирсә яки өстәп бирүне таләп итсә, ул риба кылган булыр, алучы да, бирүче дә бер үк гөнаһлы булырлар»[1]. Әлеге хәдистә әйтелгәннән, бары тик товарларны гына алмаштырырга ярый икәнлеге аңлашыла. Әгәр товар төрле төрдә булса, ул очракта төрле күләмдәгеләр белән алмаштырырга мөмкин, ләкин ваклап түләү шарты белән алмаштырырга ярамый, әгәр товар төрле төрдә һәм сыйфатта булса, алмаштырганда ваклап түләргә мөмкин. Дөреслектә, төрле күләмдәге яхшы сыйфатлы бо-

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

дайны начар сыйфатлы бодайга алмаштырырга мөмкин түгел, чөнки бер җенес булгач, үлчәме дә, күләме дә бер үк булырга тиеш.

Әбү Сәгыйд Әл-Ходри радыяллаһу ганһедән риваять китерелә: «Билял радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә яхшы хөрмә алып килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу хөрмәне каян алдың?» – дип сорый. Биләл: «Безнең начар хөрмәбез бар иде һәм без 2 сагъ[1] начар хөрмәне 1 сагъ яхшы хөрмәгә алыштырдык», – дип җавап бирде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу – риба, алай эшләргә ярамый, әгәр яхшы хөрмә аласың килсә, үзеңнең начар хөрмәләреңне сатып, килгән акчага яхшысын сатып ал», – диде.

Икенчесе – залог һәм заем рибасы. Бу төр риба – милекне, күбрәк суммада кайтару шарты белән, билгеле бер суммадагы акчага салу яки бурычка алган акчаны процентлар белән күбәйтеп кайтарып бирү – заемга яки залогка риба алу һәм бирү була. Риба – биргән әйберне арттырып алу. Мәсәлән: бер кешегә бурычка бер мең сум биреп торып, кайтарып алганда бер мең ике йөз иттереп алу. Шул артык ике йөз сум риба була.

Бу ике төр дә исламда – харам. Рибачы да һәм процентлар белән акча бирүче дә зур гөнаһ кылучылардан булалар.

Риба, процент белән сату-алу итүчеләрнең Кыямәт көнендә каберләреннән Мәхшәр мәйданына кинәт җиргә егылган һәм җыерылып, авызларыннан күбекләр чыккан өянәкле кеше кебек чыгачагы хакында күп кенә хәдис шәрифләр һәм риваятьләр бар. Мәсәлән, Табәранинең Гауф бине Мәлик радыяллаһу ганһе риваять иткән бер хәдис-шәрифтә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ярлыканмый торган гөнаһлардан сакланыгыз. (Аларның берсе) ганимәт малын урлау. Кем дә кем шулай урласа, Кыямәт көнендә ул аны алып киләчәк. Тагын риба

1 Сагъ – үлчәү берәмлеге, 5142,5 граммга тигез.

ашау. Риба ашаучы кеше Кыямәт көнендә акылдан язып, җиргә егылган хәлдә терелтеләчәк»[1].

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять кылына: « Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Риба 70 төргә бүленә, шуларның иң җиңеле – ир баланың әнисе белән зина кылуы төсле»[2], – диде.

Габдулла бине Хәнзәлә радыяллаһу ганһедән риваять китерелә: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бер дирһәм генә риба кебек алынса да, 63 тапкыр зина кылудан да хәерсезрәктер»[3], – дип әйтте.

Аллаһы Тәгалә Ислам динен иң камил рәвештә иңдергән, аңа кешеләрнең үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, үзгәрешләр кертү кирәк түгел. Әмма үзебез буйсынасы урынга, динне яраклаштырырга тырышабыз. Чынлыкта, бу яман әйбер.

Аллаһы Тәгалә рибаны катгый рәвештә тыйды. Башы-аягы белән кредитларга чумган кеше, үзен: «Мин бит аннан файда алмыйм, зыянын гына күрәм», – дип бу дөньяда акланырга тырышса да, Кыямәт көнендә кемнең зыян күрүчеләр арасында булачагын Аллаһы Тәгаләдән башка бер зат та белми.

Кредит алырга мәҗбүрмен диючеләр күп. Рибага керүнең сәбәбе, әлбәттә, дөнья малы, дөнья малына кызыгу, яңа фатир, йорт, машина, телевизор, телефон һәм башкалар. Шушы дөнья малы өчен Ахирәтебезне сатабыз. Безнең нәфесебез гаҗәеп комсыз заманга буйсынган, безгә һаман нәрсәдер җитми, һәрвакыт зарланабыз, берне алсак – ике кирәк. Икене ала башласак - ул да җитми, аз икән. Яшәр өчен 100-150 кв.метрлы йорт-җиребез бар – сыймыйбыз, җәмәгать! Йөрер машинабыз бар – ошамый, чит ил машинасы кирәк. Булганына шөкер кылу тиешле. Малың җитми икән – тәкъдиреңә риза булып, Аллаһы Тәгаләгә дога кылырга кирәк.

1 Имам Табәрани, әл-Мугҗәм әл-кәбир.

2 Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

«Йә, Раббым! Ризыгымны арттыр!» – дип дога кылу, әлбәттә, бер банктан-икенче банкка йөгерүдән бик күпкә әйбәтрәк, бәрәкәтлерәк. Берәүләребез мохтаҗлык белән сыналса, икенчеләребез байлык белән сыналалар. Бу сыналулар икесе дә тигез дәрәҗәдә авыр булыр, чөнки нәфескә һаман җитми, мал җыюдан туктый алмыйбыз. Ә бит малны арттыруның диндә бик «отышлы» ысуллары да бар – садака бирү, ятим-мохтаҗларга ярдәм итү һ.б. бернинди рибасыз кертем. Шушы садака белән Аллаһы Тәгалә дөньялыкта да ризыгыбызны арттыра, Ахирәттә дә бу кертемне бернинди бөлгенлеккә төшү дә, кризис та киметми. Ә бүген рибага, кредитка баткан җәмгыять зур борчуда торалар: һәр айда вакыты, көне җиткән саен ничек кенә алган акчаны банкка кайтарырга.

Чын, тугры мөселманнарда кредит та, кризис та юк, чөнки алар хак мөселман булганнарына шөкер итеп яшиләр, булмаган чакта кайгыга батмыйлар, сабыр итәләр, урлашуга, башка харам юлларга бармыйлар, бары бер Аллаһы Тәгаләдән генә сорап, догада булалар. Мөселман җәмгыяте шуның белән яши. Авыр, кыен чакларда бер-беребезгә ярдәм итеп, шөкер кылып Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтле колларыннан булырга барыбызга да насыйп булсын.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Гали хәзрәт Җиһаншин,*

*Югары Ослан районы мөхтәсибе*

*3 апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Бәраәт кичәсе

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъд: барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз, хәмде-сәналарыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә һәм дә салават-шәрифләребез Аның сөекле хәбибе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән, мөселманнарга һидаять юлын күрсәткән Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде. Аның әһле бәйтенә, сәхабәләренә, табигыйн һәм тәбге-табигыйннарга, галим-голәмәләргә, имамнарга, остазларга, шәехләргә, ислам юлында булган бәндәләргә Аллаһының рәхмәте һәм мәгъфирәте иңсен. Безгә тәүфыйк-истикамәттә булып, шөкерана кылучылардан булырга насыйп итсен.

Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Без раҗәб белән Рамазан ае уртасында булган мөбарәк ай – шәгъбан аена аяк бастык. Бу айда мәртәбәле Бәраәт кичәсе бар. Аны «ләйләтел-Бәраәт» дип атыйлар. «Ләйләтел-Бәраәт»нең мәгънәсе «пакьләнү», «бурычтан вә җәзадан котылу» дип аңлатыла. Гарәп телендә әлеге мөбарәк кичәне «ләйләтел-мөбарәкә», «ләйләтел-гуфран», «ләйләтел-бәра», «тәкфир» дип тә йөртәләр. Моның хакында элеккеге китаплардан укып белергә, шәех һәм хәзрәтләрнең сүзләреннән ишетергә мөмкин. Гарәпләрнең гадәте буенча бик кыйммәтле әйберләрне генә төрле күркәм исемнәр белән бизәп әйтә торган иделәрэ. Аларның мондый мәкале билгеле була: «күп исемле була торган зат – шәрәфле, дәрәҗәле була».

Әлеге айның мөселманнар тарихында фазыйләтләре бик күп, хәдистә болай дип әйтелә:

Имам Әт-Тирмизи Гайшә радыяллаһу ганһәнең әлеге сүзләрен риваять итә: «Бер кичне Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлламне югалтып, аны эзләргә чыктым, ул Бәкыйгъ дигән зиратта иде. Аллаһы Илчесенең янына килгәч, ул миңа: «Йә, Гайшә, әллә син Аллаһы сиңа һәм Үзенең пәйгамбәренә зарар китерер, дип курыктыңмы», – диде. Мин: «Син башка хатыннарың янына киткәнсең, дип уйладым», – дип әйттем. Шуннан соң пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый сүзләр әйтте: «Дөреслектә шәгъбан аеның уртасындагы кичтә Аллаһы Тәгалә Бәни Киләб кабиләсе сарыкларының йоннары санынча кешеләрне җәһәннәмнән азат итәр».

Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгында Гали бине Әбү Талбинең әлеге сүзләре риваять ителә: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Шәгъбан аеның уртасындагы кичен – Бәраәт кичәсен гыйбадәт, намаз белән уздырыгыз. Көндезен ураза тотыгыз, чөнки ул кичне Аллаһы Тәгалә кояш баеганчыга кадәр дөнья галәменә рәхмәт индерә һәм болай дип әйтер: «Гафу сораучы юкмы – аны гафу итәрмен, ризык сораучы юкмы – аны ризыкландырырмын, кайгылы вә авыру кеше юкмы – аңа шифа бирермен. Моннан башка нинди теләкләре булса, сорасыннар – бирермен. Һәм бу хәл таң атканчыга хәтле дәвам итәр».

Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәллам мондый нәсыйхәт бирә: «Бәраәт сезнең өчен зур форсаттыр, бик күп мөмкинлекләр бирә торган изге кичтер. Кадер кичәсе Бәраәт кичәсеннән зуррак булса да, кайчан булганы төгәл билгеле түгел. Шуңа күрә Бәраәт кичендә күбрәк гыйбадәт кылыгыз».

Бүгенге көндә кайбер кешеләр, бу бидгать гамәл дип куркыныч сүзләр әйтәләр. Бу рәвешле фикер йөртүче сахих хәдисләргә каршы чыга, хакыйкатьне инкяр итә. Мондый сүзләр әйтүчеләр белә торып Пәйгамбәребез

галәйһиссәламгә яла яккан кебек була. Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Кем беләә торып миңа яла яга, шуның урыны җәһәннәмдә булсын», – дип әйткән. Имам Әхмәдтән: «40 мең хәдисләр тупланган җыентыгы турында, сезнең китабыгызда зәгыйфь хәдисләр бармы?» – дип сорадылар. Ул: «Әйе бар, мин аларны махсус калдырдым, чөнки башка риваятьләрдә аларның сахихлыгын исбатлый торган хәдисләр килергә мөмкин», – дип әйтте.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةٍ مُّبَارَكَةٍ ۚ إِنَّا كُنَّا مُنذِرِينَ ﴿٣﴾ فِيهَا يُفْرَقُ كُلُّ أَمْرٍ حَكِيمٍ ﴿٤﴾ أَمْرًا مِّنْ عِندِنَا ۚ إِنَّا كُنَّا مُرْسِلِينَ ﴿٥﴾

**«Без ул Коръәнне мөбарәк Кадер кичәсендә иңдердек, Без Коръән белән имансызларны «куркытучы» булдык. Ул Кадер кичәсендә киләсе елга хәтле булачак эшләр хөкем ителер, ягъни тумак, үлмәк, ризык вә дөньядагы башка булачак вакыйгалар тәгаен ителер. Һәр әмер хикмәт буенча Безнең хозурыбызда хасил булган хәлдә, Без ул көндә мөэминнәргә фәрештәләр җибәрер булдык».**

«Духан / Төтен», 44:3-5

Мөбарәк кичләрнең берсе – Бәраәт кичендә Аллаһының рәхмәте белән кыйбла юнәлеше Бәйт Әл-Мәкъдистән Кәгъбәтуллага күчкән.

Шушы айда Расүлебез галәйһиссәлам күпләп ураза тотты. Ул бу көндә күп кешенең вакытларын гафиллектә үткәрүен әйтә иде. Пәйгамбәребез: «Раҗәб белән Рамазан арасындагы айда кешенең кылган гамәлләре Аллаһы хозурына күтәрелә. Бу вакытта уразалы хәлдә булырга телим», – дип әйткән, үзе шәүвәл аенда ураза тота торган булган. Ул: «Безнең гамәлләребез көненә ике мәртәбә иртә һәм кич, атнасына ике тапкыр:

дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе һәм елга бер тапкыр – шәгъбан аенда Аллаһы хозурына күтәреләө», – дигән.

Гади генә бер мисалга күз салыйк: әйтик, бер патша, миңа бурычлары булган кешеләр билгеле бер вакыт эчендә гафу сорасалар, аларны гафу итәрмен, дип әйтсә, нишләрләр иде икән?

Бу чагыштырыр өчен генә әйтелде. Аллаһы Раббыбыз бу мисаллардан күпкә өстен.

Бу кичтә нинди гамәлләр кылырга?

Бәраәт кичәсендә 12 рәкәгать нәфел намазы укыла. Һәр рәкәгатьтә бер тапкыр «Фәтихә», өч тапкыр «Ихлас» сүрәләре укыла.

Намаздан соң түбәндәге догаларны укырга мөмкин:

1. Ләә иләәһә илләллааһ вәхдәһү ләә шәриикә ләһ. Ләһүл мүлкү вә ләһүл хәмдү, вә һүә галәә күлли шәй иң кадиир. 2. Әстәгъфируллаһүл газыыймә вә әтүбү иләйһи. 3. Аллаһуммә салли вә сәллим вә бәәрик галәә сәийдинә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәд.

Бу кичтә Коръәни Кәрим укып, дога кылу хуп күренә, гореф-гадәтебез буенча өч мәртәбә «Йәсин» сүрәсен уку хуплана. Шушы гадәт бүгенгә хәтле Мисырда да сакланып калган. Бәраәт көнен уразада үткәрү киңәш ителә.

«Бәраәт» догасы:

اَللَّهُمَّ اِنْ كُنْتَ كَتَبْتَ اِسْمِي شَقِيًّا فِي دِوَانِ الْاَشْقِيَاءِ فَامْحُهُ وَ اكْتُبْ فِي دِوَانِ السُّعَدَاءِ وَ اِنْ كُنْتَ كَتَبْتَ اِسْمِي سَعِيدًا فِي دِوَانِ السُّعَدَاءِ فَاثْبُتْهُ فَاِنَّكَ قُلْتَ فِي كِتَابِكَ الْكَرِيمِ يَمْحُ اللَّهُ مَا يَشَاءُ وَ يُثْبِتُ وَ عِنْدَهُ اُمُّ الْكِتَابِ

**Мәгънәсе:** Йә Аллаһым, әгәр мине бәхетсез итеп, исемемне бәхетсезләр дәфтәренә язган булсаң, аны сөртеп юк итсәң иде һәм

бәхетлеләр дәфтәренә язсаң иде. Әгәр мине бәхетлеләрдән итеп, исемемне бәхетлеләр дәфтәренә язган булсаң, әлеге язуны беркайчан да сөртелми торган ит. Чынлыкта, син Коръәни-Кәримеңдә: «Аллаһы Тәгалә нәрсәне теләсә, Ләүһүл Мәхфүздән шуны сөртер, юк итәр, теләгәнен исә беркетер, сөртелмәс итәр», – дип әйтәсең.

Аллаһы Раббым шул күркәм гадәтләрне саклап, бер-беребезгә хәер догада, тынычлык иминлектә яшәргә, бозык фикерләрдән вә бозык эшләрдән Раббым барыбызга да сакланырга насыйп итсен.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

*Габбас хәзрәт Кадыйров,*

*Питрәч районы имам-хатыйбы*

# Фәтвалар

# Иясе бар кабергә икенче берәүне күмү мәсьәләсе

**Сорау: Кайчандыр берәү күмелгән кабергә, билгеле бер вакыт үткәннән соң, икенче кешене күмәргә ярый, дип ишеткәнем бар. Моның хакында динебез нәрсә ди?**

**Җавап:** Фикһ китапларында, кайчандыр бер кеше күмелгән кабергә, күпмедер вакыт үткәннән соң, икенче берәүне җирләргә ярый, дип әйтелгән. Әмма монда, беренче мәетнең гәүдәсе, таркалып бетеп, җир белән кушылган булуы шарт («Әл-Фәтва Әл-Һиндия»).

Кайбер галимнәр, җирләр өчен буш урын булган очракта, кайчандыр кеше күмелгән каберне куллануны мәкруһ хөкемендә, дип әйтә. Әмма, мәетне күмәр өчен, кабер тапмаган очракта, бу рөхсәт ителгән гамәл булып санала.

Мөхәммәд Әмин бине Габидин: «Бүгенге көндә һәрбер кеше өчен аерым каберлек булдыру кыен булганга күрә, мәетне, аңа кадәр башка берәү күмелгән кабергә урнаштырырга мөмкин. Әмма биредә алдан күмелгән кеше гәүдәсенең таралып җир белән катнашкан булуы шарт», – дип әйткән.

Ә менә вакыт мәсьәләсенә килгәндә, монда туфракның үзенчәлеге зур роль уйный. Мәсәлән, Сәгуд Гарәбстанында моны өч елдан соң эшләп булса, Истамбулда, алдан кеше күмелгән кабердә икенче берәүне күмә алыр өчен, биш ел вакыт үтү кирәк. Ә бездә, билгеле булганча, вакытның тагын да күбрәк узуы таләп ителә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*ТР мөфтие*

# «Әәмин» сүзенең әйтелеше

**Сорау: Имам җомга хотбәсен алып барганда, кайбер кеше кычкырып: «Әәмин», – дип әйтә. Бу рөхсәт ителгән күренешме? Хотбә вакытында сөйләшү тыелган, дип белә идем.**

**Җавап:** Хотбә вакытында имам дога кылганнан соң «әәмин» дип әйтү һәм, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен әйткәннән соң, салават уку тыелган гамәл (ул мәкруһ тәхрим хөкемендә). Әмма кешенең «әәмин» сүзен һәм салаватны эченнән генә укуы рөхсәт ителә.

«Раддел Мөхтәр» китабы 1нче томының 606нчы битендә болай дип әйтелгән:

«Әл-Бәккали үзенең «Мохтәсар»ында болай дип яза: «Имам дога кыла башлагач, кешеләрнең кулларын күтәреп «әәмин» дип торулары гөнаһ санала, әмма кайбер галимнәр, алар гөнаһлы булмый, тик алай эшләүләре дөрес түгел, дип әйтә. Чынлыкта, фикерләрнең дөресе булып, беренчесе, ягъни гөнаһлы булуы санала, дип әйтелгән. Бу фикергә һәм шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен әйткәннән соң салаватны эчтән генә әйтүгә дә фәтва бирелгән».

Шулай ук «Әл-бәхер әр-раик» (2нче том), 156нчы бит һәм «Әл-Һиндия»нең (1нче том) 151нче битендә болай дип язылган:

«Галимнәрнең фикерләрендә салават әйтүгә карата ихтиләф барлыкка килде, әмма дөрес фикер: Пәйгамбәребезгә салаватны һәркем эчтән генә әйтергә тиеш». Нәкъ моның хакында «Фәтхел Кадир» китабында да язылган.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*ТР мөфтие*

# Коръән укуга багышлана торган вакытның күләме

**Сорау: Дөрес булсын өчен, динебез буенча Коръән укуга күпме вакыт сарыф итәргә тиешбез? Изге Китапны елга бер мәртәбә генә уку җитәме?**

**Җавап:** Кайбер галимнәр Коръәнне бер көндә укып чыгуны дөрес гамәл түгел, моның өчен, ким дигәндә, өч көн бүлеп бирелергә тиеш, дип саный. Һәм, әгәр дә кеше елына кимендә бер мәртәбә Коръәни Кәримне хәтем кылса, ул Аллаһы Китабына битарафлык күрсәтүче булып саналмаячак.

«Әл-Фәтава Әл-Һиндия» китабында болай дип язылган:

«Коръәннең иң яхшы кыйраәте – кешенең укыган вакытта мәгънәләре турында уйлануы».

Коръәнне бер көн эчендә хәтем кылу мәкруһ санала, Аллаһы Китабы өч көннән дә әзрәк вакыт эчендә укылмый. Галимнәрнең бу мәсьәләдәге иҗмагы «Әл-Кунйә» китабында язылган.

«Әс-Сираҗия» китабында әйтелгәнчә, Коръәнне җәйге вакытта – көн башында, ә кышкы вакытта төн башында уку мөстәхәб булып тора.

Кешеләрнең Коръәнне бергәлектә, кычкырып укулары мәкруһ санала, чөнки бу очракта Китапка күрсәтеләсе игътибар юкка чыга. Моның хакында шулай ук «Әл-Кунйә» китабында әйтелә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*ТР мөфтие*

# Үрнәк затлар

# Пәйгамбәребезнең әнисе Әминә радыяллаһу ганһә

«Әгәр син булмасаң, әй, Мөхәммәд, күкләрне бар кылмас идем», – дип мәртәбәле булган; Хак Тәгаләдән:

وَلَسَوْفَ يُعْطِيكَ رَبُّكَ فَتَرْضَىٰ ﴿٥﴾

**«Тиздән синең Раббың морадыңны бирер, риза булырсың», – дип сөенеч ишеткән;**

«Духа / Иртән», 93:5

Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә:

فَوَلِّ وَجْهَكَ شَطْرَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ ۚ ﴿١٤٩﴾

**«Йөзеңне мәчет тарафына юнәлдер»,** – дип Кәгъбәтулланы кыйбла иткән;

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:149

Хак Тәгаләдән:

أَلَمْ نَشْرَحْ لَكَ صَدْرَكَ ﴿١﴾

**«Әй, Мөхәммәд, күкрәгеңне раушан нурлы кылмадыкмы»,** – дип нигъмәтләнгән;

«Инширах / Ачмак», 94:1

وَوَضَعْنَا عَنكَ وِزْرَكَ ﴿٢﴾ الَّذِي أَنقَضَ ظَهْرَكَ ﴿٣﴾

**«Әй, Мөхәммәд, синең аркаңа авыр булган киемне куйдык, ягъни аркаңнан төшердек»,** – дип әйтү белән җиңеллек тапкан;

«Инширах / Ачмак», 94:2-3

Хак Тәгаләдән:

وَرَفَعۡنَا لَكَ ذِكۡرَكَ ﴿٤﴾

**«Сине зикер итүне күтәрдек», –** дип кәрамәт бирелгән.

«Инширах / Ачмак», 94:4

Аллаһы Тәгаләнең хәбибе (ярактканы), гөнаһлы өммәтләрнең гөнаһысының табибы, пәйгамбәрләр хуҗасы, Кыямәт көненең шәфәгатьчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмдер.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Хак Тәгалә галәмне, ягъни оҗмах, тәмугны, җир һәм күкне, Гареш һәм Көрсине һәм башкаларны яратырга, бар кылырга теләгән заманда, Үз нурыннан бераз нур алып, нурга: «Хәбибем Мөхәммәд бул», – диде». Икенче риваятьтә: Хак Тәгалә җир һәм күкне бар кылырга теләгән заманда, Үзенең нурыннан бераз нур алып, нурга әйтте: «Әй, нур, син хәбиб, ягъни дустым Мөхәммәд бул». Ул нур Адәм галәйһиссәлам яратылудан әүвәл биш йөз ел элек Гарештә: «Әлхәмдүлилләһ», – дип тәваф кылыр иде. Хак Тәгаләгә бу хәмедне әйткәне өчен, Мөхәммәд дип исем кушты. Аннан соң Мөхәммәд галәйһиссәлам нурыннан Адәм галәйһиссәламне бар кылды. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәнен Адәм галәйһиссәлам балчыгыннан яратты. Моннан соң Мөхәммәд галәйһиссәламнең нурын Адәм галәйһиссәлам аркасына куйды. Ул нур Адәм галәйһиссәламнән Хәвва анага күчте. Шулай, атадан анага күчеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иреште.

## Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм нәселенең бәяне

Сәедебез, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы – Габдулла, аның атасы Габделмотта-

либ иде. Габделмотталибның дөрес исеме – Шибәтүл-хәмед, чөнки Габделмотталибның туган вакытында башында ак төкләре бар иде. Габделмотталибның атасы – Һәшим, чын исеме – Гамру, аның атасы – Габделмәнәф, чын исеме – Могыйра, аның атасы – Кусай, чын исеме – Мөҗәммигъ, аның атасы – Кәлаб, чын исеме – Хәким, Мәрра – Кәгеб улы, Кәгеб – Лүәй улы, Лүәй – Галиб улы, Галиб Фәһернең улы, Фәһернең чын исеме – Кораеш, Кораеш – Мәлик улы, Мәлик – Нәзар улы, Нәзар – Кинәнә улы, Кинәнә – Хозәймә улы, Хозәймә – Мөдрикә улы, Мөдрикә – Ильяс улы, Ильяс – Мәдар улы, Мәдар – Нәзар улы, Нәзар – Мәгъдә улы, Мәгъдә – Гадьнән улы, Гадьнән – Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән. Әмма Гаднәннән Исмәгыйль галәйһиссәламгә кадәр фәлән фәләннең улы дип билгеләүдән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тыйды. «Кәзбүн-нисәбүн» дип, ягъни нәсеп итүчеләр ялганлыйлар, дип баш тартып, мәкруһ күрә иде. Шуның өчен Рабгузый риваятенчә зикер итмәдек.

Безгә Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән дип белү дә җитәдер.

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Шам вилаятендә яһүдләрнең галимнәре үзләренең китапларында күрделәр: Яхъя галәйһиссәлам җөббәсеннән кан тамса, шулвакыт Мөхәммәд галәйһиссәламнең атасы дөньяга килер, дип язылган иде. Шул сәбәпле, тикшереп, сорашып, Габделмотталибның улы дөньяга килгәнен белделәр. Габдулла үскәч, аны үтерергә ниятләделәр. Аллаһы Тәгалә аларга фәрештәләр җибәрде, ниятләүчеләрнең барчасын үтерделәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең анасы Әминәнең атасы Вәһһаб, тау башында Яхъя галәйһиссәламнең җөббәсеннән кан тамганын күреп, Габдулла бине Габделмотталибны тәмам белде. Көннәрдән бер көнне Вәһһаб үзенең хатыны Бәррагә: «Әминәне Габдуллага хатынлыкка бирәсеңме?» – диде. Бәрра: «Әйе, бирермен», – диде. Бу заманда Аллаһының хикмәте Габделмотталиб улы Габдулла өчен Вәһһабка яучы җибәрде. Вәһһаб мең шөкер

белән кабул итте. Раҗәб аенда җомга кичне туй иттеләр. Зөфаф шул ук кичтә булып, Әминә йөкле булды. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Бу кичә Корәеш кабиләсендә булган һәр җанвар сөйләшеп, бер-берсенә: «Мөхәммәд бу көнне ана карынына төште», – дип сөенеч бирделәр». «Кәгъбәнең Раббысы белән ант итеп әйтәбез, ул Мөхәммәд – дөньяның иминлегедер, ата-бабасының нурыдыр», – диделәр. Иблис мәлгунь Әбү Кәбис тавына менеп кычкырды. Шәйтаннар: «Ни булды сиңа, әй, хуҗабыз?» – дип янына җыелдылар. Иблис: «Аһ, минем ничә еллар чиккән мәшәкатем, бу көнне Мөхәммәд ана карынына төште, Аллаһы Тәгалә аны үткен кылыч белән җибәрер, диннәрне үзгәртер, потларны сындырыр», – диде. Хисәб бине Сәбит радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Мин җиде яшемдә идем, Мәдинә урамында бер яһүди: «Әй, яһүдиләр, бу кичтә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йолдызы туды», – дип кычкырды. Расүлебезнең әнисе Әминә: «Улым Мөхәммәд белән йөкле булганда башка хатыннар кебек авырлык күрмәдем, ләкин хәез күрүем тукталды. Улым Мөхәммәдкә йөкле булгач бер нур күрдем, мәшрикъ һәм мәгъриб яктырды, хәтта Шам вилаятендә Басра шәһәренең сарайларын күрдем. Йөкле булуымның беренче аенда озын буйлы бер кеше төшемә керде: «Сөенеч сиңа, пәйгамбәрләр хуҗасы белән йөкле булдың», – диде. «Син кем?» – дип сорадым. «Атасы Адәм пәйгамбәр», – диде. Икенче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, әүвәлге һәм ахыргы кавемнең хуҗасы белән йөкле булдың», – диде. Ул Шис галәйһиссәлам иде. Өченче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, хөрмәтле пәйгамбәр белән йөкле булдың», – диде. Ул Нух галәйһиссәлам иде. Дүртенче айда янә бер кеше күрдем: «Сөенеч сиңа, шәрифле хуҗа белән йөкле булдың», – диде. Ул Идрис галәйһиссәлам иде. Бишенче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, адәмнәрнең хуҗасы белән йөкле булдың», – диде. Ул Һуд галәйһиссәлам иде. Алтынчы айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, Һәшим ыруыннан килүче пәйгамбәр белән йөкле

булдың», – диде. Ул Ибраһим галәйһиссәлам иде. Җиденче айда бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, галәмне тәрбия кылучы Аллаһы Тәгаләнең дусты белән йөкле булдың», – диде. Ул Исмәгыйль галәйһиссәлам иде. Йөклелекнең җиденче аенда Багдад шәһәрендә Кесәри патшаның сарае түбәсендә манараларының ундүрт гөмбәзе төште. Сигезенче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, тәхкыйк, ахырзаманның соңгы пәйгамбәренә йөкле булдың», – диде. Ул Муса галәйһиссәлам иде. Бу сигезенче айда мәҗүсиләрнең гыйбадәт кыла торган утлары сүнде. Яхъя Сәрәри радыяллаһу ганһе әйтте: «Мәҗүсиләрнең бу утлары мең елдан бирле сүнмичә яна иде». Тугызынчы айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, Мөхәммәдкә йөкле булдың», – диде. Ул Гайсә галәйһиссәлам иде», – диде.

Мәшһүр риваятькә нигезләнеп әйтелгәнчә, Әминә радыяллаһу ганһә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән йөкле булганның икенче аенда, Габдулла атасы Габделмотталибның йомышы белән барган иде, шунда вафат булып, Мәдинәдә күмелде. Атасы үлгәч, фәрештәләр: «Йә, Раббым, пәйгамбәрең ятим булып калды», - дип әйтте. Аллаһы Тәгалә болай дип җавап бирде: «Мин аның саклаучы Хуҗасы һәм җиңү бирүчедер». Әминә радыяллаһу ганһә: «Улымның туу киче җиткәндә дүшәмбе кич таң алды иде. Күктән бер төркем җәмәгать төште. Аларның өч әләме бар иде: берсен – Кәгъбәтулланың өстенә, икенчесен – үз йортымның түбәсенә, өченчесен Бәйт Әл-Мөкаддәскә кададылар. Йолдызлар шулкадәр якын килде, хәтта үземә төшәр, дип уйладым. Күк ишекләрен тәмам ачык күрдем. Моннан соң өемнең эче зөбәрҗәт борынлы кошлар белән тулды. Дөнья яп-якты булды. Күк белән җир арасында ефәк палас түшәлгән итеп, шулай ук һавада кулларына алтын тоткалы көмеш комганнар тоткан ир кешеләрне күрдем. Шул заман сусадым, шул комганнарның берсеннән су эчтем. Үзем уйлап ятамын, ялгызлыктан күңелем зарыкты, шулчак яныма бер төркем хатын-кыз керде. Шулкадәр

матурлар, берсе Асия иде, ул да ярдәм итте. Тулгаклап эчем авыртты, бер кош килеп, канаты белән корсагымны сыйпады, шулчак улым Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тудырдым, мөбарәк ике аягы белән туды, ягъни йөзтүбән тумады. Бу анының Аллаһы Тәгалә хөкемендә туры булуына ишарә иде. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм тугач, теле белән: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр кәбиран, Әлхәмдү лилләһи Раббилгааләмиин», – диде.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе атасы Габбас радыяллаһу ганһедән, ул үз атасы Габделмотталибтан риваять кылып әйтте: «Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм анасыннан сөннәтле һәм кендәге киселгән булып туды». Риваятьләрдә әйтелгәнчә, сөннәтле булып дөньяга килгән пәйгамбәрләр: Адәм галәйһиссәлам, Шис галәйһиссәлам, Идрис галәйһиссәлам, Нух галәйһиссәлам, Лут галәйһиссәлам, Йосыф галәйһиссәлам, Муса галәйһиссәлам, Шөгаеб галәйһиссәлам, Сөләйман галәйһиссәлам, Яхъя галәйһиссәлам, Гайсә галәйһиссәлам, Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм иде».

Әминә радыяллаһу ганһә болай дип әйтте: «Мөхәммәд галәйһиссәламне тудыргач, айга охшаган бер кеше улымны алып китеп, бер сәгать юк булып торды. Моннан соң яныма китереп: «Улыңны ал, бер сәгать мәшрикъ һәм мәгърибкә тәваф кылды, Адәм галәйһиссәлам янына барды, Адәм галәйһиссәлам ике күзе арасыннан үбеп: «Сөенеч сиңа, әй, минем дустым, син әүвәлге һәм ахыргы балаларымның хуҗасы», – диде. Моннан соң янә бер кешене күрдем, ул: «Әй, дөньяның хөрмәтлесе, Ахирәтнең шәрифлесе, беркем синең сүзеңне сөйләсә, синең шәһадәтең белән шәһадәт бирсә, Кыямәт көнне синең гыйлемең астында булыр», – диде. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе мондый сүзләр әйтте: «Ул оҗмах сакчысы Ридван иде. Аллаһының әмере белән Расүлуллаһның аркасына пәйгамбәрлек мөһерен ул басты». Габделмотталиб Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең дөньяга туу вакыйгасын бу рәвешле тасвирлый: «Мин

ул кичтә Кәгъбәтуллада идем. Кәгъбә авышып, мәкам Ибраһим тарафына сәҗдә кылды. Потлар куйган урыннарыннан егылып төштеләр. Кәгъбәтулладан: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, гөнаһлардан пакь булучы туды. Мөхәммәд галәйһиссәлам мине Раббым мөшрикләрнең нәҗесеннән пакь кылды», – дигән тавыш ишеттем. Әминә Мөхәммәд галәйһиссәламне тудыргач, аның хозурына рәхмәт болытлары түгелде, дип сөйлиләр. Әминәнең өенә килдем, аның өен болыт каплаганын күрдем. Йокымы, уяулыкмы, дип күземне сөртәмен. Ишектән: «Әминә, ишекне ач», – дип кычкырдым. Ишекне ачу белән җофар исе борыныма тулды. «Йә, Әминә, ни хәлең бар?» – дидем. Әминә: «Мөхәммәдне тудырдым», – диде. «Кайда ул, күрим», – дип бүлмәгә керергә теләдем. Шулчак бер адәм чыкты, кулында ялангач кылыч иде: «Сабыр ит, кермә, фәрештәләр күрешсеннәр», – диде» («Нәзһәтүл-мәҗәлис»).

Әминә радыяллаһу ганһә үзе болай дип сөйли: «Мөхәммәдне тудыру кичендә өйнең түбәсе күтәрелде, һавада шулкадәр матур кызлар күрдем, матурлыкта тиңдәшләре юк. Габделмәнәф кызларына охшаганнар. Гаҗәпсенеп карап торганда, берсе: «Кайчанга кадәр гаҗәпсенеп карарсың. Без барчабыз да синең хезмәтчеләрең. Гаден җәннәтеннән сиңа хезмәт итәргә килдек», – дип әйттеләр. Акылымнан яздым, һушыма килгәч, баламны тудырган идем. Улымның бер кулын күзенә, икенче кулын ят әгъзасына куйганын күрдем, шул хәлдә сәҗдә кылды. Колагымны салып тыңладым. «Өммәтем, өммәтем», – дип әйтә иде. Шулвакыт күземнән югалды. Кая киттең улым, дип торганда, бер ак болыт улымны китереп, яныма куйды. Улымны юганнар, күзенә сөрмә тартылган, хушбуй сипкәннәр һәм ефәккә чорнаганнар. Шулвакыт Гатикә кереп: «Әй, Әминә, ни хәлең бар?» – диде». Әминә булган хәлләрнең барысын да сөйләп бирде. Гатикә әйтте: «Сөйгәнемнән сикереп тордым, кайда ул Мөхәммәд дип, кулыма алып кочакладым. Шулкадәр хушбуйлы, андый ләззәтле хушбуй күргәнем юк иде. Йөзен ачып карадым, әйтерсең, тулган ай иде. Ул төн

шундый төн иде, дөньяның әүвәленнән ахырынача андый төн булмады. Кәгъбәдә өч йөз алтмыш пот бар иде, барчасы җиргә төштеләр».

Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөньяга килгәнче, шәйтаннар һәм җеннәр күккә менеп, фәрештәләрнең сүзләрен тыңлап, ишетеп, багучыларга, сихерчеләргә хәбәр бирделәр. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган кичәдә, гадәттәгечә, күккә менәргә теләгән вакытларында, Хак Тәгалә шәйтаннарны, җеннәрне йолдызлар белән атарга әмер итте. Күккә менә алмадылар, кайгырып иблис мәлгунь янына җыелып: «Ни булды икән, бу кич безне күккә җибәрмәделәр?» – дип сорадылар. Иблис мәлгунь: «Бүген Аллаһының якын фәрештәләренең күктән иңгәннәрен күрдем, барыгыз, бер хәбәр китерегез», – диде. Шәйтаннар Мәккә тарафында бер нур күрделәр, яктылыгы һавага күтәрелгән. Якын килделәр исә, Мәккәи-Мөкәррәмә турысында фәрештәләр һавада сафка тезелеп торалар, шулкадәр күп, хәтта энә чәнчер урын юк. Шәйтаннар нинди хәбәр икән, дип якын килсәләр, фәрештәләр утлы чукмарлар белән кудылар. Иблискә килеп, күргәннәрен сөйләделәр. Иблис мәлгунь: «Аһ», – дип кычкырды. Шәйтаннар: «Йә, хуҗабыз, ни өчен бу кадәр кайгырасың?» – диделәр. Иблис: «Минем өчен бу төннән каты төн юк, минем мең еллык мәшәкатемне аның сәясәте югалтыр, күккә чыга алмавыгызның һәм Мәккә өстендә фәрештәләрнең тору сәбәбе – ул ахырзаман пәйгамбәре дөньяга килү сәбәбедер. Аның шәригате барча пәйгамбәрләрнең шәригатен үзгәртер. Бер адәм мең яисә ун мең ел азгынлыкта йөреп, мөшрик булса, бер сәгать ул пәйгамбәрнең диненә кереп, тәүбә-истигъфар кылса, барча гөнаһысы гафу ителер. Аның өммәтеннән бер адәм гомере буенча азгынлыкта, бозыклыкта булса, берзаман моңа үкенеп салават әйтсә, барча явызлыклары урынына изгелек язылыр, бөтен гөнаһысы ярлыканыр, рәхмәткә лаек булыр. Бу шундый пәйгамбәрдер: Кыяматтә гөнаһлы өммәтләренә шәфәгать кылып, тәмугтан коткарыр», – дип әйтте.

Габделмотталиб пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына кергәннән соң, чын пәйгамбәрне күрде. Мөхәммәд галәйһиссәлам бабасын күреп, имән бармагын күтәреп, кәлимәи шәһадәт әйткән кебек ишарәләде. Габделмотталиб бу кәраматләрне күреп бик шатланды. Кулына күтәреп, Кәгъбә шәрифкә алып керде. Ихлас нияте белән Аллаһы Тәгаләгә мондый бала биргәне өчен шөкер итеп, дога кылды. Җиде көннән соң Мөхәммәд дип исем куштырып, Мәккә халкын җыеп сыйлады, кадер-хөрмәт кылды.

Мөхәммәд дип исем бирүенең сәбәбе бу иде: Әминә радыяллаһу ганһәгә төшендә бер фәрештә килеп: «Әй, Әминә, син барча мәхлүкъларның хуҗасына йөкле булдың, аны тудырсаң, Мөхәммәд дип исем куш, чөнки ул галәмнәрнең хуҗасы бик макталган булыр. Әй, Әминә, Мөхәммәд галәйһиссәламне тудырганда күп гаҗәп эшләр күрерсең. Күргән гаҗәпләрне адәмнәргә сөйләмә һәм бу бөтине Мөхәммәд галәйһиссәламгә так», – диде. Шул заман уянып киттем, баш астында бер алтын кәгазь таптым, анда болай дип язылган иде:

«Үгизүһү бил-вәхиди мин шәрри күлли хәсиди вә күлли халькин раиди мин каими вә кагыйди ганис-сәбили хәиди гамәл-фәсәди җәһиди мин нәфиси әү гакиди вә күллә халькин мәриди йәәхүзү бил-мәрасиди мин турукинил-мәүәриди».

Әминә төшендә күргән фәрештәнең «Мөхәммәд исемен куегыз» дигән сүзен Габделмотталибка әйтте. Габделмотталиб балага Мөхәммәд дип исем бирде.

*«Кыйсасел әнбия» китабыннан*

# Фән

# Шәригать хөкемнәре

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим**

## Мәкруһ тәхрими (тыю) вә харам зани (ачык булмаган) гамәлләр

Мәкруһ шул гамәлдер ки, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам ул гамәлне кылудан тыя иде. Мөэмин-мөселман булган кешегә аны кылу да дөрес түгелдер. Мәкруһ гамәлне гөнаһыдан куркып кылмый калган кеше саваплы булыр, кылган кеше гөнаһлы булыр. Каршылык илә мәкруһны кылу дөрес дигән кеше, имансыз булмаса да, гөнаһлы булыр. Мөэмин вә мөселман булган кешегә кылу мәкруһ булган гамәлләрнең мәшһүрләре ошбулардыр:

1. Отышмыйча отыш уеннары уйнап, бушка гомер уздыру.
2. Гыйлемгә теләге булмаган кешегә гыйлем өйрәтү.
3. Коръәннән күңелгә бикләнгән сүрә вә аятьләрне тәкрар кылмыйча (кабатламыйча) оныту.
4. Коръәнне шөгыльле вә эшле кеше янында уку.
5. Коръән сүрәләре вә аятьләр язылган кәгазьләрне вә дин китапларын кадерсез урынга кую.
6. Аять яки башка яхшы сүзләр язылган кәгазьләрне утка яндыру, гәрчә тузган булса да.
7. Җөнеб кеше, хәезле вә нифаслы хатын, вә тәһарәтсез кешегә Мөсхәф шәрифне – Коръәнне тоту, әмма букчада килеш тоту мәкруһ түгелдер.
8. Җөнеб кеше, хәезле вә нифаслы хатынга Коръән аятьләрен уку, тәһарәтсез кешегә Коръән уку дөрестер, вә дәхи җөнеб кеше, вә хәезле, вә нифаслы хатыннарга һәртөрле догаларны уку дөрестер.
9. Җөнеб кеше вә тәһарәтсез кеше азан вә камәт уку.

10. Җөнеб кеше, хәезле вә нифаслы хатынга мәчет эченә керү.

11. Мәчеттә дөнья сүзләрен сөйләшү.

12. Мәчеттә дөнья эшләрен кылу.

13. Мәчеттә алдагы сафларга басу өчен, кешеләр арасыннан атлау.

14. Мәчеттә бармакларын аралаштырып йә шартлатып, сакал-мыеклар белән уйнап, әдәпсез рәвештә утыру.

15. Мәчеттә тешләрен, борынын вә колакларын казып утыру.

16. Мәчеттә кычкырып иснәү вә төчкерү.

17. Мәчеттә имам хотбә укыган вакытта, вә вәгазь сөйләгән вакытта, хотбә вә вәгазьне тыңламыйча, башка сүзләр сөйләшеп утыру.

18. Җомгада хотбә укылган заманда җомганың сөннәтләрен яки башка бер нәфел намазы уку, әгәр дә хотбә башланганчы намазга керешкән булса, аны тәмам кылу дөрестер.

19. Мәчет эчендә төкерү, какыру вә борын сеңгерү, тәкәббер кыяфәттә олугланып утыру.

20. Намаз укый торган кешенең алдыннан йөрү, пәрдәсе булмаса.

21. Азан укыган заманда, кешегә сәлам бирү йә сәлам алу.

22. Азан укыган заманда, дөнья сүзләрен сөйләшү, дөнья эшен эшләү.

23. Ният кылып керешкән нәфел намазын вә нәфел рузасын гозерсез бозу.

24. Кунак килү йә кунакка чакыру сәбәпле, өйлә вакытына кадәр нәфел рузасын бозу дөрестер.

25. Намаз уку мәкруһ булган вакытларда, ягъни кояш чыккан вакытта һәм кояш төш вакытына килеп җиткән вакытта, вә дәхи кояш баеган вакытта намаз уку.

26. Таң атканнан соң кояш чыкканчы вә икенде вакыты кергәннән соң кояш баеганчы нәфел намазы уку, ошбу ике вакытта казага калган намазларны уку дөрестер.

27. Фәкать җомга көн йә шимбә көнне хаслап нәфел рузасы тоту.

28. Бер көн руза тотканнан соң, кич һичбер ифтар кылмыйча, икенче көн руза булу.

29. Хатынның иренең рөхсәтеннән башка нәфел рузасы тотуы.

30. Гарәфә, гает вә тәшрикъ көннәрендә гомрә хаҗын үтәү.

31. Үзенең имам булуын яратмаганлыкларын белгән кешегә намазда имам тору.

32. Җөнеб булган кеше, тәһарәт алмыйча, аш ашау.

33. Ашны йә эчемлекне сул кул белән тотып ашау йә эчү.

34. Яланбаш көенчә ашау йә эчү.

35. Бер аш мәҗлесенә чакырылмыйча барып керү.

36. Иясе күңеленнән риза булмаганлыгын белә торып, кеше ашын ашау.

37. Аш мәҗлесендә башка кешенең алдыннан алып ашау.

38. Ашны вә суны өреп суыту.

39. Ашны олугламыйча тоту.

40. Бу ризык каты булган, йә йомшак булган, пешмәгән, ачы булган дип, тәгамне гаеп итү.

41. Икмәкне вә башка тәгамне борынга куеп иснәп карау.

42. Икмәкнең өстенә пычак йә тоз савыты кебек бер нәрсә кую.

43. Икмәк сыныгын табак астында калдыру.

44. Икмәккә пычак йә кул сөртү.

45. Икмәкне бер кул белән сындыру.

46. Тәкәбберлек кыяфәте белән таянып утырып, йә кырын ятып ашау.

47. Аяк өстендә көенчә аш ашау йә су эчү.

48. Мәҗлестәге ашны, хуҗасының рөхсәтеннән башка, алып китү.

49. Йөзтүбән ятып ашау.

50. Аш мәҗлесендә әшәке вә җирәнгеч сүзләр сөйләү.

51. Табыннан аш алынганчы урыныңнан тору.

52. Табынга бер урынга килеп утырган кешене кузгатып, аның урынына утыру.

53. Аш хәзерләмичә туй вә никах туе кылу.

54. Бер кеше зәм-зәм суы, сөт йә хуш исле бер нәрсә биргәндә, кирәк түгел дип алмый калу.

55. Аш әзер булып, өстәлгә куйганнан соң ашамыйча, ашны көттерү.

56. Тәнгә зәгыйфьлек китерә торган нәрсәләрне ашау.

57. Янда аять язылган кәгазьләр вә догалы бөтиләр илә бәдрәфкә керү.

58. Өй эчендә нәҗес хаҗәтләрне үтәү.

59. Бәдрәфкә яланбаш көенчә керү.

60. Гозерсез аяк өстендә көенчә хаҗәтне үтәү.

61. Мәчет вә кабергә кырык адымнан якынрак җирдә хаҗәтне үтәү.

62. Бәдрәфтә тәһарәт алу һәм госел кылу.

63. Уң кул белән истинҗа кылу.

64. Бәдрәфтә нәҗесеңә карау.

65. Бәдрәф кебек күңел каралта торган урында зарурсыз озак утыру.

66. Су өстенә хәҗәтне үтәү, ягъни нәҗесне пакь суга төшерү.

67. Җимешле вә күләгәле агач төбенә, юл йә чирәм өстенә хаҗәтне кылу.

68. Кеше күзе алдында хаҗәтне кылу.

69. Бәдрәфтә кыйблага каршы йә аркаң белән утыру.

70. Ачык җирдә айга йә кояшка каршы, йә арка белщн утырып хаҗәт кылу, әмма ай белән кояш үзләре күренмәсәләр, зарары юктыр.

71. Бәдрәфтә хаҗәт кылганда, сүз сөйләшү.

72. Уң кул белән истибра кылу.

73. Азан укыган вакытта хаҗәт кылу.

74. Кәгазь, үлән, яфрак кебек кадерле нәрсәләр белән истибра кылу (сөртү).

75. Кеше алдында истибра кылып йөрү.

76. Истибра кылып торган кешегә сәлам бирү.

77. Уң кул белән борын сеңгерү.

78. Заруратсыз уң кул белән өртелү җирләрне тоту (оят җирләр).

79. Кеше арасында гозерсез җил чыгару.

80. Кырмыска кебек кечкенә хайваннарның ояларына хаҗәт кылу.

81. Нәҗес нәрсәләрне юлга вә урамга ташлау.

82. Бәдрәфтә сәлам бирү йә алу.

83. Сәлам бирмәс борын, сүз сөйләшә башлау.

84. Имансыз кешегә беренчеләрдән булып сәлам бирү.

85. Бер харам вә гөнаһ эшне кылып торучыга сәлам бирү.

86. Мыекның борын турысындагы җирләрен авызга керерлек кадәр итеп йөртү.

87. Хатыннар чәчләрен кыскарту.

88. Сакалдан, мыектан һәм чәчтән агарган төкләрне йолку.

89. Йөзеңнән вә каш арасыннан төкләрне йолку.

90. Ирләрнең сакал-мыек вә чәчләрен карага буяу.

91. Ирләр кулына кына ягыну.

92. Җөнеб көенчә чәч китәртү.

93. Җөнеб көенчә, хәезле вә нифаслы хәлдә тырнак кисү.

94. Тырнакны теш белән китеп алу.

95. Тырнагын озын итеп җиткереп, кырык көн кадәр кисмичә тору.

96. Алырга тиешле төкләрне касыктан һәм култык астыннан кырык көн кадәр алмыйча йөрү.

97. Тырнакларны вә төкләрне кадерсез җиргә ташлау.

98. Хатыннар чәченә чәч ялгау.

99. Матур вә кечкенә булып күренсен өчен, тешне игәүләү.

100. Хатыннарның гомуми базар мунчасына бару.

101. Хатыннарның урамга, тышкы яктан яхшы вә зиннәтле киемнәр киеп чыгуы.

102. Тәнгә, тире астына, төрле бизәк төшерү.

103. Хатыннарга хәләл ирләреннән вә кардәшләреннән башка сәфәргә чыгу.

104. Гәрчә ышанмаса да, киләчәктәге эшне багучыга каратып карау, әмма аның киләчәктән хәбәр биргән сүзенә ышану харамдыр.

105. Зарур булмаган урында Аллаһы Тәгаләнең исемен куллану.

106. Сатучы малының яхшылыгы хакында ант итү, гәрчә яхшылыгы хак булса да.

107. Имансыз кешеләр генә кия торган киемнәрне киеп йөрү.

108. Сабый ир балаларга ефәк киемнәр кидерү.

109. Кием-салымны нәҗесле вә пычрак көенчә киеп йөрү.

110. Кеше гаҗәпсенеп көләрлек, бик яхшы йә бик начар киемнәр киеп йөрү.

111. Чалбар балагын тәкәбберлек өчен, тубыктан түбән салындырып йөрү.

112. Үлсәм иде дип, үлем теләп дога кылу.

113. Дөньяда бик озак торып, күп эшләр кылуны уйлап йөрү.

114. Ваба вә тир хастасы кебек йогышлы авыру булган шәһәрдән, авырудан качып чыгып, икенче шәһәргә китү, чөнки Аллаһы Тәгаләнең казасыннан качу вә авыруны тарату ихтималы бардыр.

115. Ваба вә тире хастасы кебек йогышлы вә хәвефле авыру булган шәһәргә барып керү.

116. Йогышлы авырулы кешегә өч аршыннан артык якын килү.

117. Мәетнең яхшылыкларын әйтеп, мактый-мактый артыннан кычкырып елап бару.

118. Үз сүзен аста калдырмас өчен, хак сүзгә каршы килү.

119. Хакыйкатьне белмичә, үзе кылган эшне хак сүз иттереп сөйләү.

120. Үзендә булмаган яхшылыклар белән мактану.

121. Бер кешене, ул кешенең үзендә булмаган яхшылык илә, арттырып мактау.

122. Кеше көлдерү өчен, ялган сүзләр катыштырып, уен-көлкеле сүзләр сөйләү.

123. Кеше ояла торган, әдәпсез, чиркангыч сүзләр сөйләү.

124. Кешедән бер йомыш үтенгәндә, Аллаһы Тәгалә хакы өчен дип сорау.

125. Аллаһы Тәгалә хакы өчен, дип үтенгән кешенең үтенечен кылмый калу.

126. Биргән бүләген вә садакасын әйтеп битәрләү.

127. Файдалы сүзне кирәктән артыгын сөйләү.

128. Дөньяга да, Ахирәткә дә файдасы булмаган сүзләр сөйләү.

129. Бурыч йә башка йомыш сораганда, зинһар, бирсәнә дип, кат-кат сорап йөдәтү.

130. Сүзем матур булсын дип, тәкәллефләнеп (ясалма кыланып) сөйләү.

131. Һичкемгә зарары тими торган ялган сүзләр сөйләү.

132. Сүз җае вә кинә белән кешедән көлү.

133. Сәбәпсез вә гаҗәпсез күп көлү.

134. Тимер, җиз, бакыр вә таш йөзекләр киеп йөрү.

135. Кеше сурәтен вә хайван сурәтләрен өйдә күз алдында тоту.

136. Өй эчендә эт асрау.

137. Залим төрмәләрне тәгъзим кылу.

*Әхмәдһади Максудиның «Шәригать хөкемнәре» китабыннан*

# Сәүдә итү (Сәүдәгәрлек)

**Сорау (С).**: Нәрсә ул сәүдә?

**Җавап (Җ).:** Сәүдә – ул ризалык белән килешү төзеп, мал-мөлкәтне алмашу яки сату-алу.

**С.:** Сату-алу килешүе ничек төзелә?

**Җ.:** Сәүдә килешүе «бирдем – кабул иттем» кәлимәләре үткән заманда әйтелеп төзелә. Мәсәлән, берсе «саттым», икенчесе «алдым» дисә, солых төзелгән булып санала.

**С.:** Әгәр килешү төзүчеләрнең берсе ризалашса, икенчесенә риза булу вәҗиб булырмы?

**Җ.:** Юк, сату-алу өчен ике якның да риза булуы кирәк. Әгәр берсе килешүгә ризалашса, икенчесе теләсә – ризалаша, теләмәсә – юк. Әгәр шул урында торганда ризалашса, беренчесе үз ризалыгын кире кага алмый.

**С.:** Ни өчен сез ризалыкны билгеле бер урында тору белән бәйләдегез?

**Җ.:** Чөнки килешү төзүчеләрнең берсе ризалык биреп, ул урыннан китсә, һәм икенчесе икенче бер урында ризалык бирсә, бу килешү гамәлдән чыга.

**С.:** Сатып алучы сатучыга, килешү төзелгәннән соң, сатып алынган әйбер хакында дәгъва күрсәтә аламы?

**Җ.:** Әйе, әгәр сатып алучы товарда җитешсезлек тапса, аның сатучыга кире кайтарып бирергә хакы бар.

**С.:** Ваклап түләү шарты белән сату-алу рөхсәт ителәме?

**Җ.:** Әйе, әгәр түләү шарты алдан килешенгән булса, рөхсәт ителә.

**С.:** Әгәр кеше сатып алганда товар күләменең яки озынлыгының микъдарын күрсәтмәсә, бу килешү дөресме?

**Җ.:** Дөрес, чөнки сатып алганда товарның күләмен күрсәтү килешүнең шартыннан саналмый.

**С.:** Сатып алучы төрен әйтеп, күпме түләвен һәм акча сыйфатын әйтмәсә, килешү дөрес буламы?

**Җ.:** Әгәр сатып алучы, мәсәлән: «Синнән көмеш, алтын, динар, дирһәм яки бодай биреп сатып алам», – дисә, ләкин суммасын һәм сыйфатын әйтмәсә, бу килешү дөрес түгел. Килешү дөрес булсын өчен, суммасын әйтергә кирәк, мәсәлән: «Синнән фәлән кадәр дирһәмгә сатып алам», – дип әйтергә. Һәм сыйфатын атарга кирәк, мәсәлән: Мисыр яки Сүрия дирһәме, «яхшы» яки «начар», дип әйтергә кирәк.

**С.:** Үлчәнелгән ризыкны һәм бөртекне сатарга ярыймы?

**Җ.:** Ярый, ләкин риба килеп чыгу сәбәпле, башка төр ризыкка алмаштырырга ярамый.

**С.:** Товар өчен түләнелгән сумманың микъдарын күрсәтү вәҗибме?

**Җ.:** Әйе, вәҗиб.

**С.:** Сатып алучыга: «Бодайны сиңа чүлмәккә тутырылган хәлдә сатам», – дисә, сатып алучы чүлмәктәге бодай микъдарын белмичә кабул итсә, сату-алу дөрес буламы?

**Җ.:** Әйе, чүлмәк тулы булып, бодай микъдарын белмәсә дә, сәүдә дөрес булып санала.

**С.:** Әгәр таш үлчәме белән үлчәп, гәрчә ташның үз үлчәме нинди микъдарда икәнен белмәсә дә, сату-алу мөмкинме?

**Җ.:** Әйе, мөмкин.

**С.:** Әгәр бер көтү сарыкның һәрбер сарыгын бер дирһәм бәясе шарты белән сатса, сәүдәсе дөрес булырмы?

**Җ.:** Әбү Хәнифә фикеренчә, бер бөтен көтүне тулысынча сатарга ярамый. Ләкин берәм-берәм сарык итеп сатарга ярый. Әбү Хәнифәнең укучылары, бөтен көтүне сатарга да мөмкин, диләр.

**С.:** Сатып алучы товар сатып алганнан соң, сатып алынган товарда җитешсезлек тапса, сатып алучыга нинди эшләр рөхсәт ителә?

**Җ.:** Аның җитешсезлекнең бәясен кайтарып бирүне таләп итәргә хакы бар, шулай ук сатып алынган барлык товарын кире кайтарып, түләгән акчасын кире алырга да хакы бар.

**С.:** Әгәр сатып алучы товарында артыклык тапса, аңа нишләргә?

**Җ.:** Бу артык товарны сатучыга кайтарып бирергә кирәк.

**С.:** Әгәр бер кеше 100 м тукыманы 1 метрын 10 дирһәм бәясенә сатып алса, тукыманың озынлыгы 100 метрдан ким булса, аның нинди хокуклары бар?

**Җ.:** Сатып алучының сатучыдан товар акчасын кире алырга яки барлык тукыманы да кире кайтарып бирергә хакы бар.

**С.:** Әгәр сатып алучы тукыманың 100 метрдан күбрәк икәнен күрсә, аңа нишләргә?

**Җ.:** Барлык товар сатып алучының милкеннән санала. Җир участогы да шулай була.

**С.:** Сатучы бер бәйләм тукыма сатканда: «10 бәйләмнән торган тукыманы, һәрбер тукымага унар дирһәм итеп, 100 дирһәмгә сатам», – дисә, соңыннан алучы артык яисә ким итеп тукыма сатылганын ачыкласа, аның хөкеме нинди?

**Җ.:** Ким булганы өчен, сатып алучы теләсә, җитмәгән кадәр түләгән акчасын яисә тукыманы сорарга хакы бар, ә артык калган очракта сату-алу булып саналмый.

**С.:** Кеше өй саткан. Килешүдә өйдән башка нәрсә турында сөйләшенмәгән. Сатуга тагын өй белән нәрсә керергә мөмкин?

**Җ.:** Өй белән өйалды һәм йозаклардан ачкычлар да санала.

**С.:** Әгәр дә кеше җир сатса, бу җирдә үскән үсемлекләр дә сатыламы?

**Җ.:** Җир сатылганда утыртылган үсемлекләр килешүдә әйтелгән булса да, булмаса да сатыла. Ә чәчелгән үсемлекләр килешүдә каралган булса гына сатылырга мөмкин.

**С.:** Берәү җимеш китерә торган агачны җимешләре белән сатты. Аның җимешләре кемгә тиеш?

**Җ.:** Әгәр дә сатып алучы алдан бернинди дә шартлар куймаган булса, җимешләр сатучыга була.

**С.:** Берәү агачтагы җимешләрне сатты, тик аның сыйфаты билгесез. Мондый сату дөресме?

**Җ.:** Әйе, дөрес. Сатып алучы җимешләрне, сыйфаты нинди булуга карамастан, җыярга тиеш. Әгәр дә килешүдә җимешләрнең азрагын агачта калдырырга, дип килешенгән булса, мондый сату-алу дөрес түгел.

**С.:** Сатучы агачтагы җимешләрнең билгеле бер өлешен калдыру шарты белән сата. Мондый килешү дөрес буламы?

**Җ.:** Юк, килешү дөрес түгел.

**С.:** Бодайны башакта килеш һәм шулай ук башка игеннәрен чистартылмаган хәлдә сату ярыймы?

**Җ.:** Мөмкин, тик башка төр товарга алыштырганда гына, чөнки шул ук төргә алыштырганда риба булырга мөмкин.

**С.:** Товар күп булып, товарны үлчәргә кирәк булса, үлчәгән өчен үлчәүчегә кем акча түләргә тиеш?

**Җ.:** Сатучы.

**С.:** Сатып алучының күп санда динарлары булып, аларны үлчәргә кирәк булса, үлчәгән өчен үлчәүчегә акчаны кем түли?

**Җ.:** Сатып алучы.

**С.:** Сатып алганда башта нәрсә бирелергә тиеш, акчамы яки товармы?

**Җ.:** Әгәр дә товар акчага сатылса, башта сатучыга акча, аннан соң алучыга товар бирелә, әгәр бартер яисә акча алмашуы булса, икесе дә бер үк вакытта бирелә.

## Товарның сыйфатына дәгъва итү

Әбү Йосыф белән Мөхәммәд , товарның сыйфатына дәгъвалау 3 көн эчендә кылынырга, әгәр дә гарантиясе алдан сөйләшенгән булса, товарны кире кайтару вакыты озынайтылырга мөмкин, дип саныйлар.

**С.:** Сатучы товарын сатканнан соң, кире кайтарырга теләсә, әмма сатып алучыда ул товар булмаса, бу очракта сатучының нинди хокуклары бар?

**Җ.:** Бу көн үтмәгән булса, сатып алучы товарның кыйммәтен түләргә, әгәр товар аның милкендә булса, товарны кайтарып бирергә тиеш була.

**С.:** Әгәр сатып алучы товарда җитешсезлек тапса, бу җитешсезлек товарның сатучы милкеннән чыгуына комачаулыймы?

**Җ.:** Әбү Хәнифә фикеренчә, комачауламый. Шулай ук аның фикере буенча, товар сатып алучының милке булып та саналмый. Әмма аның укучылары Әбү Йосыф һәм Мөхәммәд фикерләрендә, товар сатып алучының милкеннән санала.

**С.:** Әгәр товарда берниндu җитешсезлек тапмаган очракта да аны кире кайтарырга ярыймы?

**Җ.:** Әгәр алдан килешенгән булса, ярый.

**С.:** Килешү төзүчеләрнең берсе сату-алу үтәлгәнче һәм гарантия срогы тәмамланганчы үлсә, гарантия туктала, бу килешүне варисларга калдырырга мөмкинме?

**Җ.:** Гарантия туктала, варислар өстендә дә калмый.

## Читтән торып сату-алу

**С.:** Әгәр берәү күрмичә мал сатып алса, бу сәүдә дөресме?

**Җ.:** Бу сәүдә дөрес, ләкин сатып алучының товарны күргәннән соң сайларга хокукы бар, теләсә үзендә калдыра, теләсә кире кайтарып бирә ала.

**С.:** Бу сатып алынган товарны кире кайтару вакытын чикләргә мөмкинме?

**Җ.:** Сатып алучы үзе ризалашмаса, мөмкин түгел.

**С.:** Читтән торып сатып алган сурәттә, килешү төзелгәннән соң, сатучының төзелгән килешүне таркатырга хакы бармы?

**Җ.:** Юк, ул килешүне боза алмый.

**С.:** Сатып алучы игътибарсыз гына, төрелгән тукыманы яки сатып алыначак кәнизәкнең битен яки атның йөзен карап сатып алса, соңыннан бу сатып алынган товардан баш тартырга хокукы бармы?

**Җ.:** Юк.

**С.:** Бер кеше өйне тышкы яктан карап сатып калса, сатып алынган өйдән баш тартырга хокукы бармы?

**Җ.:** Имам Әбү Хәнифә укучысы Зөфәрнең фикеренчә, өйнең эчке ягын да карарга кирәк.

**С.:** Сукыр кешеләрнең сату-алуда хокуклары нинди?

**Җ.:** Сукыр кешегә сату яки алу мөмкин, ләкин сатып алганда аңа үзенең барлык тойгы әгъзаларын кулланырга,ягъни тотып, иснәп яки ашап карарга кирәк.

**С.:** Сукыр кешегә ничек итеп йорт сатып алырга?

**Җ.:** Аңа бу очракта бер кешенең тасвирламасына таянып эш итәргә кирәк. Ризалашкан очракта, кире кайтарырга хакы юк.

**С.:** Чит кешенең милкен хуҗаның ризалыгыннан башка сатарга ярыймы?

**Җ.:** Бу очракта хуҗаның килешүне юкка чыгарырга һәм үз милкен кире кайтарырга хакы бар.

**С.:** Бер кеше ике кием сатып алганда берсен күреп, икенчесен сатып алганнан соң гына күрсә, килешүдән баш тартып, киемнәрне кире кайтарып бирә аламы?

**Җ.:** Әйе, кире кайтарып бирә ала.

**С.:** Әгәр бер кеше бер әйберне күреп, берникадәр вакыттан соң сатып алса, җентекләп караганнан соң, кире кайтарып бирергә хакы бармы?

**Җ.:** Әгәр товарның сыйфаты беренче күргәндәге кебек үк булса, кире кайтара алмый, әмма сыйфаты үзгәргән булса, кире кайтарырга хакы бар.

**С.:** Сатып алучының кире кайтару хакы булып, үлеп китсә, аның бу хакы белән нәрсә булыр?

**Җ.:** Бу хак үз хокукын югалта, үлүченең варисларына калмый.

**С.:** Сатып алучы товарында җитешсезлек тапса, нәрсә эшли ала?

**Җ.:** Товарны кире кайтарырга хакы бар, ләкин товарның кимчелеге өчен түләү таләп итәргә хакы юк.

**С.:** Товарны сатып алучы шул товарга зыян салса, соңыннан бу товарның элек булган кимчелеген тапса, аңа ничек бу кимчелекне кайтарырга?

**Җ.:** Ул табылган кимчелек өчен түләтә яисә, сатучы риза булса, бу товарны сатучыга кире кайтара ала.

**С.:** Берәү кием сатып ала һәм аны башка төскә буйый. Шуннан соң бу киемдә кимчелек таба. Аның бу кимчелек өчен түләтергә хакы бармы?

**Җ.:** Әйе, аның моңа хакы бар, тик сатучы бу киемне алырга бурычлы түгел.

## Фәсид (бозык) һәм мәкруһ сату-алу

**С.:** Сату-алуның дөрес һәм бозык төрләрен бәян итегез әле.

**Җ.:** Сату-алуның дүрт төре бар:

**1)** дөрес, ягъни һәрьяктан да шәригать буенча булган сату-алу;

**2)** батыйл, ягъни шәригатькә каршы килгән сату-алу;

**3)** фәсид (бозык), ягъни, нигездә, шәригатькә каршы килми, ләкин батыйлга якын булган сату-алу;

**4)** рөхсәт ителгән, ягъни сатучы чит кешенең милкен сатса, килешү хуҗаның ризалыгы белән генә дөрес булып санала.

## Мәкруһ сату-алу

Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә болай дип әйтте:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا نُودِيَ لِلصَّلَاةِ مِن يَوْمِ الْجُمُعَةِ فَاسْعَوْا إِلَىٰ ذِكْرِ اللَّهِ وَذَرُوا الْبَيْعَ ۚ

**«Ий, иман китергән бәндәләр! Әгәр җомга намазына азан әйтелсә, эшләрегезне вә сәүдәләрегезне куеп, намаз укырга, вәгазь тыңларга ашыгып барыгыз».**

«Җомга», 62:9

Димәк, җомга намазына азан әйтелә башлагач, намаз ахырына кадәр сату-алу тыела. Пәйгамбәребез бәяне күтәрү, сәүдәне монополияләштерү һәм шулай ук җитешми торган (дефицит) товарга бәяне күтәрүне тыйды.

*«Әт-Тәсһил әз-заруори ли мәсәил кудури» китабыннан*

# Тарих

# Япониядәге татарлар тарафыннан төзелгән беренче мәчет



Мәчет Япониянең Кобе дип аталган шәһәрендә урнашкан. Географик яктан Кобе, Япониянең башка шәһәрләренә караганда, бик уңайлы урында булуы белән аерылып тора. Биредә уртача климат. Шәһәр урнашкан урын куркынычсыз, мондә җир тетрәүләр бик сирәк күзәтелә. Кобеда, Япониянең индустрия үзәге булган Осаке шәһәре белән сәүдә эшләре алып баручы бик күп чит ил кешеләре яши. XX гасырның икенче яртысында монда чит илләрнең күп кенә сәүдә вәкиллекләре булган. Ул вакытта Һиндстан (Пакистан – Британия Һиндстанының бер өлеше булган чор), Индонезия, Малайзия, гарәп илләре мөселманнары да Кобе шәһәрендә

төпләнүне кулай күрә иде. Мөселман илләре белән сәүдә эшләре алып бару белән, илдә акрынлап мөселманнарның саны арта.

Алдан Кобе мөселманнары аерым-аерым яшәгәннәр: сан буенча күп булмаганнар һәм, нигездә, Кобеда тел һәм гыйбадәт кылуда төрле халыклар тупланган булган. 1917 елда революциядән һәм большевиклар җәбер-золымыннан Япониягә качып килгән татарлар барлыкка килү белән, Кобеда беренче мөселман районы формалаша. Татар җәмәгатьчелеге җомга намазын һәм Рамазан айларында тәравих намазларын укыр өчен аерым бина арендалый башлый, ә соңрак үз мәктәбен ача. Башта имам вазифаларын Иж-Бубый имамы Габдрахман хәзрәт Кәрими башкарган. Әмма озакка сузылган авыруы аркасында Габдрахман хәзрәт бу вазифаны калдырырга мәҗбүр булган. Чама белән 1934 елда имам вазифасына чыгышы белән Уфа губерниясе кешесен, Шанхайда «Мөселман качкыннары җәмәгатьчелеге»нә нигез салучы Мәдьяр хәзрәт Шәмгунины чакырталар. Арендаланган бина булгач, татар гыйбадәт йортына җомга һәм бәйрәм намазларын укыр өчен шәһәрнең башка милләт кешеләре: һиндлар, гарәпләр, индонезиялеләр, малайзиялеләр дә килә башлый. Акрынлап Кобе мөселманнары тулы кыйммәтле мәчет төзү турындагы фикергә килә. 1927 елда чыгышлары белән Британия Һиндстаныннан булган, сәүдәгәрләр Әхмәд, Мөхәммәд Габделкәрим Бочия һәм Габдрахман хәзрәт Кәрими бу изге эштә беренче адымнарны ясый. 1928 елда Һиндстан мөселманнары һәм татар җәмәгатьчелеге мәчет төзелеше өчен комитет төзү карарына килә һәм акча җыю эшләрен башлап җибәрә. 1929 елда комитет мәчет төзелеше өчен рәсми ризалык сорап, Япония хакимиятенә мөрәҗәгать итә. Комитетның рәисе итеп Мөхәммәд Габделкәрим Бочия (Британия Һиндстаныннан), комитетның акчасын саклаучы итеп, туганнар Габделсаттар һәм Бәк Габделкәрим (Британия Һиндстаныннан), һәм сәркатипләр буларак Әхмәд һәм Габдулла Гаффар (татар җәмәгатьчелеге вәкилләре) исемле кешеләр һәм ике яктан да башка күп санлы әһелләр

билгеләнә. Мәчет төзелү Япония тарихында беренче тапкыр булганлыктан, хакимияттәгеләрдән төзелеш өчен ризалык алу эше тоткарлана.

Алты ел дәвамында комитет 70 000 йен (Япониядәге акча берәмлеге, 1 йен – 0,59 сумга тиң) акча җыя. Татарлар качкыннар сыйфатында булганга күрә, аларның финанс мөмкинлекләре чикләнгән була. Шуңа күрә акчаларның күп өлеше Һиндстан мөселманнары тарафыннан туплана. Мәчет төзер өчен комитет шәһәрнең иң яхшы урамыннан җир сатып ала. Ниһаять, 1934 елда Япония хакимияте төзелеш өчен үз ризалыгын бирә. Шул ук вакытта төзелеш эшләрен алып бара торган оешма эзли башлыйлар. Нәтиҗәдә 50 000 йен акчага, илнең иң яхшы оешмаларының берсе – «Такэнагагуа» компаниясе белән килешү төзелә. Оешма 1935 елның апрель аена төзелү эшләрен тәмамларга вәгъдә бирә. Мәчетнең беренче ташын куюның тантаналы өлеше – 1934 елның 30 нче ноябрь көненә туры килә. Бу Япония мөселманнары өчен генә түгел, Җир йөзенең барлык мөселманнары өчен дә зур әһәмияткә ия булган вакыйга була. Тантанага Төркия, Иран, Мисыр, Әфганстан консуллыклары вәкилләре, Япониянең күп кенә түрәләре һәм галимнәре катнашында 400 ләп кеше җыела. Чара вакытында Мәдьяр хәзрәт Коръән аятьләре укып, Япония белән Ислам дөньясы арасындагы дуслык өчен дога кыла. Әлеге вакыйга берничә көн дәвамында радио һәм матбугат тарафыннан игътибар үзәгендә була. Мәчетне күркәм итеп, шәрык стилендә төзиләр. Ул өч каттан тора: беренчесендә – зур залда иҗтимагый чаралар үтә, икенче залда намаз укыла, өченче зал – балкон, биредә хатын-кызлар өчен намаз уку урыны каралган була. Мәчет янында мәктәп өчен аерым бина салалар. Әлеге мәчет бүгенге көнгә кадәр үз эшчәнлеген алып бара. Кобе шәһәренең үзәгендәге күркәм мәчет – Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Америка бомбаларыннан сакланып калган берничә бинаның берсе булып санала.

# Финляндиядә татар җәмәгатьчелегенең төп рухи һәм мәдәни үзәгенең барлыкка килүе



**Фредрикинкату урамы, 1974 ел. Хельсинки шәһәре музее.**

Мөгаен, Җир йөзендәге татарларның иң уникаль диаспорасы булып Финляндиядәге татар диаспорасы саналадыр. Әлеге язма Финляндиянең рухи һәм мәдәни үзәге булган «Ислам йорт»ының барлыкка килүенә багышлана.

XX гасырның икенче яртысына кадәр үзләренең дини һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен Финляндия татарлары шәһәрнең төрле урыннарында биналар арендалаганнар.

1941 елда татар җәмәгатьчелеге Хельсинкиның Фредрикинкату урамында дүрт катлы йорт сатып ала. Ә 1948 елда шәһәрнең шушы ук ура-

мында тагын бер ике катлы бинага ия булалар. Шулай да урын аз булганга күрә барыбер биналар арендаларга туры килә.




**1948 елда татар җәмәгатьчелеге тарафыннан сатып алынган бина. Фредрикинкату урамы, 33 нче йорт. Хельсинки шәһәре музее.**

XX гасырның икенче яртысында Хельсинки татар җәмәгатьчелеге алдына дини-мәдәни эшчәнлек өчен яңа зур бина табу мәсьәләсе килеп баса. Озак килешүләрдән соң татар җәмәгатьчелеге идарәсе, бинаны төзергә кирәк, дигән карарга килә. Дини-мәдәни үзәкне төзер өчен махсус комитет оеша, аны җәмгыятьнең хәзерге җитәкчесе Гатика Галинең әтисе – Габдулла Гали исемле кеше җитәкли. Комитет тарафыннан 1948 елда сатып алынган, Фредрикинкату урамы 33 адресы буенча урнашкан йортны сүтәргә һәм аның урынында яңа йорт төзергә кирәк, дигән нәтиҗә ясала. Яңа бина уңайлы һәм практик булырга тиеш була. Озак

вакыт киңәшүләр үткәргәннән соң түбәндәге план буенча төзергә кирәк дигән нәтиҗәгә киләләр:

1. Бишенче катта ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым намаз уку бүлмәсе, төрле бәйрәмнәр, чаралар, тантаналар үткәрер өчен зур зал һәм ашханә урнаша.

2. Дүртенче катта утырышлар өчен каралган бүлмә, канцелярия кирәк-яраклары өчен урын, тантаналар өчен кечкенә зал, ике укыту сыйныфы, торак-хуҗалык максатларында кулланыла торган бүлмә урнашкан була.

3. Бинаның калган өч каты арендага тапшырылырга һәм шул рәвешле чыгымнарны каплау өчен хезмәт итәргә тиеш була. Гадәт буенча Рәсәйдәге күп мәчет бинаның киләчәктәге чыгымнарын каплауны истә тотып төзелә. Бу очракта беренче катлары сәүдәгәрләргә арендага бирелеп, керемнәре мәчет кирәк-яраклары өчен кулланыла торган була.

Планны тулысынча кабул иткәннән соң, 1960 елда төзү эшләре башлана. Әмма җәмәгатьчелек тулы суммага ия булмый. Исәпләүләр буенча, бинаны күтәрер өчен 150 млн. фин маркасы таләп ителә, ә җәмәгатьчелекнең кулында 22 млн. фин маркасы гына була. Шуңа күрә кредит өчен банкларга һәм кредит бирә торган оешмаларга мөрәҗәгать итәргә дип карар кылына. Банктан бары 50 млн. марка, ә Похйола иминиятләштерү фирмасы аша 40 млн. марка алалар. Шулай ук татар җәмәгатьчелеге мөселман илләренә дә ярдәм белән мөрәҗәгать итә. Җавап итеп өч ил үзләренең ярдәм итә алганнарын белдерә: Төркия 5 млн. 300 мең марка, Пакыстан 4,5 млн. марка, а Марокко короле 600 мең марка бирә. Әмма барыбер акча тулысынча җитеп бетми. Шуннан соң төзү эшләрен алып баручы Стиг Гедман исемле адвокат төзелеп килә торган бинадагы аренда хезмәте белән кызыксына торган фирмаларга мөрәҗәгать итеп карарга тәкъдим итә. Ул вакытта кибет арендалары өчен тәкъдимнәр аз була. Нәтиҗәдә андый арендаторлар табыла һәм 21,3 млн. марка суммасы күләмендә биш

елга кредит биреп торалар. Әлеге тырышлыклардан соң тагын 14 млн. марка таләп ителә. Моннан соң җитеп бетмәгән сумманы җәмәгатьчелек вәкилләре җыеп бирә. Халык шәхси бинага ия булуны шул хәтле теләгән була ки, хәтта бик үк хәлле булмаган кешеләр дә күпләп үз өлешләрен кертә. 1960 елның 16 нчы гыйнварында иске ике катлы бинаны сүтү эшләре башлана. 16 нчы гыйнварда тантаналы рәвештә нигез салына. Чарага 200 татар җыела. Шулай ук мөселман илләре дипломатлары да чакырыла: Пакистан илчесе Әршад Хөсәен, Мисыр илчесе Әхмәд Рияд, Төркия илчелеге сәркатибе Айдын Йеген һәм башкалар катнаша. Чакырылучылар арасында финлылар да була. Бинаның сул почмагында шул көнге гәҗит һәм төзелеш эшләре хакындагы кайбер документларны һәм акча купюрасын салып калдыралар. Тантанада җәмәгатьчелекнең имамы Вәли-Әхмәд Хәким тарафыннан Коръән аятьләре укыла, дога кылына. Төзелү эшләре тиз бара, 1960 елның октябрь аенда тәмамлана һәм бераздан беренче арендаторлар да килә башлый. Беренче җомга намазы шул елның 2 нче декабрендә укыла. Аны җәмәгатьчелекнең имамы Вәли-Әхмәд Хәким укый. Намазга бик күп татар халкы җыела, күпләр шатлыклы күз яшьләрен яшерми. Фин матбугаты Хельсинки үзәгеннең түбәсендә ярымай куелган бина калкып чыгуын уңай бәяләп, моның хакында күп яза. Ул вакытта бу бердәнбер мөселман җәмәгатьчелеге була. Әмма барыннан да бигрәк җәмәгатьчелекнең мәчет белән үз бинасы барлыкка килү татар халкы өчен зур әһәмияткә ия була. Аларның хәзер диннәрен, телләрен һәм мәдәниятләрен саклый һәм үстерә алыр өчен үз биналары барлыкка килә. Диаспора әһелләре актив рәвештә бинаны куллана башлый. Бишенче катта тантаналар, никахлар үтә. Мәсәлән, беренче туй биредә 1961 елда уза. Ул көнне Чыңгыз Сафиуллин һәм Фәһимә Галигә никах укыла. Никахны җәмәгатьчелекнең имамы Вәли-Әхмәд Хәким укый.




**Хельсинкиның Фредрикинкату, 33 адресы буенча урнашкан татар җәмәгатьчелеге бинасы. Бүгенге көнге фото.**

Бәйрәм намазлары элек арендаланган биналарда үткән булса, аннан соң әлеге бинада уза торган була. 1969 елга кадәр дүртенче катта төрек башлангыч мәктәбе эшли. Мәктәп өчен ике класс бирелә: укытучылар бүлмәсе һәм 3 нче һәм 4 нче катлар арасында балкон. Мәктәп бикләнгәннән соң шушы көнгә хәтле биредә якшәмбе көн укулары дәвам итә. Биредә Ислам нигезләре һәм татар теле укытыла. Шулай ук 4 нче катта канцелярия, киңәшмәләр, тантана залы һәм китапханә урнашкан.

Бишенче каттагы тантаналар залы мәдәни максатларда да кулланыла. Аларда чәй эчү кичәләре, концертлар, спектакльләр үткәрелә. Шулай ук зур зал рәсми чаралар өчен кулланыла: ел саен җәмәгатьчелек әһелләренең җыелышы, дипломатларны, дәүләт делегацияләрен рәсми рәвештә кабул итү оештырыла.



**Татар җәмәгатьчелеге бинасындагы китапханә**

Кызганычка, гомумауропа тенденцияләре, туучылар саны кимү аркасында җәмәгатьчелекнең саны кими һәм хәзер анда чама белән 750-800 кеше исәпләнә. Аларның күпчелеге Хельсинкида һәм аның тирәсендә яши. 1960 елдан бирле бүгенге көнгә кадәр татар җәмәгатьчелегенең төп яшәеше әлеге бина кысаларында алып барыла. Бүгенге көндә әлеге бина җәмәгатьчелекнең доноры булып тора. Бинаның өч каты арендага бирелә. Нәкъ менә шуннан кергән акчалар белән җәмәгатьчелек үз эшчәнлеген алып бара. Татар халкының, башка изге корылмаларга кебек, бу бинага карата булган мөнәсәбәте үзенчәлекле. Алар аны киләчәк буыннарга да калдыра алыр өчен бар тырышлыкларын куялар. Чөнки нәкъ менә әлеге бина дин, тел һәм мәдәниятне саклауның төп гаранты булып тора.

*islam-today сайтыннан*

# Тәрбия

# Гыйлем иясенең һәм гыйлем алучының әдәпләре

Бу турыда кыскача рәвештә имам Нәвәвинең «Тибьян» («Ачыклау») исемле китабында аңлатыла:

1) Гыйлем алуда һәм гыйлем бирүдә максат (ният) ачыкланырга тиеш.

Мөгаллим һәм укучы дини гыйлем алуда максат итеп Аллаһының ризалыгына ирешүне, дөрес иман нигезләрен өйрәнүне куярга тиешләр.

Әгәр дә кеше дини гыйлем алганда максат итеп дөньяви байлыкка ирешүне яки дан казануны куйса, бу ихласлы ният булмый. Гыйлемнең ахыргы нәтиҗәсе Аллаһыдан курку булырга тиешле.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә җәһәннәм уты гыйлем алып аны кешеләргә өйрәткән һәм Коръән укыган кеше белән яндырылып җибәреләчәк. Аны Аллаһы каршына алып киләләр. Аллаһы аңа Үзенең нигъмәтләрен искә төшерә башлый, бу кеше ул нигъмәтләрне таный. Аллаһы аннан: «Син нинди гамәл кылдың?» – дип сорый. Бу кеше: «Гыйлем алдым һәм аны башкаларга өйрәттем һәм Синең ризалыгың өчен Коръән укыдым», – дип җавап бирер. Аллаһы аңа: «Син ялганлыйсың. Син гыйлемне галим дип әйтсеннәр, ә Коръәнне матур укый дип әйтсеннәр өчен генә укыдың», – дип әйтер. Соңыннан аны башы җиргә тигән килеш җәһәннәмгә сөйрәп барырлар һәм шунда атарлар»[1].

2) Укытучы дини гыйлем бирүдә акча, дәрәҗә, бүләк кебек дөньяви максатларны куярга тиеш түгел. Хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән:

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

«Кем дә кем Аллаһы ризалыгына омтылып алынырга тиешле гыйлемне дөньядагы бер максатка ирешү өчен өйрәнсә, Кыямәт көнендә ул җәннәтнең исен дә тоймаячак»[1].

Имам Шәфигый болай дип әйткән: «Мин халыкның язган китапларымны укып, хәтта бер хәрефен дә минеке дип әйтүләрен теләмәс идем».

3) Укытучы балаларның санын арттыруны беренче максат итеп куймаска тиеш.

4) Белем бирүче кеше һәрвакыт күркәм холыклы, ачык йөзле, сабыр, йомшак күңелле булырга тиеш.

5) Белем бирүче кеше гыйлем алучыга киңәш бирергә, авыр чакта ярдәм итәргә һәм аңа карата йомшак мөгамәләдә булырга тиеш. Әд-Дәрими исемле галим болай дип әйткән: «Гыйлем алучыга һәм гыйлем бирүчегә карата йомшак мөгамәләдә булыгыз».

6) Гыйлем бирүче кеше беркайчан да «белмим» дип әйтергә оялмасын.

Бервакытны Гыйракның фикһ белгече Шәгъбигә ниндидер сорау бирделәр. Ул, белмим, дип җавап бирде. Шуннан соң аннан кешеләр: «Әллә син Гыйракның фикһ белгече була торып, белмим дип әйтергә оялмыйсыңмы?» – дип сорадылар. Ул: «Хәтта фәрештәләр дә Аллаһы Тәгалә алардан сорагач: «Син бөтен кимчелекләрдән пакь! Безнең гыйлемебез юк», – дип әйтергә оялмадылар», – дип җавап биргән.

7) Гыйлем алучы кеше һәрвакыт укытучыны хөрмәт итәргә тиеш.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам болай дип әйткән:

«Олыларны хөрмәт итмәгән, кечеләргә миһербанлы, галимнәребезгә ихтирамлы булмаган кеше минем өммәтемнән булмас»[2].

*Вәлиулла хәзрәт Якуповның*

*«Вәгазьләр» китабыннан*

1 Имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Әхмәд бине Хәнбәл Мөснәденнән.

# Гаиләләребезне саклау – һәрберебезнең бурычы

Никах укытып, гаилә корып яшәү, шул гаиләне саклау, бер-береңне кайгырту, балалар үстерү – Раббыбызның адәм балаларына биргән бер нигъмәте дә, сынавы да. Динебез гаиләнең бөтенлеген бик кырыс рәвештә саклый. Аллаһы Тәгалә тарафыннан рөхсәт ителгән, әмма Ул иң сөймәгән күренеш – талак. Әле кичә генә бер-берсенә мәңгелек вәгъдәләр бирешкән пар, бер-берсен күрмәс дәрәҗәгә җитә – гаилә таркала, балалар ятим кала. Ни кызганыч, бүген гаилә кору сөннәтен үтәргә ашыгучылар кими бара, ә корган гаиләләрен тар-мар китерүчеләр – арта.

Ни сәбәптән шулай соң? Без, мөселман булуыбызга карамастан, никах, гаилә, капма-каршы җенестәге кешеләрнең аралашуына җиңел карыйбыз, Аллаһы Тәгалә билгеләгән кануннарны бозабыз. Раббыбыз безгә әманәт итеп балалар бирә. Без шушы әманәт өчен тулаем җавап бирмибез. Хәдисләрдән билгеле булганча, ата-аналарның вазифасы – балаларны үстерү, тәрбияләү, ашату-эчертү, киендерү, тиешле белем бирү генә түгел, ә ир балаларын – өйләндерү, кыз балаларын кияүгә бирү дә. Ә без нишлибез? Буй җиткән балаларыбызны укырга дип җибәрәбез дә – кем белән йөри, кем белән яши – уйлап та бирмибез. Әле никах юк – кызларыбыз инде кыз түгел, улларыбыз инде әллә кайчан ир булып яши. Ата-ана буларак безгә йөкләнелгән вазифаны без тулысынча үтәргә тиешбез. Балабыз белән бергә аңа гомерлек яр сайлауда катнашырга тиешбез. Кем, нинди нәселдән, гаиләләрендә нинди мөнәсәбәт, тәртиплеме, динлеме – барысын да бәйнә-бәйнә тикшерү кирәк. Бу мәсьәләдә без балаларыбызга ярдәм итмибез. Шуңа күрә балаларыбыз әллә кемнәр белән яши башлый. Аннары әти-әниләр мәчеткә килә, имамга: «Хәзрәт, кызыбыз балага узган бит, никахын укытасы иде», – ди…

Әлбәттә: «Хәзрәт, алар безне тыңлыйлармы соң?» – дип сораучылар булыр. Тыңласыннар. Тыңлатырлык итеп үстерик. Тәвә кошы сыман башны комга тыгу дөрес түгел. Инде балаларыбыз буй җиткән – үзебезне ниһаять олы кешеләр сыман тотыйк. Никахсыз балага узучылары да, карындагы балаларын төшерүчеләре дә, хатыннарын аерып җибәрүчеләре дә, үз нарасыйларын тәэмин итмәүчеләре дә – әллә кайдан килгән бәндәләр түгел, үзебезнең балаларыбыз. Әти-әнисе улының нинди кыз белән йөрүен белә. Ләкин балалар өчен әти-әни җаваплы. Әгәр дә улыбыз йә кызыбыз зина кылып тора икән – әти-әниләргә дә гөнаһ.

Гаиләләребездә бүген нинди вәзгыять? Кадерле хатын-кызларыбыз ирләреннән өстен тора, ир-ат һаман да хатынының итәге астыннан чыга алмый. Ир икән – ир-ат булсын. Әти буларак үзенең сүзен әйтсен. Әнинең йомшак сүзе бәлки үтмәс тә, әмма әтинең нык сүзе йогынты ясамый калмас.

«Заманасы шундый», – диючеләр бар. Әмма Аллаһы Тәгалә кодси хәдисләрнең берсендә болай дип әйтә: «Вакытны сүкмәгез, чөнки Мин Үзем – Вакыт». Халкыбыз җитмеш ел динсезлектә яшәде. Бүген шул йола юк ителгән заманда тәрбияләнгән буынның балалары гаилә кора. Динсезлекнең ачы җимешләрен бүген татыйбыз. Бала һәрдаим үзенә сеңдереп бара. Гаиләдә әти белән әни арасында нинди мөнәсәбәт – ул шуны күрә, үзе дә аннары шул рәвештә яши. Әти-әни һәрвакыт талашып, бер-берсен кимсетеп яши икән – без балада курку тудырабыз. Аерылган гаиләдә әнисе һәрвакыт атасын начар дип күрсәтә икән – аның кызы гаилә корудан котылу өчен бөтен мөмкинлекләрен дә табарга тырышачак. Үзенә авыр булса да, ир-ат белән яшәү аның уенда да булмаячак. Һәм моңа әти-әниләр турыдан-туры гаепле.

Нәтиҗәдә нәрсәгә ирешәбез? Балаларыбыз гаилә корырга әзер түгел. Өйләнешкән очракта да аларны бихисап проблемалар сагалап тора. Бер-берсен җәберләргә, кимсетергә тотыналар. Кул күтәрүләргә барып җитә.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Мөселман шулдыр, кемнең теленнән дә, кулыннан да башкаларга зыян килми». Әгәр дә мин хатыныма кул күтәрәм икән – исерек килешме, аек рәвештәме, гаебе бармы аның, юкмы – миңа гөнаһ. Мин кул күтәрүче. Әгәр хатын-кызны ирләрчә тәрбияләгәннәр, иренә көн күрсәтми икән – аңа гөнаһ. Балаларыбызны җәберлибез икән – бу да гөнаһ.

Ни кызганыч, андый күренешләр бүген бар. Күреп, укып, ишетеп торабыз. Бу бик куркыныч күренеш. Халкыбыз бу гамәлне гөнаһ дип танымыйча моны туктатып булмый. Аллаһыдан курыкмаган, бәндәдән курыкмас. Бу тәкъвалык мәсьәләсе.

إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Сездән иң хәерлеләрегез иң тәкъвалылар. Аллаһ белүче вә һәр эшегездән хәбәрдар».**

«Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:13

Ягъни Аллаһы Тәгаләдән куркучылар. Аллаһыдан куркучы ир хатынына кул күтәрерме? Аллаһының җәзасыннан куркучы хатын ирен эштән начар сүзләр белән каршы алырмы? Риза булып алган никахлы хатынnарын ачлы-туклы яшәтүчеләр дә бар. Әти-әнисе гаиләсеннән кызны алдым икән – аны ашату да, киендерү дә, укыту да, башкасы да минем өстә. Ир-ат буларак балаларны да мин тәэмин итәргә тиеш.

Гореф-гадәтебез шундый: өйдә тәртипне хатын-кыз саклый. Бу аның хезмәте. Әмма без аңа шуның өчен рәхмәтле була белмибез. Чәчәк тә бирмибез, сирәк булса да берәр бүләк тә алмыйбыз. Хатын-кызга колга караган кебек карыйбыз. Бераз авыз ача башласа – талак әйтәбез дә җибәрәбез. Аллаһы Тәгалә шуннан сакласын. Чөнки мәзлумның догасы белән Раббыбыз арасында бернинди дә пәрдә юк. Безнең золымыбыз төшкән кеше шул вакытта дога кыла икән – җәзасыннан Аллаһы Тәгалә

Үзе сакласын. Раббыбыз хозурына әйләнеп кайткач – барысы өчен дә җавап бирәсе барлыгын онытмыйк.

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

# Тәфсир

# Йосыф галәйһиссәлам кыйссасы

«Әхсанел-кыйсса» («Иң яхшы риваять») исемен алган һәм бик күп гыйбрәтле мисалларга ия булган әлеге тарихи вакыйга турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән:

لَّقَدْ كَانَ فِي يُوسُفَ وَإِخْوَتِهِ آيَاتٌ لِّلسَّائِلِينَ ﴿٧﴾

**«Һичшиксез, Йосыф галәйһиссәлам һәм аның кардәшләрендә (гыйбрәт алыр өчен аять) сораучылар өчен (Аллаһы Тәгаләнең чиксез көчен һәм төшенә алмаслык хикмәтен күрсәткән бик зур) билгеләр бар».**

«Йосыф», 12:7

Ягъкуб галәйһиссәлләмнең унике баласы арасыннан иң яратканы – сурәтләп, язып бетереп булмаслык матурлыкка ия Йосыф булган. Ягъкуб галәйһиссәлам аңа бик зур игътибар күрсәткән.

Йосыф галәйһиссәлламнән соң Ягъкуб барлык балаларыннан да ныграк үзенең кечкенә улы Бинйәминне яраткан. Башка тугыз балалары Ягъкубның башка хатыннарыннан булган. Әнә шул сәбәпле һәм үзләренең көнчелеге аркасында, әлеге тугыз угыл Йосыфны һәм Бинйәминне ят күргәннәр һәм алар турында искә төшереп, «Йосыф һәм аның абыйсы…» дип әйткәннәр…

Йосыф һәм Бинйәминнең әнисе вафат булганнан соң, Ягъкуб галәйһиссәллам аларга тагын да күбрәк игътибар бирә башлый. Аның калган улларын көнчелек һәм хөсетлек хисе биләп ала, әлеге хис көннән-көн ныграк үсә бара һәм ахырдан нәфрәткә, дошманлыкка әверелә. Хәтта Йосыфтан котылу уена кадәр үсеп җитә.

Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәндә болай дип әйтә:

إِذْ قَالُوا لَيُوسُفُ وَأَخُوهُ أَحَبُّ إِلَىٰ أَبِينَا مِنَّا وَنَحْنُ عُصْبَةٌ إِنَّ أَبَانَا لَفِي ضَلَالٍ مُّبِينٍ ﴿٨﴾ اقْتُلُوا يُوسُفَ أَوِ اطْرَحُوهُ أَرْضًا يَخْلُ لَكُمْ وَجْهُ أَبِيكُمْ وَتَكُونُوا مِن بَعْدِهِ قَوْمًا صَالِحِينَ ﴿٩﴾

**«Менә алар (үзара сөйләшкән вакытта) болай дип әйттеләр: «Әлбәттә, Йосыф һәм (ата-анасы да бер булган) карендәше (Бинйәмин) әтиебезгә бездән сөеклерәк. Хәлбуки, без – (бер-беребезгә бәйле булган көчле) бер җәмәгатьбез. Һичшиксез, атабыз – (аларны ныграк яратып, һәркемгә тиешлесен бирү мәсьәләсендә) ап-ачык бер ялгышлык эчендә. (Бу мәсьәләдә уртак фикергә килгән кардәшләр Йосыф галәйһиссәламнән котылу чаралары табу турында ихтиләфкә төштеләр, берсе болай дип әйтте:) Йосыфны үтерегез яки аны билгесез бер җиргә ташлагыз, шулчак атагызның йөзе сезгә генә юнәлер (һәм, шулай итеп, ул моннан соң сезгә генә карап торыр). Аның (алынуы) артыннан сез (кылган бер гөнаһыгыздан тәүбә итеп,) янә игелек ияләре булырсыз».**

«Йосыф», 12:8-9

Әлеге аятьләрдән аңлашылганча, көнләшү хисе Йосыфның абыйларын мәкерле уйга илтә: әтиләре Йосыф галәйһиссәламне күбрәк ярата дип исәплиләр. Алар исә үзләренең сан ягыннан күп булуларын әтиләре мәхәббәтеннән күпкә лаеклырак саныйлар.

## Ягъкубның Йосыфны башка улларына караганда ныграк ярату сәбәбе

Йосыф галәйһиссәллам үзе сурәтләп бетереп булмаслык матурлыкка ия булган – бу хакта «бар булган нәрсәләрнең матурлыгы аның ярты

матурлыгына тора» дип әйтелә. Ул үзенең төс-кыяфәте белән беркемне дә битараф калдыра алмаган.

Өстәвенә Йосыф саф күңеле белән дә нурланган була. Аның эчке дөньясы да тышкы гүзәллеге кебек күркәм була. Шуңа күрә бик тә табигый ки, үз балаларыннан Ягъкуб бигрәк тә Йосыфны ярата – ул үзенең әхлагы һәм тәкъвалыгы белән аерылып тора, бу сыйфатлар исә аның абыйларына җитеп бетми.

Ә Ягъкуб зирәк һәм алдан күрүчән кеше, ул пәйгамбәр була. Шуңа да карамастан, уллары аның турында да ихтирамсызлык күрсәтеп: «Безнең әтиебез ачыктан-ачык адашуда», – диләр.

Йосыф галәйһиссәламне үтерергә һәм аны коега ташларга теләүләре аларның тәкъвалык ияләре рәтенә кермәүләре турында сөйли. Аллаһыдан хакыйкый курку белән куркучылар һәм Раббыбызга, Кыямәт көненә иман китерүчеләр үз гамәлләре өчен хисап тотасын аңлый: һәр мизгелне Аллаһы күреп һәм ишетеп тора! Шуңа күрә тәкъва кеше мондый харам гамәлне кылу турында хәтта уйламый да.

## Йосыфның төш күрүе

Йосыф турындагы риваятьләрдә мөһим рольне төш күрүләр уйный. Бервакыт төнлә Йосыф галәйһиссәллам төшендә унбер йолдыз, кояш һәм айның аңа иелеп сәҗдә кылуын күрә. Йосыф уянуга ук, тиз арада күргәннәрен әтисенә сөйли. Бу хакта Коръәндә түбәндәгеләр әйтелә:

إِذْ قَالَ يُوسُفُ لِأَبِيهِ يَا أَبَتِ إِنِّي رَأَيْتُ أَحَدَ عَشَرَ كَوْكَبًا وَالشَّمْسَ وَالْقَمَرَ رَأَيْتُهُمْ لِي سَاجِدِينَ ﴿٤﴾ قَالَ يَا بُنَيَّ لَا تَقْصُصْ رُؤْيَاكَ عَلَىٰ إِخْوَتِكَ فَيَكِيدُوا لَكَ كَيْدًا ۖ إِنَّ الشَّيْطَانَ لِلْإِنسَانِ عَدُوٌّ مُّبِينٌ ﴿٥﴾

**«Менә Йосыф галәйһиссәлам атасына болай дип әйтте: «Ий әтием! Һичшиксез, мин төшемдә унбер йолдыз, кояшны һәм**

**айны күрдем. Алар миңа сәҗдә кылган хәлдә иде». (Улының бу төшен тыңлап торган Ягъкуб (галәйһиссәлам): «Ий улым! (Син күргән бу) Төшеңне абыйларыңа сөйли күрмә, юкса, алар сиңа (мин саклап кала алмаслык бер рәвештә) тозак корырга уйларлар. Һичшиксез, шәйтан – кешеләргә ап-ачык бер дошман», – дип әйтте».**

«Йосыф», 12:4-5

Димәк, Ягъкуб галәйһиссәллам улының бөек мәртәбәләргә ирешәчәген, дөнья һәм Ахирәт тормышында югары дәрәҗәләргә күтәреләчәген һәм абыйлары аның кул астында булып, аңа буйсыначакларын аңлый. Әтисе улын куркынычтан кисәтә һәм аңа төшендә күргәннәрен сөйләмәскә киңәш итә.

Әмма, ни кызганыч, әлеге төш турында бертуган абыйларына билгеле була. Аларның көнчелек белән томаланган башларына Йосыфтан ничек котылырга дигән уй тынгылык бирми. Шул рәвешчә, алар Йосыфны ничек үтерергә дигән планнар төзи башлыйлар. Ниятләре турында Коръәндә түбәндәгеләр әйтелә:

ٱقْتُلُوا يُوسُفَ أَوِ اطْرَحُوهُ أَرْضًا يَخْلُ لَكُمْ وَجْهُ أَبِيكُمْ وَتَكُونُوا مِن بَعْدِهِ قَوْمًا صَالِحِينَ

**«Кардәшләрнең берсе болай дип әйтте: Йосыфны үтерегез яки аны билгесез бер җиргә ташлагыз, шулчак атагызның йөзе сезгә генә юнәлер (һәм, шулай итеп, ул моннан соң сезгә генә карап торыр). Аның (алынуы) артыннан сез (кылган бер гөнаһыгыздан тәүбә итеп,) янә игелек ияләре булырсыз».**

«Йосыф», 12:9

Бервакыт Ягъкуб галәйһиссәллам үзе дә төш күрә. Имеш, ун бүре Йосыфка ташлана. Ягъкубны куркытып торган борчулар бик тиз арада тор-

мышка аша. Абыйлары Йосыфны үзләре белән дала буйлап сәфәргә алып чыгалар.

قَالَ إِنِّي لَيَحْزُنُنِي أَن تَذْهَبُوا بِهِ وَأَخَافُ أَن يَأْكُلَهُ الذِّئْبُ وَأَنتُمْ عَنْهُ غَافِلُونَ

**«Аларның бу сүзләренә Ягъкуб (галәйһиссәлам)) Әйтте: «(Аны бик сөйгәнем һәм ансыз тора алмаганым өчен) Сезнең аны алып китүегез мине борчуга салыр. Аеруча, мин (күргән бер төшем сәбәпле) сез (читтәрәк бер җирдә шаулап) аннан гамьсез калган чакта, аны бүре ботарлап ташлар дип куркам».**

«Йосыф», 12:13

Асылда, Ягъкуб галәйһиссәллам бүреләрдән түгел, ә үзенең улларыннан курыккан, әмма аларның үзсүзлелегенә каршы тора алмый һәм Йосыфка да алар белән барырга рөхсәт бирә.

Җавап итеп аңа уллары болай дип әйтә:

قَالُوا لَئِنْ أَكَلَهُ الذِّئْبُ وَنَحْنُ عُصْبَةٌ إِنَّا إِذًا لَّخَاسِرُونَ

**«Әгәр без шул хәтле күп була торып аны бүре ашаса, ул вакытта без, әлбәттә, хәсрәттә булырбыз, Йосыфны бүредән ашатмак безгә зур кимчелек булыр».**

«Йосыф», 12:13

## Йосыф галәйһиссәламнең абыйлары тарафыннан коега ташлануы

Өеннән һәм әтисеннән ерактагы далада, каты мыскыллаулардан соң Йосыфны иске коега ташлыйлар. Абыйлары белән ерак сәфәргә чыккач, Йосыф галәйһиссәламгә төрле түбәнсетүләргә түзәргә туры килә. Әмма алар коега ташланган кешенең соңрак пәйгамбәр булачагы хакында күз алдына да китермиләр. Аллаһы Тәгалә Үзе Йосыфка вәхи иңдереп түбәндәгеләрне җиткерә:

...وَأَوْحَيْنَا إِلَيْهِ لَتُنَبِّئَنَّهُم بِأَمْرِهِمْ هَٰذَا وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ

**«(Алар (әтиләрен ирексезләп ризалатып,) аны алып китеп, бер кое төбенә ташларга бердәм карарга килгәч, (аңа бик зур золым эшләделәр)). Без исә (кое төбендә ялгызлык хисен тарату һәм рәхмәтебезгә ирештереп,) аңа (сөенечле хәбәр бирү өчен Җәбраилне җибәреп) вәхи иттек: «(Беркөн) Син аларның уйларында да булмаганда, аларга бу эшләрен хәтерләтәчәксең».**

«Йосыф», 12:15

Үзләренең җинаятьләрен яшерү өчен, Йосыфның агалары аның күлмәген бәрән чалган канга буйыйлар һәм бик борчылган кыяфәттә, елап, күлмәкне әтиләренә алып кайталар. Хикмәткә ия борынгылар: «Кайгыдан зарланучыларның яшьләренә алданма. Алар арасында күпме явызлар бар! Йосыфның агалары түккән күз яшьләрен исеңдә тот. Алар дөм караңгы төндә каты кычкырып елап әтиләре янына килделәр. Әмма алар моны дөреслекне ачып салу өчен түгел, бәлки кылган явызлыкларын яшерү өчен эшләделәр», – дип әйткәннәр.

Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелә:

قَالُوا يَآ أَبَانَآ إِنَّا ذَهَبْنَا نَسْتَبِقُ وَتَرَكْنَا يُوسُفَ عِندَ مَتَاعِنَا فَأَكَلَهُ الذِّئْبُ ۖ وَمَا أَنتَ بِمُؤْمِنٍ لَّنَا وَلَوْ كُنَّا صَادِقِينَ

**Әйттеләр: «Ий атабыз, без Йосыфны әйберләребез янында калдырып, үзебез йөгерү ярышына киткән идек, без әйләнеп килгәнче Йосыфны бүре ашаган, ий атабыз, син безгә ышанмыйсың, гәрчә без дөрес сөйләсәк тә».**

«Йосыф», 12:17

Йосыфның канга баткан, әмма ертылмаган киемен күреп, Ягъкуб галәйһиссәллам аны үз битенә куя. Ачы көлеп:

– Нинди мәрхәмәтле бүре булган бу. Ул минем улымны ашаган, ә күлмәген ертмаган да! – дип әйтә.

Йосыфның агалары әтиләреннән үз хәйләләрен яшерәләр, әмма алар алып килгән күлмәк аларның ялганлавы турында сөйли.

وَجَآءُوا عَلَىٰ قَمِيصِهِۦ بِدَمٍ كَذِبٍۚ قَالَ بَلْ سَوَّلَتْ لَكُمْ أَنفُسُكُمْ أَمْرًاۖ فَصَبْرٌ جَمِيلٌۖ وَٱللَّهُ ٱلْمُسْتَعَانُ عَلَىٰ مَا تَصِفُونَ

**«Алар (бер бәти суеп,) аның күлмәгенә ялган бер кан (сөртеп, аталарына) алып килделәр. (Моны күргән Ягъкуб галәйһиссәлам: «Нәфесләрегез сезгә (яман эшләр арасында мисалы) күрелмәгән бер эшне бизәп күрсәткән. (Миңа инде тәкъдиргә каршы килмичә һәм риза булып,) Күркәм сабырлык (күрсәтергә генә кала). Сезнең сөйләгәннәрегезгә каршы Аллаһыдан гына ярдәм сорарга кирәк».**

«Йосыф», 12:18

## Йосыф галәйһиссәламнең коедан чыгуы

Йосыфның бәхетенә, коедан ерак түгел генә Мисырга юнәлә торган кәрван узган. Шул кәрваннан ике кеше Йосыфны күреп ала. Бу хәл турында Коръәндә болай дип әйтелә:

قَالَ يَا بُشْرَىٰ هَٰذَا غُلَامٌۚ وَأَسَرُّوهُ بِضَاعَةًۚ

**«Гаҗәп бер матур угылдыр, нинди сөенеч безгә!»**

«Йосыф», 12:19

Шулай итеп, ул коедан чыгарылып, коллар сатыла торган базарга эләгә, аны Мисыр хакименең вәзире сатып ала. Үз балалары булмагач, ул хатынына мондый сүзләр әйтә:

وَقَالَ الَّذِي اشْتَرَاهُ مِن مِّصْرَ لِامْرَأَتِهِ أَكْرِمِي مَثْوَاهُ عَسَىٰ أَن يَنفَعَنَا أَوْ نَتَّخِذَهُ وَلَدًا ۚ

**«Мисыр вәзире газиз хатыны Зөләйхага болай дип әйтте: «Бу баланың урынын күркәм кыл, яхшы тәрбиялә, шаять без аннан файда күрербез, яки аны үзебезгә бала итәрбез».**

«Йосыф», 12:21

Үз баласы булмагач, аның йөрәгендә аталарга хас кайгырту хисләре уяна. Гадел, тәрбияле, югары әхлаклы, тәртипле Йосыф яңа гаиләдә дә, хәтта Мисырның хөкүмәт сараендагы кешеләр арасында да алмазга тиң яратылуга ия була, вакытлар узу белән вәзир янәшәсендә үзенең лаеклы урынын ала.

Әмма төп вакыйгалар Йосыф белән вәзирнең Зөләйха исемле хатыны арасында килеп чыга. Мисырның иң матур хатын-кызларының берсе булган Зөләйха кияүгә чыкканчы ук төш күрә. Ул төшендә ай нуры уза торган якты йолдызга әверелә. Әлеге төшнең Йосыф турында икәнен Зөләйха белми һәм төшне үзенчә юрый: вәзир тарафыннан кияүгә чыгарга ясалган тәкъдимгә уңай җавап кайтара. Сөюдән яну хисе соңрак килә... Аның йөрәге ире өенә алып кайткан акыллы, ягымлы, яшь матур егеткә тартыла.

Үз хисләре белән җәфаланган һәм бу хәлдән бернинди чыгу юлын күрә алмаган Зөләйханы хәтта җитмеш дөягә төяргә мөмкин булган кыйммәтле әйберләр дә шатландыра алмый. Ул, бернигә дә карамыйча, Йосыфка булган мәхәббәте өчен көрәшне дәвам итә.

**Бөек сынау**

Зөләйханың җавапсыз мәхәббәте тиз арада кайгы-хәсрәт, борчусагышка әверелә һәм аның акылыннан өстен чыга – ул үзенең чибәрлеген сөйгәненең игътибарын яулап алуда файдаланырга уйлый. Бер тапкыр

Зөләйха иң матур күлмәген киеп, Йосыф галәйһиссәламне үзенә чакыра. Йосыф башын иеп аның алдында басып тора, ә ул гаҗәеп караш ташлый. Коръәндә аларның шушы очрашулары турында болай дип әйтелә:

وَرَاوَدَتْهُ الَّتِي هُوَ فِي بَيْتِهَا عَن نَّفْسِهِ وَغَلَّقَتِ الْأَبْوَابَ وَقَالَتْ هَيْتَ لَكَ ۚ قَالَ مَعَاذَ اللَّهِ ۖ إِنَّهُ رَبِّي أَحْسَنَ مَثْوَايَ ۖ إِنَّهُ لَا يُفْلِحُ الظَّالِمُونَ

**«Хатын хәйләгә барды ки, ул (Йосыф галәйһиссәлам исә аның өендә яши иде. Ул (хатын аның чибәрлегенә түзә алмыйча,) ишекләрне бикләде һәм: «Бире кил!» – диде. Ул исә: «(Зина кебек бер гөнаһка төшүдән) Аллаһы сакласын! Минем әфәндем каласы урынымны яхшы кылды. Һичшиксез, (зина кебек гөнаһны эшләгән, бигрәк тә үзе яшәгән өйнең хуҗасына бу хыянәтне ярый торган эш итеп күргән) залимнәр уңышка ирешмәячәк»,** – диде.

«Йосыф», 12:23

Бу аятьтән аңлашыла ки, Йосыф галәйһиссәлам Зөләйханың тәкъдимен кире кага. Зөләйха үзенең матурлыгын, гүзәллеген Йосыфны гөнаһка алып бару өчен ничек кенә файдаланырга тырышмасын, бу эш мөмкин булмый. Зөләйхага: «Мин Аллаһыдан куркам һәм үземнең хуҗама хыянәт итмим», – дип әйтеп, ишеккә таба юнәлә, ә аның йөрәге сагыштан сыкрый. Зөләйха, Йосыфның шундый килеш-килбәтеннән кире кагылганнан соң, җәһәт адымнар ясый, аның күлмәген ертып ташлый, һәм шул мизгелдә бүлмәгә аның ире килеп керә.

Коръәндә бу хакта түбәндәгечә әйтелә:

وَاسْتَبَقَا الْبَابَ وَقَدَّتْ قَمِيصَهُ مِن دُبُرٍ وَأَلْفَيَا سَيِّدَهَا لَدَى الْبَابِ ۚ قَالَتْ مَا جَزَاءُ مَنْ أَرَادَ بِأَهْلِكَ سُوءًا إِلَّا أَن يُسْجَنَ أَوْ عَذَابٌ أَلِيمٌ

**«(Хатын Йосыф галәйһиссәламне тотыйм, ул исә качыйм дип,) Икесе дә узышып ишеккә ташландылар. Ул аның күлмәген арт-**

**кы яктан (тартып) ертты. (Нәкъ шул вакытта) Ишек янында аның ирен очраттылар. (Хәлдән ничек булса да чыгарга теләгән) Ул хатын (гаепне Йосыф галәйһиссәламгә аударыр өчен): «Синең гаиләңә (зина кебек) бер яманлык (кылырга) теләгән кешенең җәзасы зинданга ябылудан яки тилмерткеч бер газаптан башка нәрсә була ала?»** – диде.

«Йосыф», 12:25

Вәзиргә якын булган кеше әлеге вакыйганы аңларга ярдәм итә:

قَالَ هِيَ رَاوَدَتْنِي عَن نَّفْسِي ۚ وَشَهِدَ شَاهِدٌ مِّنْ أَهْلِهَا إِن كَانَ قَمِيصُهُ قُدَّ مِن قُبُلٍ فَصَدَقَتْ وَهُوَ مِنَ الْكَاذِبِينَ

وَإِن كَانَ قَمِيصُهُ قُدَّ مِن دُبُرٍ فَكَذَبَتْ وَهُوَ مِنَ الصَّادِقِينَ

**«Әгәр аның күлмәге алдан ертылган булса, хатын дөресен әйтә. Ул исә – (хатынның үзен котыртырга тырышуы дәгъвасында) ялганчылардан. Әгәр Йосыфның күлмәге аркасыннан ертылган булса, Зөләйха сүзе ялган булып, Йосыф сүзе дөрес булыр».**

«Йосыф», 12:26-27

Йосыфның гаепсезлеген аңлап, вәзир үз хатыныннан таләп итә:

فَلَمَّا رَأَىٰ قَمِيصَهُ قُدَّ مِن دُبُرٍ قَالَ إِنَّهُ مِن كَيْدِكُنَّ ۖ إِنَّ كَيْدَكُنَّ عَظِيمٌ

يُوسُفُ أَعْرِضْ عَنْ هَٰذَا ۚ وَاسْتَغْفِرِي لِذَنبِكِ ۖ إِنَّكِ كُنتِ مِنَ الْخَاطِئِينَ

**«Кайчан Зөләйханың ире Йосыфның күлмәгенең арттан ертылганын күргәч, Зөләйхага болай дип әйтте: «Бу эш синең хәйләң икән, әлбәттә, сез хатыннарның хәйләсе олуг». Газиз: «Ий Йосыф, бу эштән баш тарт, халыкка фаш итмә. Син Зөләйха тәүбә ит, гөнаһың өчен миннән гафу сора! Тәхкыйк, син**

**хаталанучылардан булгансың», – диде. Бу эш Мисырга җәелде, хатыннар бик күп сөйләделәр».**

«Йосыф», 12:28-29

## Йосыф галәйһиссәлам янәдән зинданда

Әмма мәхәббәт өчпочмагыннан Йосыфка котылу насыйп булмый. Хатынының хыянәтеннән интегүче вәзирне яңа һөҗүм көтә: Зөләйханың хисләре турында һәм булып үткән вакыйгалар турында Мисырның барлык почмакларында гайбәт булып тарала:

وَقَالَ نِسْوَةٌ فِي الْمَدِينَةِ امْرَأَتُ الْعَزِيزِ تُرَاوِدُ فَتَاهَا عَن نَّفْسِهِ ۖ قَدْ شَغَفَهَا حُبًّا ۖ إِنَّا لَنَرَاهَا فِي ضَلَالٍ مُّبِينٍ

**«Мисырда бер төрле хатыннар әйттеләр: «Газизнең хатыны үзенең колыннан якынлык кылуын үтенгән вә аңа мәхәббәте чиктән ашкан икән, без ул Зөләйханы ачык азгынлыкта күрәбез, чөнки Газизне ташлап, колны сөя башлаган».**

«Йосыф», 12:30

Зөләйха затлы нәселдән булган хатын-кызларны җыеп, аларга Йосыфны күрсәтергә була. Егетнең чибәрлеге кунакларга бик көчле тәэсир итә, алар аннан бер дә күзләрен ала алмыйлар, һәм җиләк-җимешләрне чистартканда, хәтта сизмәстән үзләренең бармакларын кисәләр, «Бу кеше түгелдер, мәгәр хөрмәтле фәрештәдер», – дип аһ итәләр.

فَلَمَّا رَأَيْنَهُ أَكْبَرْنَهُ وَقَطَّعْنَ أَيْدِيَهُنَّ وَقُلْنَ حَاشَ لِلَّهِ مَا هَٰذَا بَشَرًا إِنْ هَٰذَا إِلَّا مَلَكٌ كَرِيمٌ

**«Зөләйхә ул хатыннарның гаепләп сөйләгәннәрен ишеткәч, аларны кунакка чакырып, кешеләр җибәрде вә алар өчен яхшы урыннар вә хуш тәгамнар хәзерләде, кунаклар килеп ашарга**

**утыргач, һәрберсенә үткен пычаклар бирде вә: «Ий Йосыф, ул хатыннар янына чык», – дип әйтте. Хатыннар Йосыфны күргәч, бик олуг эш санадылар вә яннарына утыртырга теләделәр һәм Йосыфтан күзләрен ала алмыйча, тәгам кисәбез дип, кулларын кискәләп бетерделәр вә: «Аллаһы пакьтер, бу кеше түгелдер, бу һичкем түгел, мәгәр хөрмәтле фәрештәдер», – дип әйттеләр».**

«Йосыф», 12:31

Хатын-кызлар бердәм рәвештә Зөләйхага теләктәшлек күрсәтәләр.

قَالَتْ فَذَٰلِكُنَّ الَّذِي لُمْتُنَّنِي فِيهِ ۖ وَلَقَدْ رَاوَدتُّهُ عَن نَّفْسِهِ فَاسْتَعْصَمَ ۖ وَلَئِن لَّمْ يَفْعَلْ مَا آمُرُهُ لَيُسْجَنَنَّ وَلَيَكُونًا مِّنَ الصَّاغِرِينَ

**«Зөләйха әйтте: «Мине шуның хакында гаеп вә шелтә кылган кол, шул колдыр, дөрес мин аның белән якынлык кылырга әстәдем, ләкин ул теләмәде, сакланды». Соңрак Зөләйха хатыннардан үтенде: «Миңа якынлык кылырга өндәгез», – дип, ләкин хатыннар бар да Зөләйха теләгәнне теләделәр. Зөләйха әйтте: «Әгәр мин әмер кылганны эшләмәсә, ягъни якынлык кылмаса, әлбәттә, зинданга салдырырмын, хурлыкка төшкән кешеләрдән булыр».**

«Йосыф», 12:32

Әмма Йосыф галәйһиссәлам зинданнан да курыкмыйча, бай һәм чибәр хатын белән зина кылудан баш тарта, үзенең тәкъвалыгына тап төшерми. Шулай итеп, Зөләйханы мәхәббәттән, ә вәзирне гайбәтләрдән коткару өчен Йосыфны күп елларга төрмәгә ябалар.

قَالَ رَبِّ السِّجْنُ أَحَبُّ إِلَيَّ مِمَّا يَدْعُونَنِي إِلَيْهِ ۖ وَإِلَّا تَصْرِفْ عَنِّي كَيْدَهُنَّ أَصْبُ إِلَيْهِنَّ وَأَكُن مِّنَ الْجَاهِلِينَ

**«Йосыф әйтте: «Ий Рабби! Мине чакырган зинага караганда миңа зиндан яхшырак, әгәр ул хатыннарның хәйләләрен миннән Үзең бетермәсәң, ул вакытта мин аларга авышырмын вә ярамаган эшне эшләп җаһилләрдән булырмын».**

«Йосыф», 12:33

فَاسْتَجَابَ لَهُ رَبُّهُ فَصَرَفَ عَنْهُ كَيْدَهُنَّ ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

**«Йосыфның догасын Раббысы кабул кылды һәм Йосыфтан ул хатыннарның хәйләсен җибәрде, дөреслектә Ул сүзләрне Ишетүче вә хәлләрне Белүче».**

«Йосыф», 12:34

Зөләйха бу чара авырлыклардан котылырга ярдәм итәчәгенә ышана, вәзир исә үз гаиләсенең намусын сакларга тели.

Зөләйха үзе әхлаклы һәм зирәк хатын-кыз була, бары Йосыфка булган кайнар мәхәббәте аны аек акылдан мәхрүм итә. Шуңа күрә Йосыф галәйһиссәлам таш төрмәдә утырса, Зөләйха үзе һәм вәзир бу чакта «намус төрмәсендә» ябылып калалар: алар гаепсез кешегә зыян салуларын аңлыйлар. Зөләйха вөҗдан газабыннан шулкадәр җәфалана ки, хәтта үзенең матурлыгын һәм яшьлеген югалта. Шулай итеп ул үзенең нәфесе һәм Йосыфка карата булган харам хисләре өчен җавап бирә. Әмма күз яшьләре һәм ихлас күңелдән тәүбә итүе сәбәпле, ул әлеге гөнаһтан пакьләнә.

**Төрмәдән ireккә чыгу**

Тәкъдиренә язганга күрә, Йосыф галәйһиссәлам белән тоткында бергә тагын Мисыр хакиме ялчысына якын торган кешеләр – эчемлекләр ташучы һәм пешекче була. Алар үзләренең төшләрен Йосыф белән урта-

клашалар: имеш, берсе йөземне изеп суын ала, икенчесе башында алып барган ипине кошлар чукый икән.

وَدَخَلَ مَعَهُ السِّجْنَ فَتَيَانِ ۖ قَالَ أَحَدُهُمَا إِنِّي أَرَانِي أَعْصِرُ خَمْرًا ۖ وَقَالَ الْآخَرُ إِنِّي أَرَانِي أَحْمِلُ فَوْقَ رَأْسِي خُبْزًا تَأْكُلُ الطَّيْرُ مِنْهُ ۖ نَبِّئْنَا بِتَأْوِيلِهِ ۖ إِنَّا نَرَاكَ مِنَ الْمُحْسِنِينَ

**«Вә аның белән бергә ике егет тә зинданга керде. Берсе хәмер ясаучы, икенчесе – икмәкче иде, алар төш күрделәр. Аларның берсе әйтте: «Мин төшемдә хәмер сыкканымны күрдем». Вә икенчесе әйтте: «Мин төшемдә икмәк күтәреп йөргәнемне күрдем, ул күтәргән икмәгемнән кошлар ашый имеш. Ий Йосыф, ул төшнең тәгъбире нәрсә, безгә сөйләп бир? Тәхкыйк, без сине яхшы кеше дип беләбез».**

«Йосыф», 12: 36

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

قَالَ لَا يَأْتِيكُمَا طَعَامٌ تُرْزَقَانِهِ إِلَّا نَبَّأْتُكُمَا بِتَأْوِيلِهِ قَبْلَ أَن يَأْتِيَكُمَا ۚ ذَٰلِكُمَا مِمَّا عَلَّمَنِي رَبِّي ۚ إِنِّي تَرَكْتُ مِلَّةَ قَوْمٍ لَّا يُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَهُم بِالْآخِرَةِ هُمْ كَافِرُونَ ﴿٣٧﴾ وَاتَّبَعْتُ مِلَّةَ آبَائِي إِبْرَاهِيمَ وَإِسْحَاقَ وَيَعْقُوبَ ۚ مَا كَانَ لَنَا أَن نُّشْرِكَ بِاللَّهِ مِن شَيْءٍ ۚ ذَٰلِكَ مِن فَضْلِ اللَّهِ عَلَيْنَا وَعَلَى النَّاسِ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَشْكُرُونَ ﴿٣٨﴾ يَا صَاحِبَيِ السِّجْنِ أَأَرْبَابٌ مُّتَفَرِّقُونَ خَيْرٌ أَمِ اللَّهُ الْوَاحِدُ الْقَهَّارُ ﴿٣٩﴾ مَا تَعْبُدُونَ مِن دُونِهِ إِلَّا أَسْمَاءً سَمَّيْتُمُوهَا أَنتُمْ وَآبَاؤُكُم مَّا أَنزَلَ اللَّهُ بِهَا مِن سُلْطَانٍ ۚ إِنِ الْحُكْمُ إِلَّا لِلَّهِ ۚ أَمَرَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٤٠﴾

يَا صَاحِبَيِ السِّجْنِ أَمَّا أَحَدُكُمَا فَيَسْقِي رَبَّهُ خَمْرًا ۖ وَأَمَّا الْآخَرُ فَيُصْلَبُ فَتَأْكُلُ الطَّيْرُ مِن رَّأْسِهِ ۚ قُضِيَ الْأَمْرُ الَّذِي فِيهِ تَسْتَفْتِيَانِ ﴿٤١﴾

**«Йосыф әйтте: «Мин сезгә башта, ашый торган ризыкларыгыз алдыгызга килмәс борын, ул ризыкларның нинди ризык икәнлеге белән хәбәр бирермен, бу эшем вә төшкә тәгъбир ясавым Раббымның өйрәтүе беләндер, тәхкыйк, мин Аллаһыга һәм дә Ахирәткә ышанмаган кешеләрне ташладым, алардан киселдем. Вә мин ата-бабаларым Ягъкуб, Исхак, Ибраһим диненә кердем, Аллаһыга берәр мәхлүкъны тиңдәш итү безнең өчен һич тә дөрес вә лаек түгел. Ошбу хак диндә булуыбыз безгә вә башка кешеләргә Аллаһының юмартлыгы вә рәхмәте, ләкин күп кешеләр бу зур нигъмәт дип белмиләр һәм Аллаһыга шөкер итмиләр.**

**Ий зиндандагы ике иптәшем! Ясалма күп илаһларга гыйбадәт кылу хәерлеме? Яки һич тиңдәше булмаган бөтен мәхлүкъның хуҗасы вә кодрәт иясе бер Аллаһыга гыйбадәт кылу хәерлеме? Әлбәттә, бер генә Аллаһыга гыйбадәт итү хәерле. Сез бер Аллаһыга гыйбадәт кылмыйсыз, мәгәр үзегез вә аталарыгыз илаһ дип исем биргән һичнәрсәгә ярамый вә файда бирми торган сыннарга гыйбадәт кыласыз, ул сыннарга гыйбадәт кылуның дөреслеге өчен Аллаһы һич дәлил иңдергәне юк, бу хакта хөкем итмәк фәкать Аллаһыга гына хастыр, башка затның хөкеме хөкем түгелдер, Ул – Аллаһы үзеннән башкага гыйбадәт кылмаска әмер кылды, бу Ислам дине – хак дин, ләкин күп кешеләр белмиләр. Ий зиндандагы ике иптәшем, инде күргән төшегезгә тәгъбир кылам: әмма берегез зинданнан чыгып әүвәлге урынында хәмер ясаучы булыр, әмма икенчегезне асарлар вә башын кошлар ашар. Егетләр: «Без төш**

**күрмәдек, уйнап кына әйткән идек», – диделәр. Йосыф әйтте: «Сез сорадыгыз – мин җавап бирдем, әлбәттә, эш мин тәгъбир кылганча булыр».**

«Йосыф», 12:37-41

Йосыф галәйһиссәлам төрмәдә үзенең хак юлга чакыру эшчәнлеген зинданда да дәвам итә. Ул төрмәне мәдрәсәгә әверелдерә. Монда аның төшләрне юрау сәләте дә ачыла.

Күпмедер вакыт узганнан соң, пешекчене үлем җәзасына тарталар, ә эчемлекләр йөртүчене гафу итеп, төрмәдән чыгаралар һәм ул янәдән хакимнең ялчысы булып эшли башлый. Йосыф галәйһиссәлам белән хушлашып, ул аның турында хуҗасы алдында искә алырга вәгъдә бирсә дә, сүзен оныта һәм Йосыф тагын берничә елга – Мисыр хакименең берәү дә юрап бирә алмаган төш күрүенә кадәр төрмәдә кала.

Күпмедер вакытлар үткәннән соң, Мисыр хакиме бер төш күрә, аны бернинди астрологлар, күрәзәчеләр, акыл ияләре дә юрый алмый.

قَالُوا أَضْغَاثُ أَحْلَامٍ ۖ وَمَا نَحْنُ بِتَأْوِيلِ الْأَحْلَامِ بِعَالِمِينَ ﴿٤٤﴾

**«Патшаның дуслары әйттеләр: «Бу төш саташу гына, без андый саташу төшләрнең тәгъбирен белмибез».**

«Йосыф», 12:44

Моны бары зинданда онытылып калган бер тоткын гына башкарып чыга ала – ул Йосыф була. Бу хакта эчемлекләр йөртүче искә төшереп җиткерә. Ул Йосыф галәйһиссәлам янына килеп:

– Ий, Йосыф! Җиде ябык сыер җиде таза сыерны кабып йотканны, ә җиде коры башак җиде яшел башакны ашаганны ничек юрарга? Мин синең төш юравыңны тапшырачакмын һәм сине төрмәдән чыгарырлар, – дип әйтә.

Йосыф галәйһиссәлам хакимнең төшен болай юрый: «Җиде таза сыер һәм җиде яшел башак җиде ел муллыкта яшәүне аңлата. Аннары җиде ел ачлык һәм коточкыч корылык киләчәк. Беренче җиде елда күбрәк иген чәчегез, ә уңышны җыеп алу вакыты җиткәч, үзегезгә туклану өчен кирәк булган кадәрен җыеп алыгыз да, калганын башакларда калдырыгыз һәм амбарларга кертеп урнаштырыгыз. Ачлык җиткәч, сез бу ашлыкны куллана алачаксыз. Җиде еллык ачлыктан соң муллык еллары җитәчәк һәм кешеләр янәдән имин, бәхетле тормышка ирешәчәкләр».

Хаким Йосыф галәйһиссәламнең хикмәтен югары бәяли һәм аны, барлык кешеләргә аның гаепсез булуын игълан итеп, азат итә. Әмма Йосыф шарт куя:

وَقَالَ الْمَلِكُ ائْتُونِي بِهِ ۖ فَلَمَّا جَاءَهُ الرَّسُولُ قَالَ ارْجِعْ إِلَىٰ رَبِّكَ فَاسْأَلْهُ مَا بَالُ النِّسْوَةِ اللَّاتِي قَطَّعْنَ أَيْدِيَهُنَّ ۚ إِنَّ رَبِّي بِكَيْدِهِنَّ عَلِيمٌ ﴿٥٠﴾

**«Патша әйтте: «Ул төш юраучы кешене зинданнан чыгарып миңа китерегез!» Чакыручы илче Йосыф янына килгәч, Йосыф илчегә болай дип әйтте: «Бар патшаңа кайтып әйт, мине күреп кулларын кискән хатыннарның миңа карата фикерләрен белсен. Хатыннарның хәйләсе вә минем хаксыз рәнҗетелгәнем ачыклансын өчен! Тәхкыйк минем Раббым аларның хәйләләрен белә».**

«Йосыф», 12:50

Йосыфның гаебе булмавын барысы да, шул исәптән Зөләйха да раслый.

قَالَ مَا خَطْبُكُنَّ إِذْ رَاوَدتُّنَّ يُوسُفَ عَن نَّفْسِهِ ۚ قُلْنَ حَاشَ لِلَّهِ مَا عَلِمْنَا عَلَيْهِ مِن سُوءٍ ۚ ﴿٥١﴾

**«Хатыннар әйттеләр: «Аллаһы сакласын, без Йосыфта бер явызлык та күрмәдек, ул пакьтер».**

«Йосыф», 12:51

Вәзирнең газиз хатыны Зөләйха да болай дип әйтә:

قَالَتِ امْرَأَتُ الْعَزِيزِ الْآنَ حَصْحَصَ الْحَقُّ أَنَا رَاوَدتُّهُ عَن نَّفْسِهِ وَإِنَّهُ لَمِنَ الصَّادِقِينَ ﴿٥١﴾

**«Менә хәзер хаклык өскә чыкты, Йосыфның миңа якынлык кылуын мин үзем эстәдем, әмма Йосыф хыянәт итмәде, аның сүзләре хак».**

«Йосыф», 12:51

Зөләйха бик тә ялварып үзенең җинаятен һәм Йосыфка булган мәхәббәтен аңлата. Ә Йосыф, үзенең югары әхлагы, акылы һәм зирәклеге аркасында баш казначы итеп билгеләнә һәм тол калган Зөләйхага өйләнә. Аңа Аллаһының рәхмәте белән яшьлеге һәм матурлыгы кире кайта.

Йосыф галәйһиссәлам үзе, Мисыр хакименең баш вәзире булып, барлык ил кешеләренең хөрмәтен казана. Йосыф галәйһиссәламнең тырышлыгы белән Мисыр җиде еллык корылыкны имин рәвештә кичерә. Киресенчә, күрше дәүләтләр авыр хәлдә кала, анда яшәүчеләр, ачлыктан интегеп, Мисырга барырга омтылалар. Алар арасында Йосыфның Фәләстыйнда яшәүче абыйлары да була. Туганнар белән очрашкач, Йосыф галәйһиссәлам аларны гафу итә, «Кылган гөнаһларыгызны Аллаһы ярлыкасын», – дип әйтә.

قَالَ لَا تَثْرِيبَ عَلَيْكُمُ الْيَوْمَ ۖ يَغْفِرُ اللَّهُ لَكُمْ ۖ وَهُوَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ ﴿٩٢﴾

**«Йосыф әйтте: «Бүген сезне гаепләп битәрләү юк, курыкмагыз, мин сезне хөкем итмим. Кылган гөнаһларыгызны Аллаһы ярлыкасын, Ул бик шәфкатьле вә рәхимле!»**

«Йосыф», 12:92

Шуннан соң алар кочаклашып, озак вакыт сөйләшәләр.

Моның хакта Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَرَفَعَ أَبَوَيْهِ عَلَى الْعَرْشِ وَخَرُّوا لَهُ سُجَّدًا ۖ وَقَالَ يَا أَبَتِ هَٰذَا تَأْوِيلُ رُؤْيَايَ مِن قَبْلُ قَدْ جَعَلَهَا رَبِّي حَقًّا ۖ وَقَدْ أَحْسَنَ بِي إِذْ أَخْرَجَنِي مِنَ السِّجْنِ وَجَاءَ بِكُم مِّنَ الْبَدْوِ مِن بَعْدِ أَن نَّزَغَ الشَّيْطَانُ بَيْنِي وَبَيْنَ إِخْوَتِي ۚ إِنَّ رَبِّي لَطِيفٌ لِّمَا يَشَاءُ ۚ إِنَّهُ هُوَ الْعَلِيمُ الْحَكِيمُ ﴿١٠٠﴾

**«(Шәһәргә кергәч,) Ул атасы белән анасын (махсус бик кыйммәтле) тәхеткә менгерде, һәм алар (уллары белән бергә сәлам бирер өчен) аңа сәҗдәгә капландылар. (Шулвакыт Йосыф галәйһиссәлам болай дип әйтте: «И әтием! Бу – минем элекке төшемнең аңлатмасы. Раббым аны (чынга ашырып,) бер хакыйкать итте. Ул мине зинданнан чыгарып; шәйтан минем белән кардәшләрем арасын бозганнан соң, сезне (барыгызны бергә бүген) чүлдән китереп, миңа (бик зур) игелек кылды. Һичшиксез, минем Раббым – теләгәннәренә мәрхәмәт итүче. Һичшиксез, Ул – (һәрнәрсәне) Белүче, Хикмәт иясе».**

«Йосыф», 12:100

Аллаһының рәхмәте белән Йосыф барлык авырлыкларны имин уза һәм күркәм сыйфатлар, гамәлләр: көч, байлык һәм хакимият белән бүләкләнә. Аллаһы – бар нәрсәгә дә көче җитүче Зат. Ул һәрвакытта да Үзенә иман китергән, итагатьлелек күрсәткән, ихластан Ислам диненә хезмәт иткән колларына булыша. Иманлы булу, туры юлдан тайпылмау һәм ныклык күрсәтү – мөселманнарның бурычы. Мөселманнарны авырлыклардан соң һәрвакытта да иминлек һәм бәхетле тормыш көтә. Коръән безгә бу хакта турыдан-туры болай дип әйтә:

سَيَجْعَلُ اللَّهُ بَعْدَ عُسْرٍ يُسْرًا ﴿٧﴾

**«Аллаһы (башка төшкән) кыенлык артыннан җиңеллек яралтачак».**

«Талак», 65:7

فَإِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٥﴾

**«Һичшиксез, авырлыктан соң җиңеллек бар».**

«Инширах / Ачмак», 94:5

Йосыф галәйһиссәлам белән булган барлык авыр вакыйгаларга карамастан, Аллаһының рәхмәте белән ул авырлыкларны җиңеп чыга һәм мәртәбәләргә ирешә, без бу хакта тирән фикер йөртергә тиешбез. Безнең әйләнә-тирәбездә була торган хәлләр Раббыбызның ихтыяры белән тормышка аша.

Аллаһы Тәгалә – Кодрәт иясе. Ул һәрвакытта да Үзенә иман китергән, Ислам дине юлында хезмәт иткән колларына ярдәм итә. Мөэминнәрнең вазифасы булып ихластан иман китерү, туры юлдан тайпылмау һәм диндә ныклык күрсәтү тора.

*Камил Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# 1. Фәтихә (Ачучы) сүрәсе

## Мәккә чоры, 7 аять

Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

Хәнәфи галимнәре фикеренчә, сүрәләр башындагы «бисмилләһ»ләр сүрәләрнең бер өлеше түгел, ә мөстәкыйль бер аять булып, сүрәләрнең араларын аерып тору һәм бәрәкәт бирү өчен кабатлана торган итеп иңгәннәр. 1. Барча мактаулар – галәмнәрнең Раббысы (Тәрбиячесе) булган Аллаһыга. 2. (Дөньяда һәрбер колына мәрхәмәтле булган) Рахманга, (иман китерүчеләргә генә Ахирәттә мәрхәмәтле булган) Рахимгә. 3. Хисап (Кыямәт) Көненең Хуҗасына! 4. (Аллаһы Тәгаләгә итагать иткән коллар:) «(Ий, Раббыбыз!) Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз! 5. Безне туры юлга күндер. 6. (Синең тарафтан) Нигъмәтләндерелгәннәрнең юлына. 7. Ачуың төшкән һәм (туры юлдан) адашканнарның (юлына) түгел!» (дип әйтәләр).

# 96. Әл-Галәкъ (Оешкан кан) сүрәсе

## Мәккә чоры, 19 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Расүлем! Һәрнәрсәне юктан бар итеп) Яратучы Раббың исеме белән (башлап, Коръәнне) укы! 2. Ул кешене (сөлек кебек аналыкка ябышып кан имеп тукланган аталандырылган күкәй күзәнәктән гыйбарәт) оеган каннан яратты. 3. Укы! Синең Раббың – чиксез юмартлык иясе. (Ул бернәрсә сорамыйча бирә.) 4. Ул каләм белән (язу язарга) өйрәтүче. 5. Кешегә (ишетү, күрү һәм аңлау кебек сәләтләр биреп һәм аятьләр иңдерү белән дәлилләр биреп,) белмәгән нәрсәләрен өйрәтүче. 6. Юк! (Кеше моның кадәр нигъмәтләрне аяк астына салып таптарга тиеш түгел.) (Кя-

фер) Кеше, һичшиксез, чиктән аша. 7. Чөнки ул үзен (Аллаһыга һәм иманга) мохтаҗ түгел дип саный. 8. Һичшиксез, (үлемнән соң) кайту синең Раббыңа бит. 9. Комачаулаган кешене күрдеңме? 10. Колга намаз укыган чагында? 11. Әгәр дә ул (колның намаз укуына комачаулаган кеше) туры юлда булса (да, комачаулау урынына ярдәмче булса). 12. Яки (потка табынырга үгетләү урынына ширектән саклануга һәм) тәкъвалыкка өндәсә (аның үзенә үк яхшырак булмас идеме)? 13. Әгәр дә ул ялган дип санаса һәм (аңардан) йөз чөерсә? 14. Аллаһы (аның кылганнарын) күреп торганын белмимени? 15. Юк! (Артык алай итмәсен!) Әгәр дә ул ваз кичмәсә, Без аны маңгай чәченнән тотачакбыз (һәм җәһәннәмгә атачакбыз). 16. Ялганчы һәм хаталыны маңгай чәченнән. 17. (Шул чакта) Мәҗлесен чакырсын (әйдә). 18. Без исә (аны җәһәннәм утына сөйрәп илтәчәк) зобаниларны чакырачакбыз. 19. Юк! Аңа буйсынма! Сәҗдә ит һәм (Раббыңа) якынай[1].

# 97. «Әл-Кадр» («Кадер») сүрәсе

## Мәккә чоры, 5 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән!

1. Һичшиксез, Без аны (мәңгелек могҗиза булган Коръән Кәримне) Кадер кичәсендә (Ләүһүл-Мәхфүздән тулы килеш беренче кат күккә)

---

[1] Риваятьтән күренгәнчә, Әбү Җәһел: «Тагын бер мәртәбә Мөхәммәднең сезнең арада сәҗдә кылганын күрсәм, муенына басачакмын һәм йөзен туфракка сөртәчәкмен!» – дигән. Бераздан аны намаз укыган чакта күргәч, янына килмәкче булган, ләкин кинәт кулларын бутый-бутый артына борылып кача башлаган. Аңардан бу гамәленең сәбәбен сораганнар. Ул исә: «Аның белән минем арамда бик күп канат һәм утлы чокыр күрдем!» – дигән. Моңа карата Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә миңа якынайган булса, фәрештәләр аның бөтен әгъзаларын өзгәләячәк иде», – дигән. Шуннан соң Әбү Җәһелне тотып янаган. Ул: «Бу вадида мин иң зур җәмәгатьле кешемен, син нәрсә белән миңа яныйсың?» – дигәч, шушы аяте кәримә иңгән. Моңа карата Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә бөтен өерен җыя башласа, зобанилар аны һәркемнең күзе алдында тотып алачаклар иде!» – дигән. (Бәйдави, Нәсәфи, Хазин)

иңдердек. 2. Кадер кичәсенең нинди икәнен син каян белә аласың? 3. Кадер кичәсе (Кадер кичәсе булмаган) мең айдан да хәерлерәк. (Шул сәбәпле, аңарда кылынган изге гамәл сиксән өч ел да дүрт ай буена бертуктаусыз кылынган гамәлгә тиң генә түгел, аннан да фазыйләтлерәк.) 4. Ул кичәдә, Раббыларының рөхсәте белән, фәрештәләр һәм Рух (дип тә аталган Җәбраил (галәйһиссәлам) һәртөрле эш өчен иңәләр. 5. Таң атканчы (фәрештәләр очраткан һәр иманлы ир һәм хатынга сәлам биргәннәре өчен,) ул (кичә) иминлек (булыр).

# 98. Әл-Бәййинә (Ачык дәлил) сүрәсе

## Мәдинә чоры, 8 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Яһүди һәм насаралар тәшкил иткән) Китап әһеленнән һәм (потка табынган) мөшрикләрдән кяфер булганнар ап-ачык дәлил килгәнче (көферлектән) аерылмадылар. 2. Аллаһыдан (җибәрелгән Мөхәммәд исемле) Расүл салләллаһу галәйһи вә сәлләм, ул (ялганнан) пакь булган сәхифәләрне (аларга) укый. 3. Аларда – (гаделлекне аңлаткан) дөрес язулар. 4. Китап бирелгән кешеләр үзләренә ачык дәлил килгәннән соң гына бүленделәр. 5. Аларга бит (үзләренең китапларында) диндә Аңа гына ихлас булып, (ялгыш ышанулардан ераклашып, бөтен пәйгамбәрләргә инанган) хәниф кешеләр буларак Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга, (фарыз) намаз укырга һәм зәкят бирергә әмер ителгән иде. Хак дин – менә шушы. 6. Һичшиксез, кяфер булган әһле китап һәм мөшрикләр – җәһәннәм утында. Алар анда мәңге калачаклар. Алар – барлыкларның иң яманнары[1].

---

[1] Бу аяте кәримәләр бәян иткәнчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм кебек ап-ачык дәлил үзләренә килгән хәлдә, аңа ышанмыйча, диненә кермәгән яһүди һәм насаралар, әһле китап булуларына карамастан, кяферлек сыйфатыннан котылмаганнар. Заманыбыздагы кайбер ялгыш фикерле теологлар аларны җәннәткә кертергә маташсалар да, бу аяте кәримә,

7. Һичшиксез, иман китергән һәм (намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек) изге гамәлләр кылганнар. Һичшиксез, алар – барлыкларның иң хәерлеләре. 8. Раббылары хозурында аларга әҗер итеп (сарайлары һәм агачлары) асларыннан елгалар агып торган Гаден җәннәтләре булыр. Алар анда мәңге калачак. Аллаһы алардан разый, алар да Аннан разыйлар. Бу Раббыларыннан курыккан кешеләр өчен булыр.

# 99. Әз-Зәлзәлә (Җир тетрәү) сүрәсе

## Мәдинә чоры, 8 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Сурга өрелеп,) Җир үзенең (тәкъдирендә билгеләнгән) тетрәү белән тетрәгәч. 2. Җир (эчендә булган үлеләр һәм хәзинәләр кебек бөтен) йөкләрен (тышка атып, уртага) чыгаргач. 3. Һәм кеше (коты алынып): «Моңа ни булган?» – дигәч. 4. Шул көнне ул (телгә килер дә, өстендә кылынган яхшы һәм яман) хәбәрләрен (халыкка) сөйләр. 5. Чөнки синең Раббың аңа (сөйләп бирүен) вәхи итте (һәм өстендә кылынган нәрсәләрне хәбәр итүен әмер итте). 6. Ул көнне кешеләр, гамәлләре үзләренә күрсәтелсен өчен, (йөзләре ак һәм кара, имин һәм куркак) төркем-төркем хәлдә (каберләреннән хисап мәйданына) чыгачаклар. 7. Кем дә кем (дөньяда) зәррә авырлыгы кадәр генә игелек кыла, аны (Ахирәттә) күрәчәк. 8. Кем дә кем (дөньяда) зәррә авырлыгы кадәр генә начарлык кыла, аны (Ахирәттә) күрәчәк.

---

әһле китаптан булса да, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ышанмаган һәм үз динен калдырып Исламга кермәгән кяферләрнең һәммәсенең дә җәһәннәмдә мәңге калачагына кире какмаслык дәлил. Мөфәссирләр бәян иткәнчә, хәниф – араларында бернинди аерма ясамыйча, бөтен пәйгамбәрләргә инанган кеше дигәнне белдерә. Шулай булгач, пәйгамбәрләрнең иң шәрәфлесе булган Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә инанмаган кеше, хәниф булмаганы өчен, җәннәт йөзен дә күрә алмас.

# 100. Әл-Гәәдийәәт (Чабып баручылар) сүрәсе

## Мәккә чоры, 11 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Җиһад юлында) Тыннары бетеп чабып барган атлар белән ант итәмен[1]! 2. (Төнлә ташлыктан үткәндә тояклары белән) Очкыннар чыгарганнар (атлар) белән (ант итәмен). 3. Таң вакытында (дошманга каршы) яу ясаучылар белән (ант итәмен). 4. Алар анда тузан күтәрделәр. 5. Шуннан соң алар анда төркем уртасына бәреп керделәр. 6. (Менә боларның бөтенесе белән ант итәмен) Һичшиксез, кеше – Раббысына шөкер кылмаучы. 7. Һәм, һичшиксез, ул моңа (көфре нигъмәтенә, саранлыгына һәм баш күтәрүенә) үзе шаһит. 8. Һичшиксез, ул малны бик нык ярата. 9. Әллә ул белмиме, каберләрдәгеләр терелтелеп чыгарылгач. 10. Күкрәкләрдә булганнар ачылгач. 11. Һичшиксез, ул көнне Раббылары алардан хәбәрдар (шуңа күрә һәркемгә тиеш булган әҗерен яки җәзасын бирәчәк)[2].

[1] Риваятьтән күренгәнчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Кинанә улларына бер отряд җибәргән булган, ләкин Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә алардан бер ай буена бернинди хәбәр дә килмәгән, шул сәбәпле ул бик борчылган. Менә шуңа карата әлеге сүрә иңгән, башындагы антлар Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә аларның җиңүен белдергән. (Бәйдави, Тәнвир әл-микъбас, Хашият әс-Сави, Лүбаб ән-нукуль)

[2] Аллаһы Тәгалә бу сүрәдә кяфернең өч начар сыйфаты хакында өч төрле ант сүзе әйткән. Бер яктан, Аллаһ юлында яу кырына чыккан мөҗаһидләрнең атларының өч сыйфаты бәян ителеп, аларның бөеклеге белдерелсә, икенче яктан, дошман өстенә җибәрелгән мөҗаһидләрнең җиңүләре турында сөенечле хәбәр Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирештерелгән, шуның аркылы кешенең белә торып нигъмәт кадерен белмәве, малга хирыслыгы һәм Ахирәттән гафләте шелтәләнгән.

# 101. Әл-Карига (Ишек каккан) сүрәсе

## Мәккә чоры, 11 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Сурга өрелгәч кубачак) Каты тавыш белән (йөрәкләргә) кагачак вакыйга! 2. Нәрсә ул каты тавыш белән (йөрәкләргә) кагачак вакыйга? 3. Каты тавыш белән (йөрәкләргә) кагачак вакыйганың ни икәнен син каян белә аласың? 4. Ул көнне кешеләр (ут тирәсендә сорышып) таралган күбәләкләр кебек (төркем-төркем, түбән, зәгыйфь һәм калтыранган хәлдә, үзләрен чакыручыга таба, очкан кебек йөгереп баручылар) булачак. 5. Таулар исә теткәләнгән йон кебек булачак. (Әнә шул көнне сурның каты тавышы аларның йөрәкләренә кагачак.) 6. (Шул көнне) Кемнең (савапларын үлчәгән) мизаннары авыр тарта… 7. Ул рәхәт тормышта булыр. 8. Әмма кемнең (бернинди игелекле гамәлләре булмаганлыктан яки, гөнаһлары савапларыннан авыррак басу сәбәпле, савапларын үлчәгән) мизаннары җиңел тарта. 9. Аның сыеныр урыны – Һавия (булыр). 10. Аның ни (дәрәҗәдә коточкыч газап урыны) икәнен син каян белә аласың? 11. (Ул – соң дәрәҗә) Кызган ут (җәһәннәмнең иң аскы каты булган бу урынга баштүбән ыргытылган гөнаһлылар җитмеш елдан соң гына төбенә төшеп җитәчәкләр).

# 102. Әт-Тәкәәсүр (Арттыру) сүрәсе

## Мәккә чоры, 8 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Малыгызны, балаларыгызны һәм кайбер өстенлекләрегезне) Арттыруга хирыслыгыгыз сезне (Раббыгызга итагатьле булудан) читләштерде. 2. (Әмма сез) Каберләргә кергәнчегә кадәр. 3. Юк! Тиздән (җан бугазга ки-

леп терәлгәч һәм каберегезгә кергәч, кылган эшегезнең начар нәтиҗәсен) беләчәксез. 4. Тагын бер юк! Тиздән беләчәксез. 5. Юк! Әгәр дә сез (күз белән күргән кебек) гыйлем белән (алдыгыздагы хәвефләрне) белсәгез иде. 6. Сез, һичшиксез, Утны күрәчәксез. 7. Сез аны хакыйкый хәлдә, һичшиксез, күрәчәксез. 8. Шуннан соң сез ул көнне (дөньяда сезне Раббыгызга итагать һәм шөкер итүгә комачаулаган) нигъмәтләрдән соралачаксыз[1].

# 103. Әл-Гаср (Икенде вакыты) сүрәсе

## Мәккә чоры, 3 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Кешеләрнең эшләре күп булган вакытка туры килгән) Икенде намазы вакыты белән ант итәмен. 2. Һичшиксез, кешеләр зарарда (чөнки гомерләрен Ахirәттә һич кенә дә файда китермәячәк бозык теләкләрен канәгатьләндерүгә сарыф итәләр). 3. Бары иман китергән, (намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек) изге гамәлләр кылган һәм бер-берләрен хакка өндәгән һәм бер-берләрен сабырлыкка өндәгән кешеләр булмасалар гына.

# 104. Әл-Һүмәзә (Яла ягучы) сүрәсе

## Мәккә чоры, 9 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

---

[1] Бик күп хәдис-шәрифтә хөрмә һәм су кебек зарури ашамлык һәм эчемлек өчен дә соралу, бигрәк тә иминлек һәм сәламәтлек, күз һәм колак кебек нигъмәтләр өчен шөкер кылуның соралуы белдерелгән булса да, бу соралу инкяр иткән һәм фарызларны санга сукмаган кешеләргә карата газапка әйләнгән шелтә сыйфатына ия булачак, гыйбадәтләрен кылган мөэминнәргә карата исә нигъмәтне хәтерләтү формасында булачак (Хазин).

1. Артта яманлаучы һәм йөзгә карап мыскыл итүче (Әхнәс бине Шүрәйк, Үбәй бине Хәләф кебек) һәр (кяфер) кемсәгә ни үкенеч! 2. Ул күп мал җыйган да шуны кат-кат саный. 3. Ул малы аны (дөньяда) мәңге кылачак дип саный. 4. Юк! Ул (ыргытылган һәрнәрсәне тар-мар иткән) Хутәмәгә ыргытылачак. 5. Хутәмәнең ни икәнен син каян беләаласың? 6. Аллаһының кабызган уты. 7. Ул (ут кеше гәүдәсендәге бөтен әгъзаларны ашап бетереп, иң азакта) йөрәкләргә кадәр үтәчәк. 8. Һичшиксез, ул (ут, эченә һич һава кермәслек һәм аннан бер тавыш чыкмаслык шәкелдә,) аларның өсләрендә булачак. 9. Сузылган баганалар эчендә (куллары һәм аяклары зынҗыр һәм богаулар белән кат-кат богауланачак).

# 105. Әл-Фил (Фил) сүрәсе

## Мәккә чоры, 5 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Расүлем!) Раббыңның фил ияләренә ни кылганын күрмәдеңме? 2. Ул аларның (Кәгъбәне җимерү) хәйләсен бушка чыгармадымы? 3. Аларның өсләренә көтү-көтү кошлар җибәрмәдеме? 4. Алар (кошлар) аларга яндырылган балчыктан ташлар аталар иде. 5. Ул (Аллаһы Тәгалә) аларны (бөҗәкләр тарафыннан) ашалып беткән иген яфраклары кебек итте[1].

# 106. Курайш (Кораешләр) сүрәсе

## Мәккә чоры, 4 аять

[1] Йәмән хөкемдары Әбраһә Сәнгада бер потханә төзеткән һәм Мәккәгә йөргән хаҗиларны шуңа хаҗ кылдырмакчы булган. Кинанә кабиләсеннән бер кеше шул чиркәү эченә кереп, анда ут төртеп янгын чыгарган. Моңа бик ачуы чыккан Әбраһә фил гаскәре белән Мәккәгә таба юлга чыккан. Бу вакыйга Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тууына илле көн кала мәйданга килгән, һәм аның киләчәгенә бер ишарә дә булган. Аллаһы Тәгалә, бу сүрәдә белдергәнчә, Әбраһәне бөтен гаскәре белән һәлак иткән.

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Раббылары) Корәешне (һәм Мәккә халкын Әбраһәнең филле гаскәреннән) берләштерер өчен. 2. Аларны кыш (Йәмәнгә) һәм җәй (Шамдагы сәүдә сәфәрләрендә) берләштерер өчен (саклады). 3. Шушы Бәйтнең Раббысына гыйбадәт кылсыннар (Кәгъбәтулланы фил гаскәреннән һәм бөтен куркынычлардан Ул гына саклады). 4. (Үләксә ашарга мохтаҗ иткән) Ачлыктан соң аларны ашаткан, (махау һәм ваба кебек йогышлы авырулар кебек) куркудан аларны имин иткән Затка (гыйбадәт кылсыннар).

# 107. Әл-Мәгүн (Изгелек кылу) сүрәсе

## Мәккә чоры, 7 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Ахирәттәге) Җәзаны ялган дип санаган кешене күрдеңме? 2. Ул – ятимне (малына кул сузар өчен аны) куучы[1]. 3. (Ахирәткә ышанмаганы өчен, кылган игелек бушка китә дип санаганы өчен, гаиләсен дә, башкаларны да) Юксылны ашатырга өндәми. 4. Намаз укыганнарга (монафикъларга) ни үкенеч! 5. Намазларында гафилләргә[2]. 6. Алар (кешеләрнең үзләрен ятууларын һәм мактаганнарын гел көтеп торганга күрә,

[1] Аяте кәриманең Әбү Җәһел, Гамр бине Гаиз, Гас бине Ваил, Вәлид бине Могыйра яки монафикъларның башлыгы Габдулла бине Үбәй хакында иңгәненә кагылышы төрле риваятьләр бар. Мәсәлән, бервакыт бер ятим, ялангач килеш, васыять бирүчесе булган Әбү Җәһелгә килеп аңардан үзенең малын сорагач, теге аны ачуланып куып җибәргән. Җаһилият дәверендә мөшрикләр хатыннарга һәм балаларга мирастан өлеш бирмәгәннәре өчен, монда хакның мирас мәгънәсендә дә бәяләндерергә мөмкин (Җәлаләйн, Сави).

[2] Алар укыган-укымаганнарына, вакытның кереп чыгуына һәм ничә рәкәгать укыганнарына әһәмият бирмиләр, укысалар да Раббыларын уйламыйлар һәм рөкеннәрне игътибар белән үтәмиләр, шуңа күрә тавык бөртек чукыган кебек укыйлар. Кайберләре исә намазның фарызлыгына ышанмаганнары өчен, берүзләре генә булган чакта, гомумән, укып та тормыйлар.

һәрвакыт) икейөзлеләнәләр. 7. Изгелек кылуны тыялар. (Зәкят һәм садака кебек файдалы нәрсәләрне бирүдән тыялар.)

# 108. Әл-Кәүсәр (Муллык) сүрәсе

## Мәккә чоры, 3 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. Һичшиксез, Без сиңа Кәүсәрне бирдек[1]. 2. (Шулай булгач) Раббың өчен намаз укы һәм (Аның исеме белән) корбан чал (да, корбан итләрен мескеннәргә тарат). 3. Һичшиксез, сиңа ачу тотучы үзе бөтен хәерләрдән мәхрүм ителгән[2].

# 109. Әл-Кәфирун (Кяферләр) сүрәсе

## Мәккә чоры, 6 аять

---

[1] «Кәүсәр» сүзе асылында «бик күп хәер» мәгънәсендә килсә дә, биредә гыйлем, гамәл, ике җиһан шәрәфе, Коръәни Кәрим, пәйгамбәрлек, хикмәт, өммәтенең күплеге кебек мәгънәләр белән тәфсир ителгән. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзеннән Кәүсәрнең нәрсә икәнлеге соралгач: «Аллаһы Җәннәттә миңа биргән һәм сөттән аграк, балдан татлырак, кардан салкынрак, күбектән йомшаграк бер елга. Аның ярлары – алтыннан, төбе – энҗе һәм якут, туфрагы – мисектән дә хуш ислерәк, кәсәләре исә күктәге йолдызлар кадәр күп. Аннан бер генә мәртәбә эчкән кеше мәңге сусамаячак», – дип әйтә. Кайбер хәдисләрдә исә Кәүсәрнең Мәхшәрдә Сыйраттан алда булган бер хавыз дигән риваяте дә бар. Казый Гыяд (рахимәһуллаһ) бәян иткәнчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең берсе – Сыйраттан алда, икенчесе Сыйраттан соң ике хавызы булып, икесенә дә Кәүсәр исеме бирелгән. (Бәйдави, Нәсәфи, Хазин, Алуси).

[2] Мәккә чорында Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең беренче улы Касыйм ике яшендә үлеп киткәч, мөшрикләрдән Гас бине Ваил Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә «нәселе корыган кеше» мәгънәсендә килә торган «әбтәр» кушаматы тага. Шуннан соң менә шушы аяте кәримә иңеп, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Кыяләткә кадәр бөтен мөэминнәрнең атасы булганын, шул сәбәпле аның хатирәсе мәңге яшәячәген, аеруча бөтен мөнбәрләрдә, азаннарда, камәтләрдә һәм һәр галимнең телендә Аллаһы Тәгаләдән соң икенче булып телгә алыначагын белдергән.

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Расүлем! Иман итмәячәкләре Аллаһыга билгеле булган аерым мөшрикләргә) Әйт: «Ий, кяферләр! 2. Мин сез табынган нәрсәләргә табынмыйм. 3. Сез дә (хәзерге вакытта) мин гыйбадәт кылган Затка табынмыйсыз. 4. Мин сез табынган нәрсәләргә (беркайчан да) табыначак түгелмен. 5. Сез дә (беркайчан да) мин гыйбадәт кылган Затка табынмаячаксыз. 6. Сезгә үз динегез (сез инде аны калдыра алмаячаксыз), миңа үз динем (мин дә аны беркайчан да кире какмаячакмын)»[1].

# 110. Ән-Нәср (Ярдәм) сүрәсе

## Мәдинә чоры, 3 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

---

[1] Сүрә араларында Гас бине Ваил, Вәлид бине Мугыйрә һәм Үмәййә бине Хәләф кебек ата мөшрикләр булган бер төркем турында иңгән. Алар Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килеп: «Ий Мөхәммәд! Әйдә, син безнең динебезгә ияр, без дә синең динеңә иярербез. Бер ел син безнең илаһларыбызга табын, бер ел без синең илаһыңа гыйбадәт кылырбыз. Әгәр дә син китергән нәрсә дөрес булса, без аннан насыйбыбызны алган булырбыз, юк икән, әгәр дә безнең кулыбыздагы хәерлерәк икән, син дә аннан насыйбыңны алган булырсың», – дигән тәкъдимнәренә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аңа башка берәүне тиңдәш куюдан Аллаһка сыенамын», – диде. Шулвакыт: «Алайса һичьюгы потларыбыздан берсенә булса да кулыңны суз да, без сине тәсдыйк итик һәм илаһыңа гыйбадәт кылыйк», – дигәч, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм вәхи көтә башлаган һәм шул мәлдә шушы сүрә иңгән. Шуннан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм иртән иртүк Харам мәчетенә киткән һәм бу тәкъдим белән килүчеләр дә араларында булган олугларга бу сүрәне укыган. Шулчак Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзләренә бирешүеннән тәмам өметләрен өзгәннәр һәм аңа да, сәхабәләренә дә җәфалауларны арттырганнар. Шул сәбәпле, бу сүрә иман итмәячәкләре әзәлдә билгеле булган бер төркем кяферләр хакында иңгәне өчен, монда көферлеккә карата бер йомшаклык яки җиһадка бер комачау турында сүз дә бара алмый. Шуңа күрә бу сүрәнең җиһад аяте белән нәсех ителүе хөкеме чыгарыла алмый. Әмма һәрбер фирканың каршы якны үз динендә ирекле калдыру, бер-берен кире кагу мәгънәсендә аңлатылса, җиһад аятьләре белән нәсех ителгәнен кабул итүебез тиеш була (Бәйдави, Нәсәфи, Хазин).

1. (Расүлем!) Аллаһның (дошманнарыңа каршы сиңа) ярдәме һәм (ширектә яшәгән өлкәләрне) җиңү килгәч. 2. Һәм син кешеләрне, төркем-төркем булып, Аллаһының диненә кергәннәрен күргән чагында. 3. Раббыңны мактап тәсбих әйт һәм Аңардан гафу сора. Һичшиксез, Ул – тәүбәләрне кабул итүче.

# 111. Мәсәд сүрәсе

## Мәккә чоры, 5 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. Әбү Ләһәбнең (Расүлуллаһка салләллаһу галәйһи вә сәлләм ыргыту өчен таш алган) ике кулы да корысын, һәлак булсын да. 2. Малы да, ирешкән нәрсәләре дә (башына киләчәк газаплардан) аны коткармады. 3. Ул ялкынлы Утка керәчәк. 4. Утыннар ташучы булган хатыны да. 5. Аның муенында тыгыз үрелгән бау булачак[1].

[1] Ибне Габбастан (радыяллаһу ганһүмә) риваять ителгәнчә, иң якын туганнарын куркыту әмере алган Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Сафа калкулыгына менеп, Корәеш ыруларын Исламга дәгъват итеп, аларны алдагы каты газаптан куркыткач, Әбү Ләһәб: «Ни үкенеч! Без бер җитди нәрсә дип эшебезне калдырып җыелдык, син безне шуның өчен чакырдыңмыни?» – дигән. Башка бер риваятьтән күренгәнчә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ыргытыр өчен ул кулына таш алган, менә бу сүрә белән куллары да, үзе дә ләгънәтләнгән. Ул һәрвакыт: «Әгәр дә мәгәр бертуганымның улының әйткәне хак булса, малымны һәм өч улымны биреп котылырмын», – дип әйтә торган булган. Әмма Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бәддогасы белән бер улын арыслан ботарлаган, үзе дә Бәдер вакыйгасыннан соң җиде төн үтүгә йогышлы авыру эләктереп һәлак булган, авыруын йоктырудан куркып, якыннары аңардан ерак торганнары өчен, өч көн шушы хәлдә калып ислән башлаган. Оят йөзеннән аны бер чокыр казып таяклар белән шунда төрткәләп төшергәннәр һәм өстенә ташлар өеп куйганнар. Өмме Җәмил исемле хатыны исә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең юлына түшәр өчен чәнечкеләр, тигәнәкләр җыя һәм шуларны бер бау белән бәйләп җилкәсендә ташый торган булган. Бик затлы нәселдән булуына карамастан, саранлыгы сәбәпле һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата бик каты нәфрәте йөзеннән, бу эшне шәхсән үзе башкара торган булган. Шуның өчен муенында җәһәннәм богаулары һәм сыртында ут утыннары булган хәлдә җәһәннәмгә керәчәге бәян ителгән (Бәйдави, Нәсәфи).

# 112. Әл-Ихлас сүрәсе

## Мәккә чоры, 4 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Расүлем!) Әйт: «Ул Аллаһы – бердәнбер. 2. Аллаһы – (бернәрсәгә дә) Мохтаҗ булмаучы. 3. Ул тудырмаган һәм тудырылмаган. 4. Һич беркем Аңа (бер яктан да охшаш, иш һәм) тиң түгел»[1].

# 113. Әл-Фәләкъ (Таң) сүрәсе

## Мәккә чоры (башка риваятьләр буенча Мәдинә чорында), 5 аять[2]

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

---

[1] Укылган вакытта савап ягыннан Коръән Кәримнең өчтән беренә тиң булган бу сүрә Корәеш мөшрикләренең Расүлуллаһка салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә Мөхәммәд! Безне гыйбадәт кылырга дәгъват кылган ул Раббыңны безгә аңлатып бир», – дип әйтүләренә җавап итеп иңгән һәм Аллаһы Тәгаләнең асыл Затын аңлаудан гаҗиз булган колларга Аны иң әһәмиятле кайбер сыйфатлары белән таныткан.

[2] Бик күп сәхабәдән риваять ителгәнчә, яһүдиләрдән Ләбид бине Әгъсам исемле бер кеше, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең берничә чәч бөртеген һәм тарак тешләреннән берничәсен кулга төшереп, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сихер ясый. Шул сәбәпле, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм берничә көн авырый. Шуннан Җәбраил галәйһиссәлам килеп аңа: «Яһүдиләрдән бер адәм, сиңа сихер ясау өчен, кайбер җепләргә төеннәр төйнәп фәлән кое төбенә ташлады», – дип әйтә. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гали радыяллаһу ганһене җибәрә. Ул, кое төбендәге бер ташны куптарып, аның астында Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тарагына эләгеп калган чәчләрен һәм тарак тешләрен табып ала. Бу чәчләрдә энә белән унбер төен ясалган була. Боларның барысын да алып, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә китергәч, Җәбраил галәйһиссәлам барлыгы унбер аяте кәримәдән торган бу ике сүрә белән килә һәм аларны Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә укып, өрә. Ул һәр аятьне укыган саен, төеннәрнең берсе чишелә бара һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер җиңеллек тоя башлый. Нәтиҗәдә, барлык төеннәр дә чишелеп беткәч, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм баулардан ычкынган шикелле рәхәтләнеп китә. (Бәйдави, Нәсәфи, Алуси). Күз буяу һәм сихернең чынлыгы хакында карагыз: «Әл-Бәкара» сүрәсе, 102.

1. (Расүлем!) Әйт: «Таңның Раббысына сыенамын. 2. Ул яраткан (кешеләр һәм җеннәрдән булган бөтен начар) нәрсәләрнең зарарыннан. 3. (Караңгылыгы һәрнәрсә өстенә төшеп,) Каплаган чакта куе караңгылык зарарыннан. 4. (Җепләргә ясаган) Төеннәргә (төкерә-төкерә) өргән (сихерче) җаннарның зарарыннан да. 5. Янә көнләшүченең көнләшкән чагындагы зарарыннан да».

# 114. Ән-Нәс (Кешеләр) сүрәсе

## Мәккә чоры (башка риваятьләр буенча Мәдинә чорында), 6 аять

Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһы исеме белән!

1. (Расүлем!) Әйт: «Сыенамын (бөтен) кешеләрнең (яратучысы һәм тәрбия итүчесе булган) Раббысына. 2. Кешеләрнең (идарә итүчесе булган) хуҗасына. 3. Кешеләрнең (гыйбадәткә лаек бердәнбер) илаһына. 4. Вәсвәсә кылучы булганның һәм (кол Раббысын телгә алган чакта) качып китүченең (шәйтанның) явызлыгыннан. 5. Ул (телләре белән зикердә булып күренсәләр дә, күңелләре белән зикердән гафил булган) кешеләрнең күкрәкләренә вәсвәсә бирә. 6. (Ул шәйтаннар) Җеннәрдән һәм кешеләрдән.

# Нәсыйхәт

# Ихлас бәяны

Факыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди радыяллаһу ганһе Мөхәммәд бине Фазыл үзенең иснәде (хәдисләрне эзлекле риваять итү) белән Мөхәммәд бине Ләбәедтән риваять итеп сөйләде: «Хакыйкатьтә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Сез курка торган нәрсәләрнең иң куркынычы кечкенә ширектер». Аннан: «Әй Аллаһының Илчесе, нәрсә ул кечкенә ширек?» – дип сорадылар. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рия, ягъни кешеләр күрә торган җирдә гамәлен яхшылап үти, әмма алар күрмәгәндә теләсә ничек үти, бәлки үтәмичә дә калдыра», – диде. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Бәндәләрне гамәлләре хисабынча җәза кыла торган көндә дөньяда рия кылучыларга барыгыз, аларга карагыз. Алар каршында изгелекне табарсызмы?»

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: Аларның дөньядагы эшләре алдау хозурында булды, шул сәбәпле, Ахирәттә алдау хозурында мөгамәлә кылынырлар. Ул алдау Аллаһы Тәгалә әйткәнчәдер:

إِنَّ الْمُنَافِقِينَ يُخَادِعُونَ اللَّهَ وَهُوَ خَادِعُهُمْ

**«Дөреслектә монафикълар Аллаһыны алдыйлар, ләкин киресенчә, Аллаһы Тәгалә аларны алдаучыдыр».**

«Нисә / Хатыннар», 4:142

Ягъни аларны алдау җәзасы белән җәзалар, гамәлләренең савабы юкка чыгар. Янә Аллаһы Тәгалә әйтер: «Шундый бәндәләргә барыгыз, алар өчен гамәл кылдыгыз, Минем каршымда гамәлләрегез өчен савап юк. Чөнки ул гамәлләр ихластан булмады». Бәндә савапны вәҗиб итми, мәгәр аның гамәле һәркайчан Аллаһы Тәгалә өчен ихластан булса, савапны вәҗиб итә. Әгәр Аллаһы Тәгалә өчен булмастан, башка өчен булса, ул гамәлдә ширек булыр һәм Аллаһы Тәгалә аннан бизүчедер».

Факыйһ үзенең иснәде белән Әбү Сәгъдтән, ул Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән, ә ул Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән риваять итә. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Мин ширек китерүчеләрне ширектән моңсыз кылам, ягъни Мин ширек белән кылынган гамәлдән баймын. Бер кеше гамәл кылганда Миннән башканы ширек кылса, мин мондый гамәлдән бизүчемен». Янә әйтелде: «Бу хәбәрдә гамәл кылучы кешедән булучы дәлил шуның хозурынадыр, дөреслектә Аллаһы Тәгалә гамәлдән һич нәрсәне кабул итмәс, мәгәр Аллаһының Үзе өчен кылынган ихлас булганын гына кабул итәр. Ахирәттә аның өчен савап юктыр һәм аның барачак җире җәһәннәм сараедыр». Моңа Аллаһы Тәгаләнең сүзе дәлил булып тора:

مَّن كَانَ يُرِيدُ الْعَاجِلَةَ عَجَّلْنَا لَهُ فِيهَا مَا نَشَاءُ لِمَن نُّرِيدُ ثُمَّ جَعَلْنَا لَهُ جَهَنَّمَ يَصْلَاهَا مَذْمُومًا مَّدْحُورًا ﴿١٨﴾

**«Бер кеше дөньяны теләсә, аның өчен ул дөньяны ашыктырырбыз, ягъни берәү үзенең гамәле белән дөньяны теләсә, Ахирәт савабын теләмәсә, ул кешегә дөньяда теләгән кадәр дөнья максатларыннан булучы нәрсәне бирербез».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:18

Янә әйтелде: «Нинди теләк булса да, без бирергә теләгән кешегә үз теләгебез белән бирербез, ул бәндә теләге белән түгелдер. Моның соңында җәһәннәм кылдык, ягъни ул кеше өчен җәһәннәмне вәҗиб иттек. Ул җәһәннәмгә хур булып керер. Хурлыкны вәҗиб итәрләр, ягъни үз-үзен һәм үзеннән башка кешене ташланган хәлдә хурлар, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән ерак булыр. Бер кеше Ахирәтне, ягъни Ахирәт савабын теләсә, Ахирәткә муафыйк булган тырышу белән Ахирәт өчен тырышса, изге гамәлләрдән булган бер гамәлне Аллаһы Тәгаләгә ихлас булган хәлдә Ахирәт өчен кылса һәм ул гамәле белән мөэмин булса, (чөнки Аллаһы Тәгалә гамәлне иманнан башка кабул итмәс) алар, ягъни гамәл кылучылар

һәм Ахирәт савабын теләүчеләр Ахирәттә шөкер кыларлар, ягъни аларның гамәле кабул ителер. Бу төрле кешеләргә дә, ягъни Аллаһы Тәгалә өчен ихлас күңел белән кылган кешеләргә синең Раббыңның бүләген бирер. Һәр ике төрле төркемгә Аллаһының ризыгыннан Раббыңның бүләге булмады, ягъни Аллаһының ризыгы дөньяда мөэмин, кяфер, изге һәм яман булуга карамастан, берсеннән дә тыелмады. Тәхкыйк Аллаһы Тәгалә бу аятьтә бәян кылды.

**«Дөреслектә, Аллаһыдан башкага гамәл кылучы өчен савап юк. Ахирәттә дә аның барачак урыны җәһәннәмдер. Янә бер кеше бары тик Аллаһы Тәгалә өчен генә гамәл кылса, аның гамәле кабул булыр, һәркайчан Аллаһыдан башкага гамәл кылса, ул кеше өчен үзенең гамәленнән өлеш булмас, мәгәр буш эш мәшәкать кенә булыр»**, – дип килде.

Факыйһ үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять итеп әйтте. Дөреслектә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Байтак ураза тотучыларның уразасыннан өлеш булмас, мәгәр сусызлык һәм ачлык кына булыр. Кичләрен аягүрә үткәрүче байтак кешеләргә өлеш булмас, мәгәр йокысызлык һәм мәшәкать кенә булыр. Ураза һәм намаз Аллаһы Тәгалә өчен генә булмаса, савап юктыр».

Хакимнәрнең кайберсеннән риваять ителде. Хакыйкатьтә, ул кайбер хакимнәр болай диделәр: «Рия өчен тәгать кылучының һәм башкаларга ишеттерү өчен гамәл кылучының охшашы шундый кеше кебектер, ул базарга чыкканда үзенең янчыгын вак ташлар белән тутырды. Кешеләр: «Боларның янчыгы ни гаҗәеп тулы», – дип әйтерләр. Кешеләрнең мондый сүзеннән болай итеп чыккан кешегә бернинди файда юк. Әгәр үзе өчен бер нәрсәне сатып алырга теләсә, ул вак таш бәрабәренә һичнәрсә бирелмәс. Шулай ук берәү рия һәм кешеләргә ишеттерү өчен гамәл кылса, ул кешегә үзенең гамәленнән һәм кешеләрнең сүзеннән башка файда да, савап та булмас.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

وَقَدِمْنَا إِلَىٰ مَا عَمِلُوا مِنْ عَمَلٍ فَجَعَلْنَاهُ هَبَاءً مَّنثُورًا ﴿٢٣﴾

**«Без алар гамәл кылган нәрсәгә килдек һәм ул гамәлне тетелгән тузан итеп кылдык, ягъни алар Аллаһы Тәгаләдән башкага гамәл кылдылар. Без ул гамәлләрне юкка чыгардык һәм аларның савабын тетелгән тузан кебек итеп кылдык».**

«Фуркан / Аеручы», 25:23

Ул «һәбә мәнсүр» шундый тузандыр ки, кояш шәүләсендә күренәдер.

Мөҗәһиттән ишеткән кешедән Суфьян Сәүри Вәкайгъкә болай дип әйтә: «Бер ир кеше Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә килеп: «Әй Аллаһының Илчесе, дөреслектә мин садака бирәм һәм шул садака белән Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын гына телимен, янә «хәер», дип әйтүне сөямен», – дип әйтте. Моннан соң бу аять инде: «Берәү Раббысына юлыгуны теләсә, ягъни Аллаһы Тәгалә каршында булган урыныннан курыкса, Аллаһы Тәгаләнең савабын теләсә, изге гамәл кылсын, ягъни чын гамәлне максат итеп Аллаһыга гыйбадәте белән һич берәүне ширек кылмасын». Янә хакимнәрдән булган бер кеше болай дип әйтте: «Бер кеше җиде әйберне җиде нәрсәдән башка эшләсә, гамәл кылган нәрсәсе белән файдаланмас. Ул җиденең беренчесе – курку белән сакланудан башка гамәл кылу, ягъни, хакыйкатьтә, мин Аллаһы Тәгалә газабыннан куркам, дип әйтер, әмма гөнаһлардан сакланмаса, бу сүз аңа файда бирмәс. Икенчесе, теләктән башка өмет белән гамәл кылу, ягъни, хакыйкатьтә мин Аллаһы Тәгаләнең савабын өмет итәм, дип әйтер, әмма савапны теләмәсә, изге гамәлләр кылуы белән аның сүзе һичнәрсәгә файда бирмәс. Өченчесе, ниятләгән гамәлләрен билгеле бер максаттан башка үтәү, ягъни изге гамәлләр, гыйбадәт кылырга ниятләр, әмма күңеле белән максат куймас, бу очракта аның нияте аңа һич тә файда бирмәс. Дүртенчесе, иҗтиһаттан башка дога белән, ягъни Аллаһы Тәгаләгә аны изгелеккә ирештерсен, дип дога кыла,

әмма үзе тырышмый, аңа догасы һич нәрсәдә файда бирмәс. Аллаһы Тәгалә аны ирештерсен өчен аңа тырышу тиешле була. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

وَالَّذِينَ جَاهَدُوا فِينَا لَنَهْدِيَنَّهُمْ سُبُلَنَا ۚ وَإِنَّ اللَّهَ لَمَعَ الْمُحْسِنِينَ ﴿٦٩﴾

**«Шундый тырышкан бәндәләрне, әлбәттә, юлларыбызга күндерербез. Хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгалә яхшы эш кылучылар беләндер, ягъни Безнең тәгатебездә тырышкан кешеләрне әлбәттә моңа ирештерербез».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:69

Бишенчесе, үкенүдән башка Аллаһы Тәгаләдән гөнаһны гафу итүне теләү, ягъни, Аллаһы Тәгаләдән гөнаһымны кичерүне телим, дип әйтер, әмма кылган гөнаһысы өчен үкенмәс, аларга үкенүдән башка булган ярлыкауны теләү файда бирмәс. Алтынчысы, эчке халәтне төзәтми торып, тышкы халәтне төзәтү, ягъни тышкы тарафтан эшләрен төзәтә, әмма эчке тарафын төзәтми. Аның тышкы тарафтан кылуы аңа файда бирмәс. Җиденчесе, ихластан башка тырышып гамәл кылу, ягъни тәгатьләрендә тырышыр, ләкин гамәлләре Аллаһы Тәгалә өчен булмас. Аның ихластан башка булган гамәлләре аңа файда бирмәс, бу аның гафиллектә калуы булыр.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итте. Хакыйкатьтә, Пәйгамбәребез болай дигән: «Заман ахырында дөньяны сөрү өчен болыт кебек кавемнәр чыгар». Икенче нөсхәдә «җыярлар», диелә, ягъни дин белән дөньяны ашарлар. Янә икенче нөсхәдә «дөньяны алырлар», диелә, ягъни ул дөньяны алырлар, киемнәре куй тиреләреннән булыр. Йомшаклыкта аларның телләре шикәрдән татлырак, күңелләре бүре күңеле кебектер. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әллә Мине алдыйсызмы яисә Миңа каршы барырга батырлык

кыласызмы? Мин Үзем белән ант иттем, әлбәттә шундый фетнә бирермен, ул фетнә акыллы хакимне хәйран калдырыр».

Вөкайгъ Суфьяннан, ул Хәбибтән, ә Хәбиб Әбү Салихтан риваять итә. Әбү Салих болай дип әйткән: «Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бер кеше килде һәм болай диде: «Әй Аллаһының Илчесе, хакыйкатьтә мин кылган гамәлемне яшерәмен. Ул эшемне кешеләр белсәләр, мин үз-үземә гаҗәпләнәм. Мондый гамәлдә минем өчен савап булырмы?» Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Синең өчен ул гамәлдә ике әҗер бар: яшерен һәм тыштан булган әҗерләрдер».

Факыйһ радыяллаһу ганһе мондый сүзләр әйткән: «Аның мәгънәсе шундый: кеше шул гамәлне аңларга һәм аңа иярергә тиеш һәм бу очракта аның өчен ике әҗер булыр: гамәл өчен бер әҗер, шул гамәлгә ияргәне өчен икенче әҗердер». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Бер кеше күркәм сөннәтне тергезсә, аның өчен шул сөннәтнең әҗере һәм аңа ияреп, Кыямәт көненә чаклы шул сөннәтне кылучыларның әҗере булыр. Берәү явыз сөннәтне тергезсә, ул сөннәтнең гөнаһысы аның үзенә булыр һәм аңа ияреп ул сөннәтне кылучының гөнаһысы Кыямәт көненә кадәр дәвам итәр.

Габдулла бине Мөбарәк Әбү Бәкердән, ул Зәмраттан, ә ул Әбү Хәбибтән риваять итә. Әбү Хәбиб түбәндәге сүзләрне әйткән: «Аллаһы Тәгаләнең Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Хакыйкатьтә, фәрештәләр Аллаһы Тәгаләнең колларыннан булучы колның гамәлен күтәрерләр, хәтта солтаныннан алып Аллаһы Тәгалә теләгән урынга илтеп җиткергәнчегә кадәр ул гамәлне күпкә санарлар, аны пакьләрләр. Аллаһы Тәгалә ул фәрештәләргә вәхи кылыр: «Хакыйкатьтә, сез Минем колымның гамәлен саклаучылар һәм Мин ул колның күңелендә булган нәрсәне күзәтүчемен. Хакыйкатьтә, бу колым үзенең гамәлен ихластан Минем өчен кылмаган. Сез аны җиде кат җир өстендә ташка языгыз». Янә ул фәрештәләр колның гамәлен

ашырырлар. Ул гамәлне солтанынннан алып Аллаһы Тәгалә теләгән урынга җиткергәнгә кадәр аны аз һәм кечкенә дип санарлар. Аллаһы Тәгалә аларга вәхи кылыр: «Хакыйкатьтә, сез колымның гамәлен саклаучылар, Мин ул колның нәфесендә булган нәрсәне күзәтүчемен. Хакыйкатьтә бу колым Минем өчен хас һәм саф булды, аның гамәлен югары күкләргә языгыз». Дөреслектә, һәркайчан аз гамәл Аллаһы Тәгалә өчен генә булса, ул Аллаһы Тәгаләдән башка өчен булган күп гамәлдән изгерәктер. Чөнки аз гамәл һәркайчан Аллаһы өчен генә булса, хакыйкатьтә Аллаһы Тәгалә Үзенең фазыйләте белән ул аз гамәлне ике өлеш кылыр. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

وَإِن تَكُ حَسَنَةً يُضَاعِفْهَا وَيُؤْتِ مِن لَّدُنْهُ أَجْرًا عَظِيمًا ﴿٤٠﴾

**«Әгәр ул гамәлләр күркәм булса, Аллаһы Тәгалә ул гамәлләрне ике өлеш кылыр һәм Үзеннән олуг әҗерне бирер. Әмма күп гамәл һәркайчан Аллаһы Тәгалә өчен генә булмаса, аңа савап юк һәм ул кешенең барачак җире җәһәннәмдер».**

«Нисә / Хатыннар», 4:40

Факыйһ болай дип әйтте: «Факыйһлар җәмәгате Гокбә бине Мөслимнән, ә ул Сәмир Әл-Әсбәхыйдән мондый сүзләр китерә: «Хакыйкатьтә ул Сәмир Мәдинәгә керде. Шул вакытта ул бер иргә очрады аның хозурына кешеләр җыелган иде. Сәмир: «Бу кем?» – дип сорады. Кешеләр: «Әбү Һөрайра», – диделәр. Сәмир Әбү Һөрайрага якынлашты, ул кешеләргә нидер сөйли иде. Ул сөйләп бетереп ялгыз калганнан соң, Сәмир аңа болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгалә сиңа сәнгатьле сөйләү сәләтен биргән, син миңа Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишеткәнеңне һәм Расүлуллаһ сиңа сөйләгәннән ятлаганыңны һәм белгәнеңне сөйлә». Әбү Һөрайра: «Утыр, әлбәттә, сиңа шундый хәдисне сөйләрмен. Дөреслектә аны миңа Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөйләде», – дип әйтте. Безнең янда башка һич берәү булмады. Моннан соң Әбү Һөрайра

кычкырып җибәрде һәм һушы китеп егылды. Күпмедер вакыттан соң һушына килеп, йөзен сыйпады һәм: «Әлбәттә, Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа сөйләгән сүзне сезгә сөйләрмен», – диде. Моннан соң янә икенче тапкыр кычкырды. Озак вакыт туктап торды, моннан соң айнып йөзен сыпырды һәм болай дип әйтте: «Миңа Аллаһы Тәгаләнең Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөйләде: «Хакыйкатьтә Кыямәт көнендә, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә мәхлүкълар арасында хөкем кылыр. Һәр өммәт тез чүгеп торыр. Чакырылган кешеләрнең иң беренчесе Коръәнне җыючы, янә Аллаһы Тәгалә юлында үтерелүче һәм малы күп булучыдыр. Аллаһы Тәгалә Коръән укучыга әйтер: «Йә синә пәйгамбәрләремә индергән нәрсәне өйрәтмәдеммe?» Коръән укучы: «Дөреслектә өйрәттең», – дияр. Аллаһы Тәгалә: «Белгән нәрсә белән нинди гамәл кылдың?» – дип сорар. Коръән укучы: «Төн һәм көндез урталарында ул гамәлемне торгыза торган булдым», – дип җавап бирер. Аллаһы Тәгалә аңа: «Ялганладың», – дип әйтер. Фәрештәләр: «Син ялганладың, бәлки син фәлән кеше Коръән укучы, дип әйтүләрен теләдең һәм тәхкыйк бу әйтелде», – диярләр. Шуннан соң мал иясеннән: «Сиңа бирелгән нәрсә белән ни эшләдең?» – дип соралыр. Мал иясе: «Ул мал белән карынымны пакьләдем, янә ул малны садака итеп бирдем», – дип әйтер. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Ялганладың». Фәрештәләр дә: «Ялганладың, бәлки син фәлән кеше юмарт, дип әйтүләрен теләдең. Тәхкыйк бу әйтелде, ягъни теләгең хасил булды», – диярләр. Янә Аллаһы Тәгалә юлында үтерелгән кешене китерерләр. Аллаһы Тәгалә аннан: «Ни өчен үтерелдең?» – дип сорар. Ул кеше: «Үлемемә кадәр Синең юлыңда сугыштым», – дип җавап бирер. Аллаһы Тәгалә аңа: «Ялганладың», – дип әйтер. Фәрештәләр дә: «Ялганладың, бәлки син фәлән адәм батыр икән, дип әйтүләрен теләдең, тәхкыйк бу әйтелде», – диярләр. Моннан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм кулы белән минем тезләремә сугып әйтте: «Әй Әбү Һөрайра, бу зикер ителгән өч төркем Аллаһы Тәгаләнең беренче халык-

ларыдыр, Кыямәт көнендә алар белән җәһәннәм уты кыздырылыр». Әбү Һөрайра болай дип әйтте: «Бу хәбәр Мөгавия радыяллаһу ганһегә иреште, ул боларны ишеткәч бик каты елады һәм, Аллаһы Тәгалә һәм Аның Расүле дөрес әйттеләр, диде».

Моннан соң бу аятьне укыды:

مَن كَانَ يُرِيدُ الْحَيَاةَ الدُّنْيَا وَزِينَتَهَا نُوَفِّ إِلَيْهِمْ أَعْمَالَهُمْ فِيهَا وَهُمْ فِيهَا لَا يُبْخَسُونَ ﴿١٥﴾ أُولَٰئِكَ الَّذِينَ لَيْسَ لَهُمْ فِي الْآخِرَةِ إِلَّا النَّارُ ۖ وَحَبِطَ مَا صَنَعُوا فِيهَا وَبَاطِلٌ مَّا كَانُوا يَعْمَلُونَ ﴿١٦﴾

**«Берәү дөнья тереклеген генә вә дөнья тормышының матурлыгын теләсә, Без аларга дөньяви эшләренең файдасын дөньяда биреп бетерербез һәм аларга дөньяви эшләренә кимчелек китерелмәс. Әмма Ахирәттә аларга уттан башка җәза булмас вә дөнья эшләре һәлак булыр, вә бидгать гамәлләре батыл булыр».**

«Һуд», 11:15-16

Габдулла бине Хәниф Әл-Әнтакый мондый сүзләр әйтте: «Кыямәт көнендә кол гамәленең савабын сораса, Аллаһы Тәгалә Үзенең колына болай дип әйтер: «Йә, савабыңны сиңа ашыктырмадыкмы? Йә, синең өчен мәҗлесләрне киң кылмадыкмы? Йә, синең өчен дөньяда кешеләрдән узу дигән нәрсә булмадымы? Йә, сатуга һәм алуга файда бирелмәдеме? Йә, моның охшашлысы һәм моңарга охшашлылар булмадымы?»

Кайбер хакимнәрдән: «Ихлас белән гамәл кылучы кеше кем?» – дип соралды. Ул хәким болай диде: «Начарлыкларын яшергән кебек үк изгелекләрен яшерүче». Янә хакимнәрнең кайберсеннән: «Ихласның чиге кайда?» – дип соралды. Ул болай дип әйтте: «Кешеләрнең мактаганын сөймәү». Зүннүн Әл-Басридан: «Кеше кайчан үзен Аллаһы Тәгаләнең якыннарыннан, ягъни Аллаһы Тәгалә сайлап алган кешеләрдән икәнен белә?» – дип соралды. Ул болай дип җавап бирде: «Моны дүрт төрле нәрсә

белән белер: рәхәтлекне калдырса, һәркайчан юмарт булса, ягъни үзендә аз булган нәрсәне дә бирсә, түбән дәрәҗәгә төшүне сөйсә, аның өчен мактау һәм яманлау бәрабәр булса».

Гади бине Хәтим Әт-Таи Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен риваять итә: «Хакыйкатьтә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтте: «Кыямәт көнендә бер төркем халыкка оҗмахка керергә боерылыр. Алар оҗмахка якын килгәнчегә кадәр барырлар, җәннәтнең исендә иснәрләр, ул җәннәтнең сарайларына һәм Аллаһы Тәгаләнең оҗмах әһеленә әзерләнгән нәрсәләренә дә карарлар. Шул вакытта, аларны кире кайтарырга, дигән тавыш булыр. Кыямәт көнендә алар өчен оҗмахтан өлеш булмас, алар хәсрәт һәм үкенеч белән кайтырлар. Бу төркем кебек әүвәлге һәм ахыргы төркемнәр кайтмас. Алар: «Әй безнең Раббыбыз, безгә боларны күрсәтүдән әүвәл утка керткән булсаң иде. Син аны әүвәл Үзеңнең әулияларың өчен хәзерләдең», – дип әйтерләр. Аллаһы Тәгалә болай дип җавап бирер: «Сезгә дә шуны теләдем, сез һәркайчан ялгыз калсагыз, олуг әйберләр белән Миңа каршы чыктыгыз. Кешеләргә юлыксагыз, Миңа баш игән хәлдә, ягъни тыйнаклык илә үзегезнең гамәлләрегез белән юлыктыгыз. Кешеләргә рия кылдыгыз, көнегездә теләгән нәрсәләрегезнең хилафына кешеләрдән курыктыгыз, Миннән курыкмадыгыз. Кешеләрне олугладыгыз, Мине олугламадыгыз, кешеләргә калдырдыгыз, Миңа калдырмадыгыз. Бу көндә сезгә газапның катысын татытырмын».

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен риваять итә: «Аллаһы Тәгалә Гаден оҗмахын яратты һәм шунда күз күрмәгән, колак ишетмәгән, кешеләрнең күңелләреннән кичмәгән нәрсәләрне бар кылды. Аннан соң Аллаһы Тәгалә әлеге Гаден оҗмахына сөйләргә әмер бирде. Ул оҗмах болай дип сөйләде: «Тәхкыйк, иман китергән кешеләр өч мәртәбә өстенлек

таптылар. Хакыйкатьтә мин саран, икейөзле һәм рия кылучы кешеләргә харам булырмын».

Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе мондый сүзләр әйтте: «Хакыйкатьтә рия кылучының дүрт галәмәте бар: ялгыз булса, һәркайчан ялкауланыр. Кешеләр арасында булса, тырышыр. Һәркайчан ул кеше макталса, гамәлен арттырыр. Әгәр хурласалар, гамәлен кылмас».

Шәкыйкъ бине Ибраһим радыяллаһу ганһедән мондый сүзләр риваять ителә: «Гамәлнең нигезе өч төрле нәрсәдер: беренчесе, гамәлне Аллаһы Тәгаләдән дип белү һәм кылган гамәлең аркасында үз-үзеңә сокланудан ерак тору; икенчесе, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын теләү һәм нәфес теләкләреннән котылу; өченчесе, гамәлнең савабын Аллаһы Тәгаләдән өмет итү һәм кылган изге гамәл өчен кешедән нидер көтүдән һәм риядан арыну. Болар белән гамәлләр ихлас булыр. Шәкыйкънең «Дөреслектә гамәлне Аллаһы Тәгаләдән дип күрү» дигән сүзенең мәгънәсе шул: дөреслектә ул кеше үзен бу гамәлгә муафыйк кылучы затны Аллаһы Тәгалә дип белер, чөнки ул кеше үзенең гамәлен Аллаһы Тәгалә рәхмәте илә кылынганын белсә, хакыйкатьтә ул гамәле өчен шөкер итү белән генә мәшгуль булыр, үз-үзенә сокланып гаҗәпләнмәс. Шәкыйкънең «Кылынган гамәл өчен Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын теләү» дигән сүзенең мәгънәсе шулдыр: әгәр кешенең нияте кылган гамәле өчен Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алу булса, хакыйкатьтә ул аны эшләр. Әмма әлеге гамәлне Аллаһы ризалыгы хакына эшләргә теләге булмаса, нәфес өчен генә булудан куркып, бу гамәлен кылмас, чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

وَمَا أُبَرِّئُ نَفْسِيٓ ۚ إِنَّ ٱلنَّفْسَ لَأَمَّارَةٌۢ بِٱلسُّوٓءِ إِلَّا مَا رَحِمَ رَبِّيٓ ۚ ﴿٥٣﴾

**«Дөреслектә, нәфес бозыклыкка боеручы, мәгәр нәфес өндәгән явыз эшләрдән Раббым рәхмәт кылган кешеләр генә котылыр...»**

«Йосыф», 12:53

Шәкыйкънең «Гамәлнең савабын Аллаһы Тәгаләдән теләү», дигән сүзләренең мәгънәсе болай: кеше ихластан Аллаһы Тәгалә өчен генә гамәл кылыр һәм кешеләрнең сүзеннән курыкмас. Кайбер хакимнәрдән мондый сүзләр риваять ителде: «Гамәл кылучыга куй көтүчесеннән әдәпкә өйрәнү тиештер». «Бу ни рәвешле була?» – дип сорадылар. Хакимнәр әйттеләр: «Чөнки көтүче куйлар янында намазын укыса, хакыйкатьтә ул көтүче укылган намазы өчен куйларның мактавын теләми. Гамәл кылучыга да шулай ук гамәл кылу тиешледер. Ул кешеләр каравыннан курыкмас, бәлки халык каршында да, аулакта булганда да гамәлен Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен кылыр, кешеләрнең мактавын теләмәс». Кайбер хакимнәр болай дип әйтте: «Гамәл тапшырылганга кадәр дүрт әйбергә мохтаҗ булыр. Беренчесе, ул гамәлдән әүвәл гыйлем алу, чөнки гамәл гыйлем белән генә булыр. Гамәлнең гыйлемнән башка булуы гамәлне боза торган нәрсә булыр. Икенчесе, гамәл алдыннан ният кылу. Ул гамәл ният белән генә төзәлер».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Гамәлләр ниятләр белән генәдер. Һәр кешегә ният кылганы насыйп булыр». Ураза, намаз, хаҗ, зәкят һәм башка тәгатьләр тормышка ашмас, мәгәр ният ашыр. Ният – гамәлнең тормышка ашуында төп шарт булып тора. Өченчесе, гамәл уртасында сабыр итү. Ягъни ул тәгатьне үтәгәнгә кадәр тәгатендә сабыр итәр. Дүртенчесе, ул гамәлдә ихлас булу, чөнки гамәл ихластан башка кабул кылынмас. Кеше ихлас белән гамәл кылса, аны Аллаһы Тәгалә кабул кылыр.

Сәһил бине Салихтән, ул атасыннан, ә ул Әбү Һөрайрадан, ул Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә Аллаһы Тәгалә берәр колны сөйсә, Җәбраил фәрештәгә әйтер: «Мин фәлән кешене сөямен, син дә аны сөй». Җәбраил галәйһиссәлам дә әлеге колны ярата башлар һәм күк әһелләренә: «Дөреслектә сезнең Раббыгыз фәлән

кешене сөя, сез дә аны сөегез», – дип әйтер. Ул колны күк әһелләре» дә сөяр. Моннан соң бу кешегә карата җирдә дә яхшы мөнәсәбәт күрсәтелә башлар. Аллаһы Тәгалә бер колга ачуланса да моңа охшашлы булыр».

Шәкыйкъ бине Ибраһимнан риваять ителә. Бер кеше аннан болай дип сорады: «Дөреслектә кешеләр мине изге дип әйтәләр. Мин үземнең изге яисә изге түгел икәнлегемне ничек белермен?» Шәкыйкъ аңа әлеге сүзләр белән җавап бирде: «Салихлар (изгеләр) янында сереңне ач, әгәр ул эшеңә разый булсалар, син изгеләрдән булырсың, әмма разый булмасалар, үзеңне изге димә. Икенчесе – дөньяны күңелеңә сал. Әгәр аны күңелең кире кайтарса, үзеңне салих дип бел. Өченчесе – нәфесеңә үлемне сал, ягъни исеңә төшер, әгәр нәфесең үлемне теләсә, үзеңне салих дип бел, әмма теләмәсә, изге дип белмә. Бу өч нәрсә синдә җыелса, гамәлеңә рия кермәсен өчен Аллаһы Тәгаләгә ялвар. Әгәр рия керсә, гамәлләрең бозылыр».

Сәбит Әл-Бәнәни Әнәстән, ә ул Расүлуллаһ галәйһиссәламнән әлеге сүзләрне риваять итә: «Мөэминнең кем икәнен беләсезме?» Аңа: «Аллаһы Тәгалә һәм аның Илчесе белүчедер», – дип җавап бирделәр. Пәйгамбәребез болай диде: «Ул шундый кешедер, Аллаһы Тәгалә аның ишетә торган әгъзаларын Үзе сөя торган нәрсә белән тутырганчыга кадәр ул кеше үлмәс. Әгәр берәү бер өй эчендә җитмеш өйгә кадәр һәр өй хозурында тимер ишек ясап, ягъни шул кадәр бикләнеп Аллаһы Тәгаләнең тәгате өчен гамәл кылса, хәтта кешеләр моны сөйләгәнче үк Аллаһы Тәгалә аңа гамәленең күлмәген кидерер һәм аны арттырыр». Пәйгамбәребездән: «Әй Расүлүллаһ, нәрсә арттырыр?» – дип сорадылар. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә мөэмин гамәле артуны сөядер», – диде. Аннан соң янә әйтте: «Йә, фәҗирнең кем икәнен беләсезме?» «Аллаһы һәм Аның Расүле белүчерәктер», – дип җавап бирделәр. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Ул шундый кешедер, Аллаһы Тәгалә аның ишетә торган урынын Үзе мәкруһ күргән нәрсәләрен тутырганчыга

кадәр ул кеше үлмәс. Берәү өйдә җитмеш йортка кадәр йорт эчендә Аллаһы Тәгалә тыйган эшне һәр йортта тимер ишек белән бикләнеп кылса, Аллаһы Тәгалә гамәленең күлмәген кидерер, хәтта кешеләр моны сөйләрләр һәм арттырырлар». Аннан: «Әй Аллаһының Расүле, ничек арттырырлар?» – дип сорадылар. Ул: «Дөреслектә фәҗир бозыклыгында арттырганны ярата».

Гауф бине Габдулладан риваять ителә. Дөреслектә ул болай дип әйтте: «Изге кешеләрнең кайберләре икенчеләренә өч төрле сүз яздылар. Бер кеше Ахирәт өчен гамәл кылса, ул бәндәнең дөнья эшен Аллаһы Тәгалә җитештерер. Бер кеше үзе белән Аллаһы Тәгалә арасын төзәтсә, Аллаһы Тәгалә ул кеше белән кешеләр арасын төзәтер. Бер кеше үзенең эчке тарафын төзәтсә, Аллаһы Тәгалә тышкы халәтен төзәтер».

Факыйһ радыяллаһу ганһе: «Миңа ышанычлы кеше үзенең иснәде белән Җәблә Яхсәби дигән кешедән хәбәр бирде», – диде. Ул кеше болай дип әйткән: «Без Габделмәлик бине Мәрван белән сугышта булдык. Безгә йокысыз кеше иптәш булды. Ул кичләрен бик аз йоклый. Без күп көннәр бергә тордык, аны белмәдек, моннан соң таныдык. Бу кеше Аллаһы Тәгалә Илчесенең сәхабәләреннән икән. Ул безгә берәүнең Расүлебезгә биргән соравы һәм аның җавабы турында сөйләде. Берәү Аллаһының Илчесеннән: «Әй Аллаһының Расүле, киләчәктә котылу нәрсәдә?» – дип сораган. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһыны алдамауда», – дип җавап биргән. Бу кеше: «Без ничек Аллаһыны алдыйбыз?» – дигән. Расүлуллаһ галәйһиссәлам түбәндәге сүзләрне әйткән: «Үзегезнең гамәлегез һәм теләгегез белән. Гамәлләрегезне риядан саклагыз, чөнки рия ул Аллаһыга ширек китерү. Хакыйкатьтә Кыямәт көнендә рия кылучыларны дүрт төрле исем белән чакырырлар: «Әй кяфер, әй бозык, әй ялганчы, әй өметсез, син гамәлеңнең юлыннан адаштың, әҗерең юкка чыкты, бу көндә сиңа өлеш юк. Әй алдакчы, кемгә гамәл кылган булсаң, шуннан әҗереңне сора», – дип кычкырылыр. Җәблә әйтте: «Ул кешегә

әйттем, Аллаһы белән ант итеп әйтәмен, Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк. Син бу хәбәрне Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ишеттең». Ул кеше болай дип җавап бирде: «Аннан башка гыйбадәт кылуга лаек булмаган Зат – Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, дөреслектә мин ул хәбәрне Расүлуллаһтан ишеттем мәгәр берәр әйберне ниятләп хата кылсам гына, ялганлап әйтмәдем». Моннан соң әлеге аятьне укыды:

إِنَّ الْمُنَافِقِينَ يُخَادِعُونَ اللَّهَ وَهُوَ خَادِعُهُمْ وَإِذَا قَامُوا إِلَى الصَّلَاةِ قَامُوا كُسَالَىٰ يُرَاءُونَ النَّاسَ وَلَا يَذْكُرُونَ اللَّهَ إِلَّا قَلِيلًا ﴿١٤٢﴾

> **«Әлбәттә, монафикълар Аллаһыны алдыйбыз дип уйлыйлар, Аллаһы исә аларны дөньяда һидаятьтән, Ахирәттә җәннәттән мәхрүм итеп алдаучыдыр».**

«Нисә / Хатыннар», 4:142

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Берәү Ахирәттә гамәлен риядан башка табарга теләсә, ул гамәлен Аллаһы Тәгалә өчен ихластан кылырга тиешле була. Моннан соң гамәле юкка чыгармасын өчен, ул изге гамәлне онытырга тиеш, чөнки гыйбадәтне саклау аны башкаруга караганда авыррак».

Әбү Бәкер Әл-Вәсәтый мондый сүзләр әйткән: «Тәгатьне саклау ул тәгатьне кылудан авыррак, чөнки ул тәгать пыяла кебектер. Тиз ватылырга мөмкин һәм аны кире төзәтеп булмас. Әгәр гамәл рия өчен кылынса, пыяла ватылган кебек үк, гамәл дә юкка чыгар. Әгәр кеше берәр гамәлне кылганнан соң үз-үзенә сокланса, шулай ук гамәле юкка чыгар. Әгәр берәү гамәлен рия өчен эшләсә, аңа тәүбә итү кирәктер. Шаять Аллаһы Тәгалә аның икенче гамәленең ихластан кылынуын муафыйк итәр».

Мисалда әйтелә: дөреслектә рия кылучылар үлгәннән бирле дөнья харап булды. Чөнки ул рия кылучылар мосафирханәләр, күперләр һәм мәчетләр кебек, кешеләр өчен файдалы эшләрдә изгеләр гамәлен эшли

торган булдылар. Әмма алар рия өчен булса да, бу гамәлне кылучыга байтак вакыт файда бирер. Әүвәлгеләрдән кайберләре риваять иткәнчә, мөселманнарның берсенең догасы хакыйкатьтә ул мосафирханәне кылды һәм үз-үзенә әйтә торган булды: «Белмим, бу гамәлем Аллаһы Тәгалә өчен булдымы яисә булмадымы?» Килүче йоклаганда килеп әйтте: «Әмма бу гамәлең Аллаһы Тәгалә өчен булмаса да, мөселманнар синең өчен дога кылалар, ул гамәлең Аллаһы Тәгалә өчендер». Бу сәбәптән шатланды.

Хозәйфә бине Йәмән радыяллаһу ганһе янында бер кеше килеп болай дип әйтте: «Әй Аллаһы, монафикъларны һәлак кыл». Хозәйфә радыяллаһу ганһе мондый сүзләр әйтте: «Әгәр алар һәлак булсалар, дошманыгыздан котылмас идегез, ягъни хакыйкатьтә ул монафикълар сугышка чыгарлар, дошман белән сугышырлар».

Сәлман Фарси радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Ул болай дип әйткән: «Мөэминнәрне монафикълар куәте белән Аллаһы Тәгалә көчле кыла, мөэминнәр догасы белән монафикъларга җиңү бирә».

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Фарызларны кешеләргә сөйлә. Кайберәүләр әйттеләр: «Фарызларга рия кермәс, чөнки ул гамәлләр барча халыкка фарыздыр. Аңа фарыз булган нәрсәне үтәсә, ул фарызга рия кермәс». Кайберләре: «Фарызларга да, фарызлардан башкага да рия керер», – диделәр.

Факыйһ радыяллаһу ганһе мондый сүзләр дә әйткән: әгәр берәү фарызларны кешеләр күргәндә һәм кешеләр күрмәгәндә рия белән үтәсә, әлбәттә ул фарызны үтәмәгән булыр. Мондый кеше тәмам монафикътыр, ул Аллаһы Тәгалә әйткән кешеләр җөмләсеннәндер:

إِنَّ الْمُنَافِقِينَ فِي الدَّرْكِ الْأَسْفَلِ مِنَ النَّارِ وَلَن تَجِدَ لَهُمْ نَصِيرًا ﴿١٤٥﴾

**«Дөреслектә, монафикъларның кайтачак урыннары шиксез җәһәннәмнең иң түбән катлавындадыр».**

«Нисә / Хатыннар», 4:145

Чөнки ул монафикъның Аллаһыны берләве дөрес һәм ихлас булса, рия ул кешене фарызларны үтәүдән тыймас иде. Әгәр ул кеше фарызларны үтәсә, аларны халык янында күркәмрәк, тәмамрак итеп үтидер. Әмма аны беркем күрмәсә, ул фарызларны ким итеп үти, аңа моның өчен савап булмас. Ул кеше бу фарызлардан соралыр, алар хозурына хисап кылыныр.

*«Тәнбиһүл-гафилин» китабыннан*

# Олы гөнаһлар

## Ятимнәр малын ашау

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الَّذِينَ يَأْكُلُونَ أَمْوَالَ الْيَتَامَىٰ ظُلْمًا إِنَّمَا يَأْكُلُونَ فِي بُطُونِهِمْ نَارًا ۖ وَسَيَصْلَوْنَ سَعِيرًا ﴿١٠﴾

**«Ятимнәрнең малларын золым белән (хаксызга) ашаган кешеләр карыннарын ут белән тутырачаклар һәм тиздән (мисалы булмаган бик куркыныч) ялкынга керәчәкләр».**

«Нисә / Хатыннар», 4:10

وَلَا تَقْرَبُوا مَالَ الْيَتِيمِ إِلَّا بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ حَتَّىٰ يَبْلُغَ أَشُدَّهُ ۖ وَأَوْفُوا الْكَيْلَ وَالْمِيزَانَ بِالْقِسْطِ ۖ لَا نُكَلِّفُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا ۖ وَإِذَا قُلْتُمْ فَاعْدِلُوا وَلَوْ كَانَ ذَا قُرْبَىٰ ۖ وَبِعَهْدِ اللَّهِ أَوْفُوا ۚ ذَٰلِكُمْ وَصَّاكُم بِهِ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ﴿١٥٢﴾

**«Балигъ яшенә җиткәнче, иң яхшы куллану (булган саклау һәм файда казандыру юллары) белән генә булмаса, ятим малына якын килмәгез; үлчәүне вә авырлыкны билгеләүне гаделлек белән (төп-төгәл) башкарыгыз. (Үлчәүдә һәм чамалауда арттырмыйча яки киметмичә, төгәл гаделлек итү бик авыр булса да,) Без һичкемгә көченнән килмәгәнне йөкләмибез. (Шул сәбәпле, сез, кулыгыздан килгәнчә, таләпчәнлек күрсәтсәгез, белми торып җибәрелгән ялгышларыгызны кичерербез.) Сез (кешеләр хакында биреләсе хөкемнәр белән бәйле теләсә нинди мәсьәләдә) сүз әйткән чакта, (сүз әйтелгән кеше нәселлек ягыннан) якыныгыз (булып чыгарылачак хөкем аңа каршы)**

**булса да, гадел булыгыз, (гадел булырга, әмер һәм тыюларын үтәү мәсьәләсендә) Аллаһыга биргән вәгъдәгезне тотыгыз. Ул (Аллаһы Тәгалә) боларны (үтәүне) сезгә әмер итте, – бәлки, (бу хөкемнәр турында яхшылап бер) уйларсыз (һәм кирәк булганча гамәл кылырсыз)».**

«Әнгәм / Терлек», 6:152

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам санап киткән җиде олы гөнаһ арасында ятимнәрнең малын ашау да бар.

Тәрбиягә алган кеше шул малдан аларга рөхсәт ителгән өлешне генә кулланырга ярый, аннан артыгын куллану – харам, бу кешегә хәләл ризык, хәләл мал булмаячак. Ул (хәләл) өлешне ислам дине кануннарына һәм горефләренә таянып хисаплап чыгарып була. Ул өлешне хисаплаганда начар ниятләр булырга тиеш түгел.

## Пәйгамбәребезгә яла ягу (ялган хәдисләр уйлап табу)

Кайбер ислам галимнәре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата ялган сүзләр әйтү (Пәйгамбәребез әйтмәгән сүзләрне, анықы дип белдерү) – көферлек һәм исламнан чыгу була дип саный.

Дөреслектә, Аллаһы Тәгаләгә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә яла ягучы кеше; хәләлне харам, харамны хәләл дип әйтүче кешеләр имансыз булалар. Галимнәрнең бүтән очракларга карата булган хөкемнәре бу хөкемнәрдән аерыла.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Миңа яла ягу (ялган хәдисләр уйлап чыгару, Пәйгамбәребез турында уйдырмалар

чыгару) калган кешеләргә яла ягу белән тәңгәл түгел. Бу эшләрне аңлы рәвештә эшләүче кеше үзенә утта[1] урын әзерләсен»,[2] – дип әйткән.

Шулай ук: «Мөселманда алдалау һәм хыянәттән кала, төрле сыйфатлар (мөселман төрле холыклы) була ала[3].

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Минем исемнән ачык ялган сөйләүче кеше ике ялганчының берсе булып тора», – дип әйткән.[4]

Бу хәдисләр ялган хәдисләрне уйлап чыгаруның тыелган эш икәнен күрсәтеп торалар.

## Җитди сәбәпләрсез Рамазан аенда ураза тотмау

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аенда җитди сәбәпләрсез бер генә көн уразасын калдырган кеше, гомер буе ураза тотса да, бу уразасы кадәр әҗер ала алмаячак»[5], – дип әйткән.

Пәйгамбәребез шулай ук: «Ике намаз, ике җомга һәм ике Рамазан арасында зур гөнаһлардан ерак торган кешенең кечкенә гөнаһлары ярлыканыр», – дигән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ислам биш баганага нигезләнгән:

1. Иман китерү (шәһадәт);
2. Намаз уку
3. Зәкят түләү;
4. Рамазан аенда ураза тоту;
5. Хаҗ».

---

[1] Җәһәннәмдә (ред.).

[2] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

[4] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[5] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

Бине Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Исламның асылы һәм нигезе өч баганадан тора. Алар:

1. Аллаһы Тәгаләдән кала гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк, дип шәһадәт китерү;

2. Намаз уку;

3. Зәкят түләү.

Боларның берсеннән генә булса да баш тарткан кеше имансыз була[1].

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр дә кеше алдаудан, ялган белән эш итүдән, наданлыгыннан баш тартмый икән, Аллаһы Тәгаләгә андый кешенең су һәм ашаудан тыелып торуы (ач булуы) кирәкми»[2].

Шулай ук ул: «Рамазан аенда ураза тотып та, гөнаһлары ярлыканмыйча калган кешегә хәсрәт булсын», – дип әйткән.

Рамазан аенда җидти сәбәпләрсез ураза тотмаган кеше, чит кешенең хакына керүче йә эчкечедән дә түбәнрәк икәнен барлык мөселманнар диярлек кабул итә.

Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын.

## Зина кылу

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلَا تَقْرَبُوا الزِّنَىٰٓ ۖ إِنَّهُۥ كَانَ فَاحِشَةً وَسَآءَ سَبِيلًا ﴿٣٢﴾

**«Зинага (керү түгел, кагылу һәм үбү кебек гөнаһларга хәтта) якынлашмагыз. Һичшиксез, ул бик җирәнгеч бер эш һәм (шәһвәтне канәгатьләндерү өчен эзләнә торган) бик кабахәт бер юл».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

1 Боларны эшләргә кирәкми, дип әйтүче. Мәсәлән, намазны кире кагучы кеше (ред.).

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

وَالَّذِينَ لَا يَدْعُونَ مَعَ اللَّهِ إِلَٰهًا آخَرَ وَلَا يَقْتُلُونَ النَّفْسَ الَّتِي حَرَّمَ اللَّهُ إِلَّا
بِالْحَقِّ وَلَا يَزْنُونَ ۚ وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ يَلْقَ أَثَامًا ﴿٦٨﴾

**«Янә алар Аллаһы белән берлектә башка илаһка табынмыйлар (үтергән бер кеше өчен кыйсас, Исламга кергәннән соң диннән чыгу һәм өйләнгән килеш зина кылу кебек) хак белән булмыйча, Аллаһы тыйган җанны үтермиләр, зина да кылмыйлар. Кем дә кем боларны кылса, (гөнаһының) җәзасын алачак».**

«Фуркан / Аеручы», 25:68

الزَّانِيَةُ وَالزَّانِي فَاجْلِدُوا كُلَّ وَاحِدٍ مِّنْهُمَا مِائَةَ جَلْدَةٍ ۖ وَلَا تَأْخُذْكُم بِهِمَا
رَأْفَةٌ فِي دِينِ اللَّهِ إِن كُنتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ ۖ وَلْيَشْهَدْ عَذَابَهُمَا
طَائِفَةٌ مِّنَ الْمُؤْمِنِينَ ﴿٢﴾

**«Зина кылган хатын һәм зина кылган ир (балигъ яшенә җиткән, акыллы, мөселман һәм кол булмаган кешеләр икән, бигрәк тә бер тапкыр да кияүдә булмаган яки өйләнмәгән булсалар) – һәрберсенә йөзәр тапкыр (камчы белән) суктырыгыз. (Ләкин итләренә һәм сөякләренә зарар китерү максаты белән чамадан чыкмагыз, баш, йөз, корсак һәм җенси әгъзаларга сугудан да сакланыгыз.) Аллаһыга һәм Ахирәт көненә ышансагыз (беркемне дә кызганмагыз һәм сездән мәрхәмәтлерәк булган Яратучының хөкемен үтәр өчен), Аллаһының дине (гамәлгә ашырылу) мәсьәләсендә сезне кызгану (хисе) биләп алмасын. Мөэминнәрдән бер төркем ул икәүнең җәзасына шаһит булсын (шулай итеп, зина гөнаһының яманлыгы күрсәтелсен һәм бу җәза башкалар өчен гыйбрәт булсын)».**

«Нур», 24:2

الزَّانِي لَا يَنكِحُ إِلَّا زَانِيَةً أَوْ مُشْرِكَةً وَالزَّانِيَةُ لَا يَنكِحُهَا إِلَّا زَانٍ أَوْ مُشْرِكٌ ۚ وَحُرِّمَ ذَٰلِكَ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ ﴿٣﴾

**«Зина кылган ир зина кылган бер хатыннан яки ширек кушкан бер хатыннан башкага өйләнми. Зина кылган хатынны исә, аны зина кылган бер ир яки ширек кушкан бер ир генә хатынлыкка ала. Бу (зиначыларга өйләнергә яки кияүгә чыгарга) иман итүчеләргә харам кылынды»[1].**

«Нур», 24:3

Берьюлы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән олы гөнаһлар турында сорадылар. Ул: «Сине барлыкка китергән Аллаһы Тәгаләгә ширек кылу, тукландыра алмаудан куркып үз балаңны үтерү, күршеңнең хатыны белән зина кылу»[2], – дип җавап бирде.

Икенче бер хәдистә Расүлебез галәйһиссәламнең түбәндәге сүзләре риваять ителә:

«Мөэмин зина кылганда, урлаганда, хәмер эчкәндә имансыз халәттә була»[3].

Тагын бер хәдистә: «Мөэмин кеше зина кылганда иманы чыгып, өстендә шәүлә кебек тора»[4], – дип әйтелгән.

---

1 Зинаның харамлыгы хакында фикер берлеге бар, ләкин зиначылар белән өйләнешү Исламның башыннан ук харам булса да, бераз соңрак, шушы ук сүрәнең, гыйффәтле гыйффәтсезгә бүлеп карамыйча, буйдакларны һәм толларны өйләндерергә әмер иткән 32 нче аяте кәримәсе белән нәсех ителгән. Фасикъларга охшау, гаептә шикләнү, начар сүзләргә мөмкинлек ачу кебек бик күп сәбәпләр аркасында гыйффәтсез хатыннарга өйләнү мәкруһ саналса да (Нәсәфи).

2 Имам Бохари, имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Бохари, имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

4 Имам Бохари, имам Мөслим, имам Әбү Давыд, имам Тирмизи, имам Ән-Нәсаиның хәдисләр җыентыгыннан.

«Кеше көлмәгән салган кебек, Аллаһы Тәгалә зина кылучының һәм исерткеч эчүченең иманын чыгара»[1].

– «Аллаһы Тәгалә өч төркем кеше белән Кыямәт көнендә сөйләшмәс, аларга карамас һәм гөнаһларыннан чистартмас. Болар:

– зиначы карт ир кеше;

– ялганчы идарә итүче;

– тәкәббер ярлы кеше»;[2]

«Аллаһы Тәгаләнең дүрт төркем кешегә ачуы бар. Алар:

– күп вәгъдә бирүче сәүдәгәр;

– тәкәббер ярлы кеше;

– зиначы карт ир кеше;

– үзенең кул астындагыларга зыян салучы идарә итүче»[3].

Иң авыр зина булып кешенең үз әнисе, кыз туганы, әтисенең хатыны һәм аңа харам булган башка хатын-кызлар белән кылган зина санала.

*Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан*

1 Имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

2 Имам Мөслим, имам Ән-Нәсаиның хәдисләр җыентыгыннан.

3 Имам Ән-Нәсаиның хәдисләр җыентыгыннан.

# Әдәби сәхифә

# Агулы сабак

Сәгать инде төнге уникедән авышып китүгә карамастан, Раилә, тирән уйга батып, йоклый алмыйча ятты. Җәйге төннең тынлыгын бүлеп черелдәгән чикерткәләрнең тавышы элек бик романтик тоелып, аның күңелен куандырган булса, кияүгә чыгып, хәләл җефетенең йортына килен булып төшкәннән соң, табигать авазларын һәм, гомумән, тормышны ул башкачарак тоя башлады. Сөйгән яры Рәсим белән никахлашканчы, күктәге ай аның җанын өмет һәм сөенеч нурлары белән иркәләсә, гаилә корып, бергә тора башлаганнан соң, дөнья кырысланды сыман: ай яктысы да сүрәнләнеп китте, хәтта юаш чикерткәләрнең черелдәве дә йөдәтеп, теңкәгә тия торганга әйләнде.

Инде күптән үзенең бу халәте турында уйланып, Раилә үз-үзенә бер үк сорауны бирә: нишләргә? Менә хәзер дә ул тәрәзәгә озак карап ятканнан соң, өй янындагы алмагач ботаклары аша бүлмәне салкын һәм бернигә исе китмәгәндәй ваемсыз яктырткан айга мөрәҗәгать итте: ниш-ләр-гә... Ә ул – дәшми. Белмидер инде ул да, нишләргә... Каян белсен? Күңелдә – бушлык. Әнисеннән сорар иде, юк шул инде ул бу дөньяда, мәрхүмкәй. Әнисе вафат булганнан соң, әтисе яңа гаилә корып, башка авылга күченде. Хәер, монда булса да, аның белән киңәшмәс иде ул. Шәһәрдә яшәүче энесе дә бу мәсьәләдә киңәшче түгел: яшь ир-егет нәрсә дисен инде бу хакта? Шуңа да үз соравына җавап белмәгәнлектән, Раилә бимазаланып, өзгәләнеп бетте.

Яратып кияүгә чыкты ул Рәсимгә, яратып. Хәзер дә өзелеп ярата ул аны. Яратмый ни: аралаша башлауга ук уңган-булган, яхшы холыклы, шомырт күзле, нурлы йөзле чибәр егет аның йөрәген яулап алды. Хәзер дә ул яшь хатынның күңел түрендә... Ләкин бергә тора башлаганнан соң бәхетсәгадәтле тормышларында мәҗбүри юлдаш булган каенанасы бер мичкә балга дегет кашыгы булып төртелде дә куйды. Әллә бердәнбер улын «чит»

кеше белән бүлешәсе килмәгәнгә, әллә Раиләне ошатмаганга күрә, каенана яшь киленгә көн күрсәтми башлый. Төрле вак-төякне дә сәбәп итеп, гел ырлап-мыгырданып торган, «дошман-килмешәк» нәрсә генә эшләсә дә ризасызлык белдергән, «болай тормыш итәләрме соң?» дип көн дә сукранып йөргән биемнең кыланмышлары Раиләнең күңеленә тиеп, тәмам туйдырып бетерде. Рәсим өйдә булса, әле бер хәл: андый чакта ул әнисе җикеренә башлауга, шуңа ачу белән җавап кайтарырга омтылган хатынын назлы карашы белән тыеп кала, аның янәшә булуы да ничектер тынычландыра... Әмма өйдә сирәк тора шул хәләле. Шәһәрдәге заводта сменалы эштә эшләгән ире өйдә булмаганда хәлләр тагын да кискенләшә. Баштарак Раилә, чыгып качардай хәлгә җитсә дә, биеменә булган мөнәсәбәтне ачулы чырае аша гына белдертте, ләкин соңрак, нахакка әйтелгән гаепләүләргә рәнҗеп, түзә алмыйча, җавап кайтара башлады. Аннан китте инде: көн дә диярлек ызгыш, талаш, кычкырышу... Менә бүген дә тырышып табаксавытны юганнан соң, кечкенә кәстрүлдәге ашны Рәсим эштән кайтуга җылытып бирермен дип калдырган иде, каенанасы: «Ул ашны тавыкларга салып, кәстрүлен юып куясы иде», – дип кара тавыш чыгарды. Раилә дә: «Ярар, әни, хәзер чыгарып бушатырмын да, юармын кәстрүлне», – дип җавап бирәсе урынга, бөтен дөньяны куптарып тузынып, йөренгән каенанасына әллә ниләр әйтеп бетерде.

Иренә: «Башка чыгыйк, аерым яшик», – дип ничә тапкыр әйтеп караса да, Рәсим әллә олы эшкә тотынасы килмәгәнгә, әллә әнкәсен жәлләгәнгә, ризалашмады, «борчылма, җайланыр әле тормыш», дип кенә Раиләне тынычландырырга тырышты. Җайланырлыкмы соң? Кайчандыр бер китапта укылган «Әгәр тау бер урыныннан икенче урынга күчсә – ышан, әмма кешенең холкы үзгәрде дисәләр – ышанма» дигән сүзләрне исенә төшереп, ул бу проблеманың җиңел генә хәл ителмәячәген абайлады. Шуңа күрә дә «Нишләргә?» дигән сорау, үҗәт бер корт сыман, күңелендәге бәхет алмасын әкертен генә кимереп торды. Мәсьәләнең хәл

ителүен тагын сузсаң, «алманың» бөтенләй юк ителүе ихтималлыгы зур булганга, Раилә: «Алга таба болай яшәп булмый, нидер эшләргә кирәк», – дигән катгый карарга килде…

Рәсим төнге сменада эштә иде. Раилә, байтак уйлап ятканнан соң, күптән, әле үсмер чагында ук караган бер киноны исенә төшерде. Анда төп каһарман булган хатын аның үзәгенә үткән олы яшьтәге әбине агулап үтергән иде. «Әллә соң…» – дигән куркыныч уй тәэсирендә Раиләнең күңеле әүвәл тетрәнеп куя. Ләкин тора-бара бу дуамал фикер, яман гамәлнең уңай нәтиҗәсе һәм якты, бәхетле киләчәкнең ымсындыруы йогынтысында, янә үз кысасына керде. Каенанасының һәр иртә яңа сауган җылы кәҗә сөте эчәргә яратканын белгәнгә, Раилә уенда туган мәкерле планны тормышка ашыру ысулын да чамалап куйды. Шулай да, ниндидер химик матдә салып агулау бик тиз фаш ителергә мөмкин булуын белгәнгә, ул үлән-мазар кулланып максатына ирешеп булмасмы икән дигән ният белән, шәһәр базарына барырга һәм андагы аулак бер почмакта шифалы үләннәр саткан әбидән бу мәсьәләне ипләп кенә сораштырырга ниятләде.

Иртүк, төнге сменадан кайткан ирен ашатып чәй эчергәннән соң, Раилә, шәһәр базарына барып кайтам әле дип, автобус тукталышына юнәлде. Өйдән чыгып, урамнан бераз баргач, ул туктап борылды да, сөенергә дә, көенергә дә белмичә, язмыш аны урнаштырган йортка бераз карап торды. Берничә көннән биредә авылдашлары җыелып, үлгән каенанасын соңгы юлга озатканнарын күз алдына китергәннән хатынның йөрәге кысылды, күңелен курку басты. «Җүләр, нишләргә җыенасың син…» – дигән уй җанының астын-өскә китерсә дә, «башкача булмый, шул аҗдаһа аркасында бәхетемнән колак кагыйммыни?» – дигән җавап күңел түренә калкып чыгып, өстенлек алды. Автобуста барганда да шул ике уйның котырып көрәшкәненнән Раиләнең башы авырта башлады. Шуңа да базарга килеп җиткәч, ул иң элек даруханәгә кереп баш даруы алды. Шунда ул сатучыдан: «Кәҗәбезне бөтенләйгә йоклатасы иде, берәр агуы-

гыз юкмы?» – дип тузга язмаган сорау бирүен сизмичә дә калды. «Моны ветаптекадан сорагыз», – дигән җавапны тиз генә аңлап та бетермәде, аннан, исенә килеп, тиз генә чыгып китәргә ашыкты.

Аулак почмактагы әби урынында иде. Шуның янына килеп баскач, Раилә каушап, сүзен башлап җибәрә алмыйча торды, аннары тотлыга-тотлыга, даруханәдә биргән ахмак соравын нигәдер кабатларга булды:

– М-миңа н-ни... Н-ни инде... Кыскасы, авырган кәҗәбезне... бөтенләйгә йоклатасы иде... Агулы үлән кирәк...

...Әби башын күтәрде дә, сәер үтенеч белдергән кызның йөзенә игътибар белән бераз карап торганнан соң, сорады:

– Кәҗә дисеңме? Нәрсә булган кәҗәгезгә?

– Авырып китте... – диде Раилә, шушы ике сүзне калтыраган иреннәре аша көч-хәл белән яңгыратып.

– Кыяфәтеңә караганда, кәҗә түгел, ә син авырып киткәнсең! – дип, карчык урыныннан торды да, уң кул бармаклары белән ишарәләп, кызга үзенә таба иелергә кушты, аннары як-якка каранып алып, ярымпышылдап әйтте:

– Йәле кызым, яныбызда кеше булмаганда сөйлә әле дөресен – ни булды? Курыкмыйча сөйлә – бөтен сөйләшкәннәребез, валлаһи, үзара гына калачак!

Әллә онытылып, әллә михнәт вә борчу белән тулган күңел кәсәсен кичекмәстән бушатырга теләп, Раилә елый-елый әбигә барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

– Аннан котылмыйча, яхшы, тыныч тормыш булмаячак! – диде ул сөйләгәннәрен җөпләп, һәм «мине сатмас микән?» дигән шикелле әбекәйгә сагаеп карап куйды. Ләкин әби рухи яктан изаланып беткән кызны гаҗәпләндереп, аңа теләктәшлек белдергәндәй башын какты да:

– Ярый кызым, аңладым. Котыласы булгач, котыласы инде. Агуларбыз биемеңне. Минем моның өчен кирәкле үләннәрем дә бар... – дип

күзләрен серле итеп ялтыратып алды. Астагы тартмаларында бераз актарынганнан соң, ул Раилә алдына берничә кечкенә төргәген чыгарып салды да, кызны якын иткәндәй пыш-пыш килеп, болай диде:

Син, кызым, шунысын аңла: биемеңне кинәт кенә, бер минут эчендә агуласаң, шунда ук синнән шикләнәчәкләр. Шуңа күрә мин сиңа кешене акрынлап бетерә торган үләннәр төнәтмәсен ясарга өйрәтәм. Шуның бер кашыгын каенанаң ризыгына сиздермичә генә өстәп болгатырсың – берничә айдан дошманың үлем түшәгенә ятачак. Әмма сак бул: кеше-кара белә күрмәсен…

Карчыкны зур игътибар белән тыңлап, күңел аша үткәрелгән һәр сүзенә диярлек «әйе, ярар» дигән сыман башын кагып торган Раилә шулай җайлы гына ярдәмче-фикердәше табылуына сөенеп бетә алмады. «Фикердәше» исә янә як-якка каранып алып, пышылдавын дәвам итте:

– Һәм тагын бер бик мөһим киңәш: бүгеннән башлап аңа якты чырай күрсәтеп, гел елмаеп тор: янәсе синең ниятеңдә берninди яман-хәтәр юк… Нәрсә генә дисә дә, яхшы сүз белән җавап кайтар, аңа карата гел ихтирамлы, илтифатлы бул. Шулай итсәң, каенанаң үлгәннән соң, синнән беркем шикләнмәячәк… Аңладыңмы?

Үлән сатучының әйткәннәрен Раилә, әлбәттә, бик яхшы аңлады. Шуңа күрә кайтуына биеме: «Ярты көн «гүләйттә» йөрдең, фәлән син дә төгән!» дип ни генә әйтмәсен, бер сүз каршы дәшмәде, эченнән генә: «Моның үлемтек әйберләре алынган микән?» – дип кенә уйлап куйды. Ире төнгә эшкә китеп, каенанасы ятканнан соң, Раилә аш бүлмәсендә табак-савыт белән маташкан булып, базарда сатып алынган төргәкләрне чыгарды да, нәкъ үлән сатучы өйрәткәнчә төнәтмә ясады, соңыннан явыз убырдай күзләрен ялтыратып:

– Көннәрең санаулы, озакламый хушлашабыз синең белән, аждаһа… – дип борын астыннан гына мыгырданып куйды.

Иртән бием кәҗәне савып, сөт савытын мич артындагы эскәмиягә куйды да, тавыкларга ашарга салам дип абзарга чыгып китте. Форсаттан файдаланып, Раилә тиз генә каенанасының зур бизәкле чынаягына сөт салды, аннары төнлә әзерләгән төнәтмәнең бер кашыгын шунда бушатып, болгатып куйды. Каенанасы өйгә керүгә Раилә: «Әни, урын-җиреңне җыештырдым, идәннәрне сөртеп алдым, сиңа сөт салып өстәлгә куйдым, эчәрсең!» – дип сандугачлардай черелдәп, мөлаем елмаеп җибәрде. Каенана нәрсә диярга дә белмичә, аптырап калды. Шулай да, утырып, бер чокыр сөтне эчеп бетергәч: «Уф, әллә авыз тәме юк шунда...» – дип кенә әйтте дә, бакчага чыгып китте. Менә шул көннән башланды да инде. Раилә биеменә ничек тә ярарга тырышып, якты чырай күрсәтеп, елмаеп кына торды, үзе көн дә иртән агу салынган бер чынаяк сөт әзерләп бирде.

Бервакыт, ишегалдында кер элгәндә, Раилә очраклы гына каенанасының күрше Саимә апа белән урамда, капка алдында сөйләшкәннәрен ишетеп алды.

– Нихәл, Миннисәттәй? Әллә авырыйсыңмы? – күренмичә тордың бу арада?

– Үзем исән-сау, Аллага шөкер. Менә киленем генә әллә нишләде бит әле...

– Нәрсә булган Раиләгә?

– Нәрсә булсын? Сәерләнеп китте киленебез: бер сүз каршы әйтми, авызына киртә тотканнармыни...

– Кит аннан...

– Чын менә! Нәрсә кушсаң да, «син дигәндә – аяк идәндә!» дигән шикелле чабып кына йөри. Йөзендә елмаю, телендә – татлы сүз... Хәйран калырсың: бер булмаганны – миңа көн дә хәтта эчәремә сөтне дә әзерләп куя!

Килене белән үзе дә эт белән мәчедәй яшәгән Саимә апа ике кулын селтәп алъяпкычына кагып алды да: «Вәт заразы!» – дип гаҗәпләнүен

белдерде, һәм шунда ук: «Личит итәргә кирәк аны, личит итәргә!» – дип кырт кисеп, хөкем дә чыгарып куйды.

Шулай атналар узды. Һәркөн иртән каенана агу кушылган сөтне эчеп барса да, аны-моны сизенмәде (базардагы әби үләннәрне белеп биргәндер инде, күрәсең). Биеменең озакламый үләсен белгәнгә, Раилә кайвакыт аны кызганып та куя иде. Шуңа күрә мыр-мыр килеп йөрүләренә каршы дәшмәде, киресенчә – назлы тавыш белән «ярар-ярар» дип тәкрарлап, авызын ерып торды. Тора-бара Миннисә апа да килененә мөгамәләсен үзгәртте: үзе дә сизмәстән, каныгуларын киметеп, аңа елмая башлады, кайвакыт онытылып «кызым» дип тә әйткәләде, кыскасы, үзара мөнәсәбәтләре көннән-көн яхшыра барды. Иртән Раилә биеменә сөт әзерләгән булса, көндез һәм кичен каенана (хәтта улы өйдә булмаса да) килененә тәмле итеп чәйләр әзерләп эчертә башлады, аның татлы сүзләренә матур итеп җавап кайтарды. Ә бер көнне Раилә каенанасының күрше Саимә апа белән ишегалдында сөйләшкәннәренә аш бүлмәсенең бераз ачык калган тәрәзәсе аша янә шаһит булганнан соң, аптырап, тирән уйга батты. Йомыркага дип кергән җиреннән, сүз иярә сүз чыгып, Саимә апа күршесеннән килене хакында сорашасы итте.

– Теге тәмсез хәсрәтең ничек соң анда – һаман үз туксаны туксанмы? – дип зәһәрләнеп сорап куйды ул, күршесен чәнчүле карашы белән бораулап. Әмма Миннисә апа аңа теләктәшлек белдереп килененнән зарланасы урынга, күршесен көтелмәгән җавабы белән шаккатырды:

– Нишләп хәсрәт булсын ди ул? Күңеле яхшылыкта, изгелектә булган киленемне үз кызымнан да ким күрмим мин хәзер. Миңа шундый килен биргәнгә Аллаһы Тәгаләгә мең шөкер!

Шушы сүзләрне ишетүгә Раилә кулындагы табаны төшереп җибәрә язды. Тора-бара ул үзе дә каенанасын үз әниседәй күреп, аны бөтен җаны-калебе белән яратканын, бик якын иткәнен аңлады. Тик… Йә Аллаһ! Ул бит аны үз куллары белән инде берничә ай кабергә керергә дип әзерләп

йөрде. Гадәткә кергәч, теге үләннәр төнәтмәсен бүген дә сөтенә салган иде. «Их, тинтәк мин, тинтәк!» – дип тиргәде үз-үзен Раилә. – Белә торып кешене агулап ят инде, йә! Базардагы әби әйткән вакыт та килеп җитә... Нишләргә?!»

Сәгать инде төнге уникедән авышып китүгә карамастан, Раилә шомлы уйлар тәэсирендә йоклый алмыйча ятты. Җәйге төннең тынлыгын бүлеп черелдәгән чикерткәләр бертуктаусыз: «Тинтә-әк! Тинтә-әк!» – дип черелдәп тора сыман. Инде сәгатьтән артык үзенең дуамал, мәгънәсез, ахмак гамәле турында уйланып, Раилә үз-үзенә бер үк сорауны бирә: нишләргә? Ярый әле Рәсим бүген эштә түгел. Ләкин бит ул хатынының күңел халәтен, гомумән, нәрсә булганын белми, әнә ич – гамьсез мышнап, тыныч кына йоклап ята, җаныкай. Уртаклашып киңәшерлек кеше булмагач, Раилә өй янындагы алмагач ботаклары аша бүлмәне кырыс, хәтта ачулы яктырткан айга мөрәҗәгать итте: ниш-ләр-гә... Ә ул – дәшми. Белмидер инде ул да, нишләргә... Каян белсен? Күңелдә – үкенү, һәм курку... Әллә Рәсимне уятып бәйнә-бәйнә барысын сөйләргә дә, бу мәсьәләне уртага салып, бергәләп хәл итү юлын эзләп карарга? Юк... Юк-юк, кирәкми... Ул белсә!..

Тагын шулай өзгәләнеп, җан газабыннан җәфаланып бераз ятканнан соң, Раилә үз әбисенең «мәхлүкъ белмәс, Аллаһы белер» дигән сүзләрен исенә төшерә. Шуңа да торып авыл мәчете урнашкан якка юнәлеп тезләнә дә, ихластан Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп сорый: «Йә Раббым, нишләргә? Әнкәбезне ничек коткарырга?..» Дога кылып бетерүе була, шунда ук күңелендә шундый фикер туа: базардагы үлән сатучыга барып, икенче төрле – шифалы, ул биргән агуның зарарын бетерә торган үләннәр сорарга кирәк! Әйе-әйе, нәкъ шулай итәргә кирәк!.

Бу төнне Раилә йокламады диярлек. Иртә белән йокымсырап киткәч кенә, ул иренең хафалы дәшүеннән уянып, күзен ачты.

– Раилә, тор, әни әллә нишләп китте бит әле! – диде шомлы тавыш белән Рәсим.

Тәненә ут капкандай сикереп торып, Раилә тизрәк каенанасы янына ашыкты. Агарынган, хәлсез, тирләп пешкән биеме караватында авыр сулап ята иде.

– Әни, нишләдең син? Нәрсә булды сиңа? – диде Раилә хафаланып, һәм куркуыннан калтырана ук башлады.

– Инде кичә үк ... үземне начар хис итә башладым... Ә менә бүген... бөтенләй начараеп киттем... Эчем ут яна... – дип сүрелгән зәгыйфь тавыш белән җавап бирде ана.

«Бетте баш – өлгермәдем...» – дигән коточкыч фикер Раиләне кара кайгыга салды. Шулай нәрсә эшләргә белмичә бермәл басып торганнан соң, Рәсим: «Болай булмас, табиб кирәк», – дип телефоннан ашыгыч ярдәмгә шалтыратты. Раилә исә: «Кыяфәтенә караганда, нәрсә беләндер агуланган бугай ул. Минем шәһәрдәге бер танышым шундый авыруларны дәвалый, тиз генә барып кайтыйм әле мин», – дип, автобус тукталышына юнәлде.

Раиләгә шул көнне 25 минутлык юл очы-кырые булмаган мәңгелек булып тоелды. Аллаһының рәхмәте, үлән сатучы әби урынында иде. Аның янына йөгереп килгәч, кыз үкси-үкси әбигә олы гозерен җиткерде:

– Әниебез... Әнкәбез... Бик авыр хәлдә... Зинһар, коткарыгыз!..

– Тынычлан! Әниең авырып киттемени? – диде үлән сатучы, һәм зур игътибар белән Раиләнең күзләренә бакты.

– Үз әнием түгел – каенанам! Исегездәме, минем үтенечем буенча сез аны агулар өчен миңа үләннәр биргән идегез! Эчерттем бит шуңа аларны, тинтәк, эчерттем! Ә хәзер минем аны үтерәсем килми! Ишетәсезме? Ул яшәргә тиеш! Ул... ул... бу дөньядагы иң яхшы биem! Мин аны үз әнием кебек бик яратам... Аллаһы хакы өчен сорыйм: миңа сез биргән агуның

зарарын бетерүче үләннәр бирегезче! Коткарыгыз аны, апа! Зинһар, коткарыгыз!

Раиләнең кабаланып, өзгәләнеп бик җитди гозерен белдерүенә карамастан, әби бер дә исе китмәгәндәй күзләрен кысып елмая башлады. Елап беткән кыз: «Аһ син елан… Хәйләкәр аждаһа!» – дип уйлап куярга өлгермәде, карчык аның кулын ике учы белән кысып алды да, ягымлы, йомшак тавыш белән әйтте:

– Бер дә борчылма, кызым. Теге вакытта мин бит сиңа агу түгел, ә йөрәкне ныгытучы шифалы үләннәр бирдем. Агу исә синең башыңда иде. Холкыңны төзәтеп, олы кешегә карата сабыр, күндәм, ихтирамлы булырга өйрәнеп, син шул агуыңнан арына алдың…

Әбинең шушы сүзләреннән хәйран калып, Раилә башта нәрсә дияргә дә белмәде. Бераздан гына күз яшьләре аша елмаеп, әйтте:

– Һм… Алай икән… Менә хикмәт… Әмма бүген әниебез каты чирләп, урын өстендә ятып калды бит… Анысы нәрсә булыр тагын?

– Бер дә борчылма, – дип җавап бирде әби. – Кизүдер ул, кызым, терелер әнкәгез. Мә, балакаем, менә шушы үләннең төнәтмәсен эчертерсең, булышырга тиеш. Акчасын да алмыйм! Шунысы гына бик борчый: хәзер шактый күп гаиләләрдә, яшьләр һәм өлкәннәр арасында мин-минлек, кирелек, үзсүзлелек чире таралган. Менә монысы – чыннан да куркыныч кизү. Аннан имин булыр өчен бер-береңә елмаеп, яхшы сүз әйтеп, игелекле гамәл кылып, җаннардагы боздан, каннардагы тоздан арынырга һәм башкаларны да үзеңне яраткан кебек яратырга, хөрмәт итәргә өйрәнәсе иде! Ә сезнең гаиләдә булган хәл, кызым, ул – бик күпләр өчен гыйбрәт булырлык бер хикмәтле сабак, – диде әби, һәм киң итеп елмаеп җибәрде дә:

– «Агулы» сабак! – дип атар идем мин моны! – дип, Раиләне яратып аркасыннан каккалап алды.

*Ришат хәзрәт Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*